ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Илгиз Кадыйров**
**Илсөяр Закирова**

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МУЗЫКАЛЬ-ЭПИК ИҖАТЫ

## Себер ареалы

Казан
2022

**УДК 392.5**
**ББК 82.3(2=632.3)**
**К 13**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы тәкъдиме буенча басыла*

**Редколлегия:**

*К.М. Миңнуллин* (рәис), *О.Р. Хисамов, И.И. Ямалтдинов,*
*Н.Х. Нургаянова, Г.Г. Гыйлемҗанова*

Ноталарны компьютерда җыючылар:

*Д.Н. Арсланова, Н.Х. Нургаянова*

**Рецензентлар:**

Л.Х. Дәүләтшина, Г.Г. Гыйлемҗанова

**Кадыйров И.Ш., Закирова И.Г.**
К 13 **Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты:** Себер ареалы / И.Ш. Кадыйров, И.Г. Закирова. – Казан, 2022. – 312 б.
ISBN 978-5-93091-425-2

Себер татарларының музыкаль мирасын өйрәнүгә багышланган сериядә дөнья күргән икенче китап татар халык иҗатының көй белән башкарыла торган эпик һәм лиро-эпик жанрлары турында бай мәгълүмат бирә. Хезмәттә һәр жанрга бәйле фәнни мәкаләләр, 1968–1972 елларда үткәрелгән фәнни экспедицияләр вакытында татар музыкасы һәм фольклор белгече Илгиз Кадыйров тарафыннан тупланган дастан, бәет, мөнәҗәтләрнең ноталары һәм текст үрнәкләре тәкъдим ителә.

Китап татар халкының милли-мәдәни мирасы, музыка сәнгате белән кызыксынучыларга адреслана.

УДК 392.5
ББК 82.3(2=632.3)

**ISBN 978-5-93091-425-2**

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2022
© Кадыйров И.Ш., 2022
© Закирова И.Г., 2022

# КЕРЕШ

Әлеге китап Себер татарларының музыкаль мирасын өйрәнүгә багышланган сериянең икенчесе булып, әлегә кадәр мәгълүм булган хезмәтләрдән шактый аерыла. Биредә халык музыкасы белгече Илгиз Кадыйровның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында[1] эшләгән чорда (1968–1977) Себернең Төмән, Новосибирск, Томск, Омск, Кемерово өлкәләрендә узган экспедицияләр вакытында язып алынган дастан-йомак назымнары, бәет, эчтәлекләре һәм башкарылу үзенчәлекләре белән бәетләргә якын тарихи җырлар һәм мөнәҗәт көйләре тупланды.

Әби-бабаларыбызның көйләп мөнәҗәт укулары, бәет әйтүләре, яки озын-озын кыйссаларны көйгә салып укулары күпләребезгә таныш.

Кышкы кичләрдә йон өмәсенә җыелган хатын-кызлар бераз аралашып алганнан соң, арадан берәрсе «Йосыф кыйссасын» көйли башлый:

*Газиз Йосыф тәмам унбер яшәр ирде,*
*Якуб сәүче итәгендә уйкур ирди...*

Күпмедер вакыттан башкаручы туктап кала. Ул арада, өмәчеләр, алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен сөртә-сөртә, кыйссаның эчтәлеге турында, геройларның язмышы турында сөйләшеп ала. Өлкән яшьтәгеләрнең күбесе «Кыйссаи Йосыф»-ны яттан белә, берсе туктап калса, икенчесе дәвам итә. Бераз гәпләшеп алганнан соң, апалар кыйссаны туктаган җиреннән

---

[1] 1996 елдан Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

дәвам итәләр. Көйләп башкарыла торган кыйссалар күп. Бер очрашканда «Йосыф кыйссасы», икенчесендә «Таһир-Зөһрә», өченчесендә «Сак-Сок» бәетен көйлиләр.

«Сак-Сок» бәетен татар халкының бер үзенчәлекле маркеры дип карарга мөмкин. Кайда гына яшәсә дә, татар халкы «Сак-Сок» бәетен яхшы белә. Хәзер дә, экспедицияләр вакытында нәрсә сөйләргә белми аптырап калган информантларга «Сак-Сок» бәетен искә төшерәбез. Сак белән Сок дигән кошларга әверелеп, өенә кайта алмаган балалар турындагы бу бәет безнең, кайда гына яшәсәк тә, бер халык булуыбызны раслап тора. Язмышмы яки тормышмы җир шары буенча сипкән бик күп татарлар да, Сак белән Сок кебек, бер аерылып киткән туфракларын сагынып, җирсеп яшиләр. Бер-берсе белән очраша алмаган туганнар турындагы «Сак-Сок» бәете – менә шуңа күрә дә татарның иң популяр фольклор әсәредер.

«Сак-Сок» бәете берничә көйгә башкарыла, сүзләренең дә берничә варианты очрый. Әлбәттә, Себердә дә әлеге бәетне беләләр, саклыйлар. Хәзер дә, көйләп күрсәтә алмаган информантлар сүзләрен искә төшерә, әби-бабалары язып калдырган кулъязмаларны күрсәтә. Бу бәет, шул рәвешле, информант белән фольклорчы арасындагы чикләрне алып ата да барыбызның да Сак белән Сок кебек аерылган татар балалары булуын тагын да искәртә кебек.

Халыкны тетрәндергән вакыйгалар артыннан иҗат ителгән бәетләр дә – көйләп башкарыла торган жанр. Тарихи бәетләр зур тарихи вакыйгаларны чагылдырса, шәхси фаҗига бәетләре аерым трагик хәлләрне бәян итә. Тарихи бәетләрнең бер өлеше төрле сугышларга багышланган. Алар эчтәлекләре белән тарихи җырларга якын. Сугыш җырларының аерым строфалары сугыш бәетләренә дә керә һәм киресенчә, ягъни бер үк строфа ике жанр арасында йөрергә мөмкин. Шәхси фаҗига бәетләре арасында да бик популяр әсәрләр бар. Алар билгеле бер төбәктә бер кешенең фаҗигасы аркасында иҗат ителгән булуына карамастан, хәзерге вакытта киң таралыш алган. Шундый бәетләргә

«Әбделмән купец», «Суга баткан Гайшә бәете», «Зөлхәбирә» бәетләрен кертергә мөмкин. Бу бәетләрдә шәхси фаҗига турында сүз барса да, бәла аерым гаиләгә генә килмәгән, күп халыкны тетрәткән, еш кына алар артында халык фаҗигасы ята.

Эчтәлекләре белән бәетләргә якын торган тарихи җырларда да халык тормышының аерым вакыйгалары, төгәлрәк әйткәндә, зур вакыйгалар турында мәгълүмат саклана. Бу – татар халкының авыл-авыл, нәсел-нәсел булып Себергә күчеп китүен чагылдырган «Бараба җиренә күчкәндә» җыры, Герман сугышының кайтавазы булган «Герман сугышы» җыры, сугыш җырлары...

Китапта дастаннар яки мөнәҗәт-бәетләрнең Себернең төрле өлкәләрендә язып алынган көйләренең нотациясе һәм поэтик текст кына түгел, мөмкин булганда шушы ук регионда язып алынган тулы текстлары да бирелә. Татар халкының иң популяр дастаннарын берничә вариантта бирү дә бу кыйммәтле мирасның байлыгын күзалларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны иң күп таралган дастаннардан, аның дистәләгән вариантлары язып алынган. Шул рәвешле һәр әсәр белән мөмкин кадәр тулы һәм төрле яклап танышырга мөмкинлек туа.

Һәр бүлек алдыннан бирелгән мәкаләләрдә дастан һәм йомак, бәет һәм мөнәҗәт көйләренә анализ ясала. Татар халык фольклорының дастан жанры, аерым әсәрләр, аларның үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирелә. Лиро-эпик әсәрләрнең көй үзенчәлекләренә багышланган мәкаләләрне, шушы сериядә чыккан «Татар халкының туй җырлары: Себер ареалы» дигән беренче китапны укучылар фикерләрен истә тотып, рус телле киң катлау укучыларга аңлаешлы итү максатыннан, рус телендә бирү урынлы дип табылды.

Бу басма – ярты гасыр элек язып алынган милли мирасны халыкка кайтарган олы хезмәт. Ул үз укучысын, үз башкаручысын табар дип ышанабыз.

*И. Закирова*

## СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ МУЗЫКАСЫ

1968–1977 елларда, СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшләгәндә, миңа, фәнни экспедицияләргә чыгып, Көнбатыш Себер татарларының музыкаль-поэтик иҗатын өйрәнергә туры килде. Әлеге мәкалә әнә шул экспедицияләр нәтиҗәсендә туган иде.

Көнбатыш Себер татарлары Көнбатыш Себернең урманлы-далалы көньяк өлешендә урнашкан. Авыллары башлыча Иртыш, Тура, Тара, Ом, Исәт, Тубыл һәм башка елгалар буена утырган. Бу елгалар калын урманнар һәм үтә алмаслык сазлыклар аша бердәнбер аралашу юлы да булган.

Татарлар, нигездә, авылларда, азрак санда Төмән, Тубыл, Том, Тара, Барабинск, Новосибирск, Омск һ. б. шәһәрләрдә яшиләр.

Хәзерге Себер татарларының иң якын борынгы бабалары булып XII–XIII гасырларда Көнбатыш Себер далаларыннан алып, Иделнең түбән өлешенә кадәрге киң мәйданда яшәүче төрки телле кыпчак кабиләләре санала.

Көнбатыш Себер территориясендә монгол империясенең Җүчи улусы җирендә Төмән ханлыгы барлыкка килә. Бу Себер татарларының беренче берләшмәсе була[1]. Соңыннан Себер ханлыгы оеша. Аның башында XVI йөзнең алтмышынчы елларында Күчем хан (күчмә үзбәкләрдән килгән шәйбанлыклардан)

---

[1] Очерки истории СССР. Период феодализма. IX–XV вв. Ч. II. М. Изд-во Акад. Наук СССР, 1953. С. 464.

тора[1]. Ханлык озак яшәми. 1582 елда Күчем хан җиңелә һәм аның территориясе Рус дәүләтенә кушыла.

Себер ханлыгында яши торган төрки телле кабиләләр билгеле бер дәрәҗәдә казакъларга, күчмә үзбәкләргә һәм, күрәсең, нугайларга да кардәш булган[2].

Себер татарлары формалашуда Казан, Самара, Сембер, Пенза һәм Россиянең башка губерналарыннан күчеп килгән татарлар да катнаша. Шунысы кызык, Себердә аларның барысы да Казан татарлары дип йөртелә. Россиядән татарларның күчеп килүләре XX йөз башларына кадәр дәвам итә. Алар арасында сөргенгә җибәрелеп, Себердә яшәп калганнары, Үзәк Россиядә җир җитешмәү сәбәпле килеп төпләнгәннәре дә бар.

Халкыбызның шактый зур этник төркемен тәшкил иткән Көнбатыш Себер татарларының музыка мәдәнияте XIX гасырның 60 нчы елларына кадәр белгечләребез игътибарыннан читтәрәк кала килде. Моңа, әлбәттә, бу төбәкнең төп сәяси һәм мәдәни үзәгебез Казаннан ераклыгы да комачаулык итте. Революциягә кадәрге чорда басылган хезмәтләрдән Себер татарларының телен һәм халык авыз иҗатын өйрәнү өчен иң кыйммәтле чыганак итеп академик В.В. Радловның «Төрки кабиләләренең халык әдәбияты үрнәкләре»н генә китерергә мөмкин[3].

1864 елда «Тобольские губернские ведомости»да Тубыл татарлары җырлары басылып чыга[4]. Аларны җыюда Тубыл татары Нияз Урмаев булышкан. Укымышлы бу кеше булдыра алган кадәр диалекталь үзенчәлекләрен саклап, сигез дистә чамасы дүртьюллык язып алган һәм русчага тәрҗемә иткән.

Себер татарларының музыкаль фольклор үрнәкләрен беренче булып шагыйрь Мөхәммәт Садри җыя. Ул 1940 елда Көн-

---

[1] *Потапов Л.П.* Этнический состав и происхождение алтайцев. Л.: Наука, 1969. С. 81.

[2] Шунда ук. Б. 82.

[3] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен. СПб., 1872.

[4] Тобольские губернские ведомости. 1861. С. 35–45.

батыш Себергә оештырылган фәнни экспедиция[1] вакытында фонографка Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә яшәүче татарлардан күп санда җырлар һәм көйләр язып ала. Соңрак композитор А.С. Ключарев бу язмаларны нотага сала һәм кырыктан артык җыр-көйне «Татар халык көйләре» җыентыгына кертә[2]. Алар арасында инде хәзер гомумтатар музыка хәзинәсенең энҗеләренә әверелгән «Карьят батыр», «Сәрвиназ», «Илчебага», «Зәңгәр күз» җырлары бар.

Себер татарларының берничә җырын композитор Җәүдәт Фәйзи дә язып ала. «Халык җәүһәрләре» дип аталган җыентыгына ул 1965 елны Төмән һәм Тубыл шәһәрләрендә язып алган берничә җырны кертә. Шулардан «Сахралар» һәм «Усакайлар» җырлары Татарстан радиосы концертларында еш яңгырый иде.

Себер татарлары җырлары турында Х. Ярми, М. Госманов, М. Мәһдиев, Ф. Әхмәтова, Ф. Урманчеев хезмәтләрендә байтак мәгълүматлар табарга мөмкин.

СССР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты һәм сәнгать секторлары тарафыннан 1968–1975 елларда оештырылган экспедицияләр Себер татарлары иҗатының гаять катлаулы һәм составы ягыннан чуар булуын күрсәтте. Монда Көнбатыш Себер татарларының җирле диалекталь фольклоры, Казан ягы фольклоры (казан татарлары, керәшен һәм мишәр татарлары белән килгән фольклор), татар халкының күпчелек этник төркемнәренә уртак үрнәкләр – гомумтатар классик фольклоры, бохаралы, башкорт, казакъ һәм рус халыкларының гаҗәеп себерләшкән фольклоры барысы бергә үзенчәлекле мозаика тәшкил итә.

---

[1] Экспедиция Татарстан Халык Комиссариаты карамагындагы Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты һәм Казан музыка кабинеты тарафыннан Х. Ярми, С. Әмиров, В. Хаҗиев, М. Садри составында оештырыла.

[2] Татар халык көйләре / төзүче һәм җыючы А.С. Ключарев. Казан, 1955.

Себер татарлары шигъри-музыкаль иҗатының формалашуы һәм үсүе халык булып оешу процессы белән тыгыз бәйләнештә барган дип карарга кирәк. Тарихи эзлеклелекне нигез итеп алып, аны гомуми рәвештә генә дүрт чорга аерып карарга була: иң борынгы, борынгы, яңа һәм бүгенге чор.

Иң борынгы чордагы музыкаль фольклорны без гомумтөрки фольклоры дип, ягъни Себер татарларының бабалары Алтай йортыннан аерылып чыкканда үзләре белән алып киткән хәзинә дип фикер йөртәбез.

Борынгы фольклор, нигездә, XVII гасырга кадәр, ягъни Себер ханлыгы чорында формалашкан дип санарга мөмкин. Бу чорда музыкаль фольклор аерым вак этник төркемнәрнең җыр-көйләре җыелмасы рәвешендә генә яши, чөнки Себер татарлары бердәм халык булып формалашырга өлгермәгәннәр.

Борынгы фольклорга бохаралы, казакъ һәм башка төрки телле халыкларның, шулай ук ханты-мансиларның өлешчә йогынтысы булырга тиеш. Беренчеләре Себер йортының таркалуына кадәр үк килеп утыра башласалар, калганнары алар белән озак гасырлар янәшә яшәгәннәр.

Яңа фольклор чоры исә XVII гасырда Идел буе өлкәләреннән күчеп килүче татарларның халык иҗаты белән тыгыз элемтә башлану нәтиҗәсендә туа башлый. «Күчеп утыручылар аерым авыллар булып та, шул ук вакытта Себер татарлары белән бергә дә утыралар»[1]. Шушы чордан алып, Себер татарлары тормышында яңа дәвер башлана. Кайчандыр Алтай йортында бергә булып, соңыннан төрле тарихи сәбәпләр аркасында шактый гасырлар аерылып яшәгән һәм шул дәвер эчендә һәрберсе үзенчәлекле музыкаль фольклор үрнәкләре тудырып өлгергән кардәш халыклар XVII гасырда бер-берсенә яңадан якыная башлыйлар. Моңа кадәр дә аларның рухи бәйләнеше бервакытта да өзелеп тормаган. Чөнки Себер ханлыгы Болгар

---

[1] *Храмова В.В.* Западносибирские татар // Народы Сибири. М.-Л.: Изд-во акад. наук СССР, 1956. С. 474.

дәүләте һәм Казан ханлыгы белән даими сәяси һәм икътисади багланышта торган.

Казан татарлары үзләре белән башлыча ангемитоник пентатоника ладына корылган җыр-көйләр һәм бәетләр алып киләләр. Җирле халыкның музыкаль фикерләве пентатониканың көчле йогынтысын кичерә. Себер татарлары арасына акрынлап ислам дине керә башлый. Бу хәл, үз чиратында, мөнәҗәтләрнең таралуына китерә.

Мишәр татарлары исә ангемитоника һәм диатоникага бай катнаш көйләр алып киләләр. Алар җирле фольклорга органик рәвештә кушылып китәләр. Чөнки диатоник көй агышы өчен Себер татарларында күптәннән җирлек була.

Тулаем алганда, Казан татарлары музыкаль иҗатының Себер татарларына тәэсире гаять киң, һәм ул әле аерым бәет-мөнәҗәт һәм җыр-көйләрне турыдан-туры күчереп алуга гына кайтып калмый. Экспедиция материаллары шуны күрсәтте: Себер төбәгендә татар музыкаль фольклоры тулы яңгыраш алган һәм аның барлык жанрлары да диярлек иҗади файдаланыла. Монда сүз, шулай итеп, Себер татарларының музыкаль фикерләвенә тирәнтен үтеп керү турында бара. Әлбәттә, иҗади ярдәмләшү төрле чорда төрле дәрәҗәдә булган һәм торган саен катлаулырак төс алган. Мондый тыгыз һәм нәтиҗәле иҗади бәйләнеш ике халыкның да музыкаль һәм шигъри фикерләвендә уртак сыйфатлар булганда гына мөмкин.

Икенче бер төбәктән килгән җыр-көйләр җирле татарларның традицион фольклоры белән янәшә «тыныч кына» яшәми, әлбәттә. Алар, кагыйдә буларак, җирле музыка стиле белән тыгыз элемтәгә керә, «уртак тел» табарга тырыша, аның кай өлешен булса да үзенә муафыйк килерлек итеп үзгәртә, һәм шул ук вакытта алар үзләре дә акрынлап ассимиляциягә дучар була – «себерләшәләр». Күп очракта хәтта ул җырларның кайсысы җирле, ә кайсысы күчеп килгән булуын билгеләү ифрат читенләшә. Бу, үз чиратында, яңа үзләштерелгән

фольклор үрнәкләренең җирле төбәктә тоткан ролен билгеләргә комачаулый.

Җирле һәм читтән килгән фольклорның күп гасырлар дәвамында бер-берсе белән шулай тыгыз элемтәгә кереп, аерып ала алмаслык дәрәҗәдә «чорналып» үсүе Себер татарлары музыкасының катлаулы стиль комплексы тууына китергән.

Себер төбәгендә җыеп алынган музыкаль-шигъри хәзинәне, башкарылу рәвешенә карап, өч төргә бүләргә мөмкин: көйләүләр, көйләр, җырлар.

Көйләүләрнең нинди дә булса бер йола белән бәйләнгәннәре һәм мөстәкыйль башкарыла торганнары бар. Йола көйләүләренең бүгенге көндә бары тик калдыклары гына сакланып калган, ул да булса – «Яңгыр теләү». Бары тик ике тавышлы гына булган бу гади көйләү, һичшиксез, Себер татарларының гына түгел, ә гомумтатар фольклорының иң борынгы үрнәкләреннән берсе булырга тиеш[1]. Себер вариантына охшаш көйне күрше казакъ халык иҗатында да очратырга мөмкин.

Мөстәкыйль көйләүләрдән дастан һәм әкият назымнарын, бәет, мөнәҗәтләрне күрсәтә алабыз.

Көйләрнең шулай ук тормыш-көнкүреш йоласы белән бәйләнгәннәре (аларны могам дип йөртәләр, мәсәлән, «Шайтан могам», «Ат могам») һәм мөстәкыйль башкарыла торганнары бар. Соңгыларына бию көйләре, инструменталь маршлар һәм пьесалар керә.

Җырлар – Себер татарлары музыкасында иң зур төркем. Җыр аша аерым шәхеснең дә, бөтен бер халыкның да эчке рухи дөньясы ачыла. «Җырын алалмадың – серен алалмадың!» Тормыш-көнкүреш һәм эчке дөньяларының җыр-көйләрдән аерылгысыз икәнлеген алар әнә шундый тапкыр сүз белән бел-

[1] Ике тавышлы яңгыр теләү көйләрен кара: *Абдуллин А.* Тематика и жанры татарской дореволюционной народной песни // Вопросы татарской музыки. Казань, 1967, С. 15; *Нигмедзянов М.* Олиготонные лады в татарской народной музыке // Советская музыка. 1974. № 1.

дергәннәр. Җырлар шулай ук йола җырлары һәм мөстәкыйль җырлар (лирик җырлар) төркеменә аерылалар. Йола җырлары арасында туй җырлары иң күренекле урынны алып тора. Болар: кияүне кыз куенына озату җырлары («Кияү типсәү»), ишек бавы җыры, кызның чәчен икегә аерып үргәндә башкарылган җырлар («Яр-яр», «Үләң таш»), кызны егет өенә озату, туй мәҗлесендә кода-кодагыйларның бер-берсен макташу җырлары, кара-каршы башкарыла торган күңелле туй уены җырлары («Хан кызы», «Башмак» һ. б.), сатып яки көчләп бирелгән кызларның ата-анасын, туган авылын каргап китү җырлары.

Гаилә тормышында туйлар чын мәгънәсендә зур вакыйга булган. Туйга авыл халкы белән беррәттән алыстан да кода-кодагыйлар һәм кардәшләр килгән. Кагыйдә буларак, килен читтән алынган. Чөнки ыруглык калдыклары озак сакланып калган Себер татарларында бер авыл кешеләре бер-берсе белән туган-тумача саналган.

Туй – ул яңа гаилә төзү, кыз белән егетнең җитлегүен котлау тантанасы. Яучылау һәм фатиха бирүдән алып, туйдан кунаклар таралган вакытка кадәр булган һәрбер адым тирән әхлакый мәгънәгә ия. Ул берничә гасырлар элек шушы этник төркемгә хас тормыш-көнкүреш һәм гаилә-әхлак кагыйдәләреннән чыгып булдырылган.

Туйларга махсус рәвештә җырчылар һәм музыкантлар чакырылган һәм туйның уңышлы килеп чыгуы алар осталыгына да турыдан-туры бәйләнгән. Мондый мөнәсәбәт, күрәсең, туйдагы җыр-музыка үзенә күрә ниндидер магик көчкә ия була дигән ышануга нигезләнгән. Бу ышану Себер татарларында XX гасыр башларына кадәр дәвам итә. Туй йоласы җырлары да шул чоргача актив рәвештә башкарылып килә, һәм ул җырлар өлкән яшьтәге кешеләр хәтерендә әле дә саклана.

Туй йоласы җырлары туйның өч өлешендә башкарылган: кияүне урам буйлап, тип сугып, кыз өенә озата барганда («Кияү типсәү», «Күч җыры», «Кияү сүзе», «Ялтыр-талалтир»), кыз

өенең капка төбендә («Ишек бавы»), егет өенә китәр алдыннан кызның чәчен икегә аерып үргәндә («Яр-яр» яки «Үләң таш»), «Яр-яр» җырларына тукталып үтик.

Себер татарларында, кайбер башка халыклардагы кебек, кыз белән яшь киленне чәч толымына карап аерганнар. Кызлар чәчне – бер, яшь киленнәр ике толым итеп үрергә тиеш булганнар. Шуңа күрә чәч аеру ритуалы кыз озатканда иң изге, иң җаваплы йолаларның берсе саналган[1]. Ул болай үтәлгән. Кияү белән кияү егетләре кыз алырга килгәч, чыбылдык эчендәге кызның чәчен җиңгәләре махсус тарак белән елый-елый икегә аерып үрә башлыйлар, һәм шул вакытта кызның туган-үскән йорты, ата-анасы, дус-ишләре, туган-тумачалары белән саубуллашу сәгате җиткәнне аңлатып, «Яр-яр» әйтелә башлый.

«Яр-яр» җырлары гаять зур территориядә яшәүче төрки телле халыкларның кыпчак төркеменә караганнарына хас. Күрше казакъларда ул – «Җар-җар», үзбәкләрдә – «Ёр-ёр», нугайларда – «Хей-җар», каракалпакларда – «Хауҗар», Башкортстандагы Ык буе татарларында – «Яр-яр».

«Яр-яр»ның шигъри тексты Кормашиның «Кыйссаи бүз егет» дастанына да кертелгән. Бу очраклымы? Күрәсең, юк. һәрхәлдә, XVII гасырга караган «Яр-яр» текстының безнең Идел төбәгендә табылуы бу йола җырының Идел буенда яшәүче татарларга да ят нәрсә булмаганлыгын күрсәтә[2]. Драматург М. Фәйзинең дә «Кызыл йолдыз» пьесасына бу куплетларны кертүе, һичшиксез, халык иҗатына таянудан килә.

«Кияү типсәү». Түбән өлкәсе авылларында шушы җыр белән кияүне кыз куенына озатканнар. Бу болай булган. Башка авылдан килгән кияү иң элек дусларына яки туган-тумачаларына туктый. Нүгәрләр (кияү егетләре) кияүне ике яктан култыклап алып,

---

[1] *Әхмәтова Ф., Гайнанов Р.* Себер юлларында // Социалистик Татарстан. 1967. 13 авг.

[2] *Усманов М.* Об археографических экспедициях Казанского университета // Тихомировские чтения 1970 года. М., 1970. С. 122.

шушы җыр белән кыз өенә алып киләләр. Әгәр дә кияү буласы егет күңеленә хуш килгән кеше булса, кыз түшәк җәеп көтеп торган, ошамаса – чыгып качкан. Бу очракта аны беркем дә ирексезләп бирергә батырчылык итмәгән. Шунысы кызык: кайвакытта олы яшькә җиткән картлар да, шаярып һәм дә гомер иткән карчыгын сынарга теләп, үзләрен шулай «иңдертеп» йөргәннәр.

Төмән өлкәсе Вагай районы Күләт авылында Халиков Хәйдәр бабай (1889 елгы) бу турыда менә нәрсәләр сөйләгән иде: *«Моны ялтир әйтү тиләр. Җегетне көнтес алып кереп таныштырып алатылар. Ваклар җиснә дип килгәч, ул аларга косык* (эрбет чикләвеге) *өләшә. Кич белән ялтир әйтеп ай әллерләп алып киләләр бичәгә. Иегет пелән кысга аерым чатыр коратылар. Кыены анта саклап утыратылар тyслары, җиңгәләре».*

Лирик җырлар – Себер татарлары шигъри-музыкаль иҗатының иң зур тармагы. Музыкаль тасвирлау чараларының байлыгы, шигъри нәфислеге белән аерылып торган бу җырларны халыкның эстетик кичерешләре көзгесе дип әйтергә мөмкин. Лирик җырларга киң колачлы аһәң хас. Төрле йола һәм гореф-гадәтләр белән бәйле әсәрләр зур иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр аркасында онытылуга таба барган вакытта алар урынын лирик җырлар биләп ала. Җанрлар төрлелеге кимесә дә, җыр-көйнең халык өчен әһәмияте кимеми. Лирик җырлар халык тормыш-көнкүрешенең барлык тармакларына үтеп керә, аның тематикасы киңәя.

Себер татарларының лирик җырларын якынча дүрт төркемгә: сузып җырлана торган иректе метро-ритмдагы эпик яңгырашлы озын көйләргә, иректе метро-ритмдагы лирик озын көйләргә, төгәл метро-ритмдагы квадрат структуралы җыйнак, кыска көйләргә, ирекле метро-ритмдагы баш өлештән һәм төгәл метро-ритмдагы җыйнак кушымтадан торган озынча салмак җырларга бүләргә була..

Беренче төркемгә Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында Абтюкова Сәлимә (1925 елгы), Сауpгач авы-

лында Разулев Шәфикъ (1913 елгы), Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында Таҗетдинова Җәмилә (1906 елгы), Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Хәбибуллин Кәримулладан (1928 елгы) язып алынган «Борынгы җыр», «Туктасын качкы», «Мәхмүт мәргән», «Кара да гына елан» һәм башка җырларны алырга була. Киң эпик яңгырашлы бу җырлар Себер татарлары иҗатына аеруча хас үрнәкләрдән санала.

Бигрәк тә Бараба татарларының иң күркәм һәм киң таралган «Кара да гына елан» һәм «Асыл кошлар» җырларын һәр җырчы белә диярлек. Ә Казан ягыннан килгәннәре исә «бу инде чын барабалар көе» дип искәртеп куярга онытмыйлар.

Озын лирик көйләр (икенче төркем) – иң күпсанлы. Аларны йөзләп санарга була, һәм үзенчәлекләрен дә бер-ике үрнәк белән күзаллау һич мөмкин түгел. «Туп-туп баскан туры ат», «Аргамагым», «Агавын» (Бараба татарлары), «Иске пасхуд», «Җиктем күк юрга» (Омск өлкәсе), «Димен лә», «Бадьян баскыч», «Моңлы көй» (Том татарлары) җырлары халык телендә әле дә яши.

Калган ике төркемгә кергән җырлар Себер татарларының һәр этник төбәгенә дә бердәй хас.

Шунысы кызыклы, лирик озын көйләргә «Йосыф-Зөләйха», «Бүз егет», «Таһир-Зөһрә», «Сәйфелмөлек» кебек мәгълүм дастаннарның аерым өзекләре дә җырлана. Алар күптән инде мөстәкыйль җыр булып таралып киткәннәр.

Себер татарларының музыка сәнгате тамырлары белән тарих тирәнлегенә китә. Аның нигезләре борынгы төрки телле кабиләләрнең шигъри-музыкаль хәзинәсеннән аерылгысыз. Кайбер гомумтөрки бәйләнешләрне карап үтик.

Менә бараба татарларының тыңдәшсез «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны. «Шигъри хәзинәсендә «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны булган һәрбер халык аны үз әсәре дип исәпли, туган телендә сөйли, милли моңы белән җырлый... Безнеңчә, дастанның һәрбер милли версиясе һәм

барлык вариантлары бер тамырдан үсеп чыккан, бер тамырдан таралган», дип яза Ф. Урманчеев. Бу гаҗәеп әсәр халык тормышының үткәнен зур панорама итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Дастанның төп эчтәлеге сөйләп, кайбер диалоглары көйләп әйтелә. Ләкин аның кайчандыр уен коралына (мәсәлән, «Җатыган» дип йөртелә торган кыллы уен коралына) кушылып, көйләп әйтелүендә безнең шигебез юк.

«Хан кызы» җыры, фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләргә керә[1]. Шуңа карамастан, «эчтәлеге белән дә, формасы ягыннан да әсәр бәет жанрының башка үрнәкләреннән аерылып тора»[2] икән. Менә шул аерымлыкларын исәпкә алып та, кайбер фольклорчылар «Хан кызы» бәет түгел, җыр дип исәплиләр. Себер татарлары, мәсәлән, Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында яшәүче Исәньярова Зинникамал (1927 елгы) «Хан кызы»н җыр дип атый. Аның әйтүенчә, туй мәҗлесләрендә, яшьләрнең аулак өендә ул кара-каршы башкарылган күңелле, шаян җыр икән. Аны кунакларның кәефен күтәрү, китәсе кызның туган өйдән аерылу хәсрәтен җиңеләйтү өчен җырлаганнар.

Фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләр бары тик безнең татар халык иҗатына гына хас жанр. «Башка халыкларда безнең бәетләргә тәңгәл килердәй әсәрләр юк. Дөрес, бәетләр башкорт халык иҗатында да бар. Ләкин, башкорт галимнәре фикеренчә, алар татар фольклоры йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән»[3].

Ә менә Ф.Н. Катановның хакасларда язып алынган фольклор үрнәкләре арасында «Хан кызы» җырының шигъри юлларына тәңгәл килә торган әсәр бар[4]. Үзбәк халкында да шуңа охшаш җырны очратабыз.

---

[1] *Бәдигый Х.* Халык әдәбияты. Бәетләр. Казан, 1913.

[2] *Урманчеев Ф.* Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар. Казан, 1974. Б. 83.

[3] Шунда ук.

[4] *Катанов Ф.Н.* Хакасский фольклор. Абакан, 1963. С. 20, 98.

Йигит:

*Сочинги узун дейдилар,*
*Доно укам, ёр-ёр,*
*Кора соч укам, ёр-ёр,*
*Курсат сочингни бир курайин,*
*Жоним укам, ёр-ёр!*

Киз:

*Сочимни куриб нима киласиз,*
*Сиз акажоним, ёр-ёр,*
*Жон акажоним, ёр-ёр,*
*Бозордаги сочпапукни*
*Курмабмидингиз, ёр-ёр!*

«Хан кызы» Себер татарларында гына таралган җыр түгел[1]. Мәсәлән, ул Г. Тукайның җырлар дәфтәрендә дә бар (кызганычка каршы, бу көйнең җырлары дәфтәрдән ертып алынган[2]. Г. Тукай аны җырлар арасына кертә, бәетләр белән бутамый. Әлбәттә, бу кызыклы факт. Менә шуңа күрә дә «Хан кызы»ның яңа вариантларын язып алырга кирәк. Күп вариантларның көй һәм сүзләрен чагыштырып карагач кына җырның төп функциясе турында катгый фикер йөртергә мөмкин булачак.

Себер татарлары иҗатын өйрәнгәндә кайбер бәхәсле җырлар да очрый. Мәсәлән, «Тамчы тама» шундыйлардан. Аның көе С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовның мәгълүм «Эшче» операсындагы Нигъмәт ариясе белән тәңгәл килә. Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылында Йосыпова Шәмсинур (1900 елгы) көйнең бу авылда бик күптәннән, «бабайлар заманыннан» билгеле булуын әйткән иде.

Көйнең Себердә бик популяр булуын төп Себер татары Таминдаров Сәгыйр (1888–1975) дә раслады. Аның әйтүенчә,

---

[1] Бер вариант Н. Мөштәриева тарафыннан Пермь өлкәсендә язып алынган.

[2] *Тукай Г.* Әсәрләр. 2 том. Казан, 1955. Б. 295.

Кемерово өлкәсендә яшәүче калмакларда бу җырны нүгәр егетләре кызны егет өенә озатыр алдыннан җырлаганнар. Җыйналган барлык кеше елаган. 1969 елның көзендә бу җырны ачыклау өчен махсус рәвештә Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылына керелде (С. Таминдаров исә күрше Эскәтем авылында туган). Авылның иң өлкән кешесе Шулаяков Гафур бабай бу җырны «Кыз озату җыры» дип яздырды. Яшь вакытта ул аны нүгәр егете булып җырлап йөргән. Димәк, җырның ким дигәндә алтмыш еллык гомере бар. «Эшче» операсы исә 1930 елны сәхнәгә куела.

Солтан Габәшинең Нигъмәт ариясе турында язмалары күренми (һәрхәлдә, әлегә табылмаган). Шуңа күрә бу көйне Себер татарларыныкы дип өзеп әйтергә ашыкмыйк. С. Габәши – халык җырларын җыючы һәм өйрәнүче, музыкаль фольклорны гаять тирәннән белүче. Әгәр дә композитор үзе белгән һәм җыйган йөзләгән көйләрнең берәрсен операда файдалана икән, бу профессиональ музыка өлкәсендә табигый хәл санала. Күп вакытта автор көйнең кайдан алынуын да әйтеп тормый. Мәсәлән, Җ. Фәйзи 1952 елда Әлмәт шәһәрендә язып алган «Сагынам» җырының көен «Тапшырылмаган хатлар» операсында Галия ариясендә генә файдаланып калмый, операның төп музыкаль лейтмотивы итә.

Теге яки бу җыр-көйнең таралып китүен алдан әйтү кыен. Алар, иң беренче чиратта, фән өчен әһәмиятле. Теләсә кайсы халыкның музыкаль-поэтик хәзинәсе – зур мәдәни кыйммәте булган, илебез музыкантлары һәм галимнәренең игътибарын көннән-көн үзенә җәлеп итә торган тиңдәшсез дәүләт милке. Аны мөмкин кадәр югалтмыйча җыю һәм саклау – дәүләт эше.

Себер татарлары җыр-көйләрен магнитофон тасмасына яздыруда йөзләрчә җырчылар катнашты. Шулар арасында Нургалиева Вәйдә, Абитов Биктимер, Уразов Зәйнулла, Разулев Шәфикъ, Хәбибуллин Кәримулла, Сөләйманов Имаметдин, Таҗетдинова Җәмилә, Корманов Шәриф, Шулаяков Гафур,

Таминдаров Сәгыйр кебек кабатланмас иҗади шәхесләр белән очрашулар күңелдә тирән эз калдырды. Аларның һәрберсе – халык иҗатындагы коллектив башлангычның һәм шул ук вакытта башка җырчыларга караганда чагыштырмача индивидуальләшүнең гүзәл гәүдәләнеше. Алар – халыкның кадерле мирасы, иң әһәмиятле милли үзенчәлекләреннән берсе булган музыкасын һәм аны башкару традициясен саклаучы, яшьләрнең тәрбиячесе һәм акыллы киңәшчесе. Музыкантлар һәрвакыт иҗтимагый тормышның уртасында яши.

Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында яшәүче Абитов Биктимер абый татар халык җырларын күп белүе белән безне таң калдырды. Аның башкаруында магнитофон тасмасына кырыктан артык җыр язып алынды[1]. Аңарчы билгеле булмаган «Җиктем күк юрга», «Ямщикәй», «Иске пасхуд», «Сәвә» (кыз исеме), «Уракчы», «Милай Мәхмүзә», «Исәт» һәм башка бик күп җыр-көйләр үзенчәлекле интонацион лад төзелешләре белән аерылып торалар иде.

Биктимер абыйдан язып алынган җырлар тематик яктан гаҗәеп күптөрле: арада тормыш-көнкүреш җырлары да, ямщиклар моң-зары, бәет-мөнәҗәтләр дә бар. Иң күбесе – мәхәббәт җырлары. Аларга эпик яңгыраш, тирән фәлсәфи мәгънә хас.

Биктимер абый бу зур мирасның күп өлешен әтисеннән өйрәнгән. Әтисе Мәлик бабай әйләнә-тирәдә дан тоткан җырчы-ямщик булган. Безне таң калдырганы тагын шул булды: үлем түшәгендә ятканда да Мәлик бабай җырларын Биктимер абыйга өйрәтеп яткан. Менә кайда ул музыкаль традициянең көче, менә кайда ул саекмас чишмәләр!

*И. Кадыйров*

*Казан утлары. 1979. № 4;*
*Түгәрәк уен. 2013. № 1–2*

---

[1] Мондый феноменнар әкият сөйләүчеләр арасында да бар. Мәсәлән, шул ук районның Эбаргул авылында 78 яшьлек Хамматов Әхмәт бабай егерме әкият яздырды.

## НАПЕВЫ В ДАСТАНАХ И СКАЗКАХ ЗАПАДНО-СИБИРСКИХ ТАТАР

Фольклор западно-сибирских татар богат и разнообразен высокоразвитыми, классическими образцами эпических памятников. К ним относятся дастаны и сказки. Благодаря академику В.В. Радлову[1] («первоклассный мировой ученый» – акад. В.В. Бартольд) они стали достоянием мировой культуры уже сто лет тому назад[2]. Многое, что было собрано В.В. Радловым бытует и в наши дни. Новые записи показывают, что из всего традиционного фольклора сравнительно хорошо сохранились эпические произведения. На это в свое время обратил внимание Х. Ярмухаметов. «Можно, например, смело говорить о том, что в отличие от фольклора казанских татар в поэтическом наследии сибирских татар гораздо полнее сохранились эпические произведения – сказания и дастаны ранних веков»[3].

По определению М. Нигмедзянова, уже «со второй половины XVI в. ... стал постепенно исчезать из музыкального быта

---

[1] О В.В. Радлове см.: *Ярмухаметов Х.Х.* В.В. Радлов и изучение татарского фольклора // Тезисы докладов итоговой научной сессии за 1972 год. Изд. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН СССР. Казань, 1973. С. 81–83.

[2] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен. Т. IV. СПб., 1872. Здесь опубликованы дастаны «Кузы Күрпәч мән Баян-Сылу», «Бури хан», «Йерән Чичән», «Көрнең улы» и др., сказки «Мешәк Алып», «Тимеркендек», «Суфи патша» и др.

[3] *Ярмухаметов Х.* Сказание «Козы -Курпеч и Баян-Слу» в устном творчестве сибирских татар // Народный эпос «Кузы-Курпес и Маян-Хылу» (сборник статей). Уфа, 1964. С. 91.

татарского народа ряд жанров, ... эпико-исторические, героические, шуточные песни или баиты, песни и музыка, сопровождающие массовые празднества. Некоторые из этих жанров сохранились до конца XIX в. у сибирских татар (героический эпос)[1].

Музыкальное воплощение эпических произведений, по утверждению многих исследователей, относится к наиболее древним видам народного творчества. Так как эпос не принадлежит к категории массово-обиходных жанров, исполнение его доступно лишь выдающимся народным талантам, которые объединяют в себе дар рассказчика, поэта, певца и музыканта.

Дастаны[2] следует рассматривать как целостную музыкально-поэтическую форму воссоздания «широкоформатной» картины народной жизни далекого прошлого. Как писал В.В. Радлов, эпос поэтически отражает «всей жизни и всех стремлений народа, которые состоят, понятно, из отдельных характеристических черт»[3].

Эпос – жанр синкретический. Он является объектом исследования многих наук. Музыкальную фольклористику интересует прежде всего музыкальное воплощение эпических произведений, т.е. напевы в дастанах и сказках.

---

[1] *Нигмедзянов М.* Народная музыка // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., Наука, 1967. С. 447.

[2] «Тарихи поэмалар (героик поэмалар), рус фольклорындагы былина һәм эпослар, татар халык әдәбиятындагы дастаннар/дастан (фарсыча) – экият, хикәят дигән сүз, эпик поэзия жанрына керәләр. Дастаннар тарихта тирән эз калдырган зур иҗтимагый вакыйгалар җирлегендә барлыкка килгәннәр. Аларның баш геройлары – шушы вакыйгаларда җитәкчелек иткән тарихи затлар. Бу геройлар кайбер дастаннарда яки бер үк дастанның төрле вариантларында хәтта лирик сурәтләргә киендерелеп алынганнар. Ничек кенә булмасын, дастаннарның реаль нигезе булып тарихи вакыйгалар тора. Дастаннарның авторлары – халык, хезмәт ияләре коллективы». См.: *Җәләй Л.* «Идегәй» дастаны турында // Совет әдәбияты. 1940. № 5–6. Б. 157.

[3] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы северных тюркских племен. Наречие дикокаменных киргизов. СПб., 1889. С. 12.

Изучение всего материала, записанных с времен В.В. Радлова до настоящего времени показывает то, что у западносибирских татар дастаны[1] исполняются в двух формах: стихотворно-песнопенной форме и повествовательной с иллюстративным песнопением. Вторая форма – основная, наиболее распространенная. Такую форму[2] имеет бытующий у барабинских татар выдающийся памятник поэзии кыпчакской группы тюркских народов (казахов, башкир, алтайцев, уйгур) – «Кузы-Курпе и Баян-Слу». Основное содержание дастана исполняется в прозаической форме, а некоторые диалоги – вокальными фрагментами без инструментального сопровождения[3]. Но нет сомнений в том, что в недалеком прошлом дастанчи сопровождали свое пение. Об этом говорит недавнее бытование щипкового музыкального инструмента «җатаган», напоминающего перевернутое корыто с натянутыми струнами[4].

В народном творчестве западно-сибирских татар эпическое песнопение «көйләү» по своему стилю отличается от других песенных жанров, баитов и мунажатов. Пока для обширных исследований у нас музыкального материала явно недостаточно, поэтические и музыкальные средства выразительности, мелодико-интонационный и ладовой строй, ритмический склад и, наконец, манера исполнения позволяют выделить напевы дастанов и сказок в особый самостоятельный вид народного музыкально-поэтического творчества.

---

[1] Жанровые разновидности сибиротатарского эпоса см.: *Ахметова Ф.В.* О героическом в богатырских сказках сибирских татар // Тезисы докладов итоговой научной сессии за 1972 год. Издание ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФ АН СССР., Казань, 1973. С. 86.

[2] Такая форма исполнения нашла отражение и в самом народном творчестве. Напр., есть загадка о ветре: «Үзе көйли, үзе сөйли, үзенең теле юк». «Сам напевает, сам же рассказывает, а языка – нет (подчеркнуто нами. – *И.К.*).

[3] Материалы экспедиций Ф.В. Ахметовой.

[4] О жатыгане см. в разделе «Музыкальные инструменты».

Среди барабинских татар бытуют сказки («йомак»), стихотворные части которых имеют свои напевы. Нами записаны сказки «Мултел» (имя девочки) и стихотворный отрывок из сказки «Была я дочерью Колганбая». В этих не очень больших сказках места, исполняющиеся нараспев, являются неотделимым элементом сюжета. Такое явление характерно только для сибирских сказок? Отнюдь нет.

В опубликованных да этого сборниках татарских народных сказках нередко встречаются и стихотворные части[1]. Трудно судить об исполнении этих стихов нараспев, т.к. не имеется нотных приложений и объяснительных комментариев. Во всяком случае, они весьма удобны для распевания. Например,

| | |
|---|---|
| *Тәгәри китте йомгагым,* | Покатился клубочек мой, |
| *Күрмәдеңме, әбекәй.* | Не видела ли, бабуля. |

или:

| | |
|---|---|
| *Үләргә киткән түтекәй* | Тетя, ушедшая помирать |
| *Баеп кайта, ләң, ләң...*[2] | Вернулась богатой. |

А о пении героини Гульчачак (одноименная сказка) рассказывается в самой сказке:

*«Урман эче бик якты,*
*Күктә айлар калыкты,*
*Көлдән күмәч аламын,*
*Әниләргә барамын,*
*Әниләргә барамын, –*

дип җырлый-җырлый китеп бара»[3].

---

[1] Татар халык әкиятләре (Татарские народные сказки). Книга вторая / сост.: Г. Баширов и Х. Ярми. Казань, 1956.

[2] Там же. С. 266–259.

[3] Там же. С. 260–263.

(«В лесу стало светлее, на небе луна взошла, из золы калач возьму, домой к маме пойду, пела она»).

Эта строфа без изменений как бы рефреном, повторяется девять раз только в одной сказке! А таких мест в татарских сказках – чередование прозы и стиха – довольно частое явление. Не говорит ли оно о том, что поэтические слова поются или пелись раньше, а со временем пение перешло в «такмаклап әйтү» (говорить такмаком, песенкой).

По мнению С. Раимовой, народные сказки оказывают влияние на возбуждение интереса детей к песне и музыке (подчеркнуто нами. – *И.К.*). «В текст татарских народных сказок «Алпамша», «Гульчачак»[1] вплетаются песни, через песню полнее раскрываются образы положительных героев. В сказке сибирских татар «Мултел» песня помогает девочке Мултел найти своих братьев, а также утвердить победу добра и справедливости»[2].

А у народов Сибири?

Наличие музыкально-поэтических отрывков в сказках характерно и для некоторых народов и народностей Сибири. Например, в нанайских и удэгейских «прямая речь героев... обычно исполняется с музыкальной декламацией. Это очень простые напевы»[3]. А бурятские богатырские сказки – «... прозаические повествования с многочисленными стихотворными вставками...»[4] и т.д.

---

[1] Композитор Дж. Файзи называет «Гульчачак «музыкальной сказкой». См.: *Фәйзи Җ.* Музыка кичәләре. Казан, 1968. Б. 12.

[2] *Раимова С.И.* К вопросу о татарском детском музыкальном фольклоре // Вопросы истории, теории и музыки и музыкального воспитания. Уч. записки КГПИ, вып. 104. Казань, 1972. С. 40.

[3] Музыкальный фольклор народов Севера и Сибири. М.: Музыка, 1966. С. 18–19.

[4] *Баранникова Е.В.* Бурятские богатырские сказки // Эпическое творчество народов Сибири (тезисы докладов). Улан-Удэ, 1978. С. 66.

В арсенале народного творчества западносибирских татар (Омская и Тюменская области) широко бытуют татарские версии дастанов народов Востока (книжные дастаны), что очень важно для исследования взаимосвязи культур этих народов. Во время фольклорной экспедиции записаны дастаны «Буз егет», «Тахир-Зухра», «Сайфульмулюк»[1]. Например, Шариф Курманов (1889 г.р.)[2], считавший себя коренным бухарцем, исполнил «Бүз егет» с вокальными фрагментами – *назым*, среди которых – свадебная «Яр-яр», два баита и т.д.

Следует отметить огромную популярность вышеназванных дастанов. Видимо она и явилась причиной того, что отрывки из дастанов – назым – в настоящее время отделились от своих первоисточников и стали бытовать как самостоятельные лирические песни. Нужно иметь ввиду и то, что исполнение дастанов в наше время – явление чрезвычайно редкое.

Напевы дастанов и сказок, которые бытуют в наше время, являются яркими образцами древнейших пластов народного музыкального языка. Роль напевов состоит в восполнении стихотворно-прозаического повествования особой эмоциональной сферой, которую словесная поэзия создать не в состоянии.

При напевании, а тем более при инструментальном его сопровождении полнее раскрываются поэтические особенности текста, чувства и переживания персонажей, что дает возможность создать исполнителю дастана целостный художественный образ.

Стихотворные части дастанов и сказок западно-сибирских татар исполняются напевами неширокого диапазона декламационно-речитативного типа. Именно в речитативе проявляется наиболее непосредственная связь слова с музыкой. Эмоциональная окрашенность вокально-драматической речи приобретает здесь живость и убедительность.

---

[1] Записи Ф. Урманчеева и автора. Материалы экспедиции, 1969 г.

[2] Деревня Тусказан Большеречинского района Омской области.

Все напевы выдержаны в характере размеренного сказа, ибо на первом месте стоит не напев, а поэтическое повествование. В основном, напевы дастанов практически выполняют роль интонационно-ритмической основы повествования, помогая более эмоционально воспринять вокальные эпизоды, представляющие собой речи действующих лиц.

Однако своеобразие идейного содержания, поэтических и музыкальных средств выразительности, манера исполнения – все это резко отличает эпическое песнопение – «көйләү» – от других песенных жанров.

По структуре и типу мелодического развития, по своей роли как метроритмической канвы обширного стихотворного текста напевы дастанов весьма близки к баитам – одним из древних музыкально-поэтических жанров татарского народа. И там и тут поэтический текст приобретает ведущее положение.

Видимо оно вытекает, как отличает исследователь музыки монгольских эпических сказаний С.А. Кондратьев, из-за «внутренней борьбы между разнородными видами искусства, в данном случае – между музыкой и словом. Поэтому всякая законченная форма «словопения» есть всегда результат борьбы, в конечном счете – компромисс между требованием музыки и стиха или прозы. В таких компромиссах иногда преобладает влияние музыки, иногда – слова... а в улигере с его громадным количеством текста и капризным развитием фабулы доминирует слово, текст. Не удивительно поэтому, что пение улигера строится на несложных музыкальных темах»[1].

Аналогичное явление мы наблюдаем и в западно-сибирских эпических произведениях. Они являются музыкально-поэтическими импровизациями, где речитативное песнопение происходит на музыкально-ритмической канве.

---

[1] *Кондратьев С.А.* Музыка монгольского эпоса и песен. М.: Сов. композитор, 1970. С. 51.

Мелодическое строение напевов характеризуется лаконичностью и ограниченностью звукового объема, спокойными, речитативного плана, интонациями. Диапазон всего напева, в том числе отдельных фраз, в пределах большой сексты и октавы. Часто наблюдается изменчивость внутрифразовой ритмики, которую диктует импровизационность поэтического текста. Метрические соотношения звуков напева и слогов стиха предельно строги.

Во всех примерах наблюдается повторность звука, который является важнейшим приемом интонационного развития не только дастанных напевов, но и всей песенной мелодики.

Структура напевов имеет два вида: а) мелодическое предложение, состоящее из двух фраз, б) мелодический период, состоящий из двух предложений, каждое из которых четко разделяется на две фразы,

Например, в напевах сказок «Мултел» и «Была я дочерью Колганбая» применяется так называемый однострочный или стиховой напев. При многократном повторении их мелодический контур и ритмическая структура полностью сохраняются.

Как правило, в напевах дастанов и сказок мелодические и текстовые цезуры совпадают.

Как было отмечано выше, отдельные музыкальные эпизоды книжных дастанов народов Востока, таких как «Буз егет», «Тахир-Зухра», «Сайфульмулюк» приобрели некую исполнительскую самостоятельность в музыкальном быту. В таких случаях «көйләү» – речитативное песнопение сочетается с отчетливым мелодическим рисунком, с явной песенной оформленностью. Вследствие некоторого распева они переросли в лирические песни с теми же названиями: более развиты по форме и более индивидуализированы в интонационном отношении. Наиболее ярко это проявляется, на наш взгляд, в Омском варианте песни «Сайфульмулюк»[1].

[1] Записано в дер. Б. Тибендя Омской областити от Маматалиевой Фархи автором и Ф. Урманчеевым – в 1960, автором в 1974 году.

Однако мелодизм в дастанных напевах не проявляется в полную меру, ибо он все еще сковывается строгим метроритмом, ритмикой стиха. Такое положение приводит к ликвидации мелодической орнаментации и одноплановости интонационного развития.

Ладовое строение напевов в дастанах весьма характерное – почти все они имеют олиготонные ангемитонные ладовые строения. Например, в основе напева диалога Баян-Слу и снохи из дастана «Кузы-Курпэ и Баян-Слу» лежит наиболее распространенный вид – терцовый лад с нижней квартой, т.е. субквартой (по определению Т. Поповой).

Тетрахорд в квинте составляет ладовую основу напева «Была я дочерью Колган-бая».

Важную музыкально-стилистическую особенность напевов можно обнаружить в их ладовом развитии. В этих примерах оно протекает только в одной тонической (устойчивой) зоне. Субквартовая же (относительно устойчивая) зона выявляется крайне слабо, т.к. она представлена еще только одним звуком. Такое развитие следует считать первичным. Расстояние между зонами может быть и квартовым и терцовым. Оба примера такие. Но следует обратить особое внимание на второй. Здесь между субквартой и нижним крайним звуком тонической зоны – расстояние малой терции. Это именно расстояние, а не интервал, т.к. она не интонируется в мелодическом развитии и составляет лишь ступень общего звукоряда.

Взаимосвязь или взаимозависимость основных тонов зон выявляется через интонирование активной кварты. Здесь явное «централизованное» подчинение, которое минует побочную ступень.

Наличие активной кварты и ее восходящее направление приводит к тому, что большетерцовая тоническая зона всегда оказывается выше субквартовой, как обычно бывает наоборот в других жанрах (в деревенских напевах, баитах и др.).

В напевах характерным ладообразующим мелодическим движением являются прима и секунда, реже терция. Переход от субкварты в тонику и обратно осуществляется только квартовым шагом, как правило, эти звуки двух и трехкратно повторяются.

Такое кратное интонирование, т.е. «завоевание» учтойчивой и относительно устойчивой ступеней следует считать наиболее архаичным средством мелодического интонирования. Именно, в напеве «Была я дочерью Колганбая» впервые встречается двухкратное проведение всех четырех ступеней лада.

Следует указать на качественно разные в интонационном отношении терций в напеве «Мултел», т.к, звуки *h-g* расположены через ступень ангемитоники, а *g-e* являются соседними ступенями. Первая представляет некоторую трудность для интонирования. Поэтому, не случайно его появление на цензуре между фразами. Такой интервал следует назвать пассивным. Незначительная ширина звукоряда диктуется прежде всего специфическими условиями исполнения эпоса. Напев лишен самостоятельности. Он универсален. На этот мотив исполняется столько стихотворных строф, сколько диктуется художественными запросами данного дастана.

В напевах дастанов наблюдается развитие малозвучных бесполутоновых ладовых образований до полной пентатоники. Она выступает в основном как ладовое образование, организованное при помощи «сцепления» двух ангемитонных самостоятельных попевок. Сцепление весьма крепкое, т.к. обе зоны имеют по два общих звука. Причем один из них – соль (в напеве «Мөлтәл») находится в центре общего пентатонного звукоряда. Оба ячейки «крутятся» вокруг общей оси. Обе фразы начинаются именно с этого центра. Вторая мелодическая фраза повторяется семь раз, т.е. до полного исчерпывания строк строфы. Этим подчеркивается значение и главенствующее его положение среди обеих зон.

Здесь наблюдается одна из самых интереснейших ладовых особенностей общетатарского мелоса *s-t* соотношение ладовых тяготений. Именно в этом примере можно наблюдать постепенный переход ладового центра от верхней зоны к нижней. Здесь нужно говорить именно о переходе, т.к. мелодическое завершение происходит не на I ст., а на II ст., что редчайшее явление в ладовых образованиях татарской народной музыки. Такое можно наблюдать только в очень древних напевах. Это происходит от того, что II ст. пока нейтрален в функциональном отношении.

Она почти одинаково тяготеет и к I ст. и к III ст., т.к. разрешается к обоим: при нисходящем – в I ст. при восходящем направлении при повторении стихов строфы в III ст. Видимо, в напеве «Мөлтәл» включение II ст. вызвано чисто художественной целью создать ощущение постоянной неустойчивости, незавершенности мелодического движения.

Но в более ранних примерах, например, в напеве диалога Кузы-Курпе с матерью появление II ст. вызвано иной необходимостью, а именно – опевающей и вспомогательной. В первом проведении напева он не имеет собственного слога текста. Во втором и третьем проведении он не появляется. Исчезновение его придает напеву сурово-сдержанной эпический характер. А в последнем, четвертом проведении напева звукоряд достигает ангемитонной пентатоники. В каденции при нисхождении от верхнего звука лада к основному тону II ст. поддерживает поступенность хода к тонике.

Появление II ст. (а это равносильно рождению нового ладового образования – пентатоники) проходит еле заметным, т.к. для него уже интонационный простор завоеван ходом субквarты. Однако следует считать, что завоевание пентатонного звукоряда проходило в довольно длительном этапе развития народной музыки.

Образование пентатоники как сложной ладовой системы, при помощи сцепления из двух ладо-интонационных зон убеж-

дает нас в том, что основное мелодическое развитие содержится в больше терцовой зоне. Именно на ее основе при помощи единого интонационного шага субкварты строится ладовая рамка пентатоники.

Приведенный краткий анализ показывает то, что в выяснении зарождения и эволюции ладоинтонационных особенностей пентатоники как одного из основного ладоинтонационного мышления народно-песенного творчества сибирских татар, да и не только этих татар, напевы дастанов и других обрядовых жанров представляют особый интерес. Именно в этих жанрах наблюдается определенная историческая последовательность возникновения и развития олиготонных и пентатонных ладовых образований ангемитонного строения. Мало выявление полевого материала и как результат этого слабоизученность, особенно олигатоники вынуждает нас пока ограничиваться только предположениями. Поэтому, нужно вести фронтальное собирание во всех этнических группах и сравнительное его изучение во всех аспектах.

*И. Кадыров*

## ТАТАР ХАЛЫК ДАСТАННАРЫ – ҖЫРУЛЫ ЙОМАК

Алыплар тормышын, пәһлеван баһадирларның аңлашылып та бетмәгән батырлыгын, ил батырларының басып алучыларга каршы яуларын, ханнарның тәхет өчен барган көрәшен, үзенә аталган кәләшне эзләп юлга чыккан геройларның мажаралачарын тасвирлаган чәчмә, тезмә яки шигъри һәм чәчмә өлешләре аралашып килгән зур күләмле әсәрләрне татар фольклорында фарсы теленнән кергән сүз белән *дастан* дип атау кабул ителгән. Бу термин «буыннан буынга күчеп сөйләнә торган тормыш турындагы хикәя» мәгънәсендә йөри. Гомумән, фольклористика фәнендә дастаннар *эпос* термины астында карала. В.М. Жирмунский, әлеге жанрның әһәмиятен күрсәтеп: «Эпос – ул халыкның героик идеаллаштыру масштабындагы үткәне. Аның фәнни һәм тарихи кыйммәте, шул ук вакытта гаять зур иҗтимагый, мәдәни, тәрбияви әһәмияте дә шуның белән аңлатыла», – дип яза. Ягъни, дастаннар – халыкның узган тормышын, халык тарихындагы аерым вакыйгаларны героик планда тасвирлаган фундаменталь характердагы эпик яки лиро-эпик әсәрләр, дип билгеләргә мөмкин.

Дастанның билгеләмәсе эпос жанрының асыл сыйфатлары белән тәңгәл килә: героик, фантастик һәм романик эчтәлекле шигъри – поэтик, прозаик яки катнаш формадагы әсәрләрне әдәбиятта һәм фольклорда дастан дип атыйлар .

Татар фольклористикасында шушы ук жанрны аңлаткан кыйсса һәм хикәят терминнары да бар. Башка төрки халыклар-

да да эпосның үз милли атамалары бар. Шулай да озак вакытлар бу жанрның хасиятен аңлаткан башка термины да булырга тиеш, дигән уй баштан китмәде. Себердә узган күпсанлы экспедицияләр вакытында информантларның дастаннарны әкиятләрдән аермавы, аларның барысын да «йомак» дип атавы күзәтелә. Бары 2019 елда Төмән өлкәсенең Саз ягы авылларында эшләгән вакытта бу күренешнең сәбәбе ачыкланды. Лайтамак, Вәчир авылларында (Тубыл районы) яшәүче информантларыбыз жанрга карата «җырулы йомак» терминын кулланалар. Лайтамак авылында яшәүче Хәтимә апа Колмәмәтова (1940 елгы) әлеге терминның һәрвакыт кулланылуын, *йомак* белән *җырулы йомакның* аермасын – икенчесендә көйле өлешләр булуын аңлатты.

Татар дастаннары – тезмә, ягъни шигъри һәм чәчмә өлешләр аралашып барган әсәрләр. Күбесендә тезмә өлеш бик аз сакланган. Бу күренеш тә җырау-чичән профессиясе югалу белән аңлатыла. Үзләре дә шигъри осталыкка ия, импровизациягә сәләтле бу талант ияләре тезмә текстларны сәгатьләр буе башкарган. Кайбер әсәрләр яки дастаннарның аерым фрагментлары музыка коралларына кушылып, көй белән башкарылган. Җыраулар юкка чыкканнан соң, дастаннарны көйләп башкару аларның эчтәлеген сөйләү белән алышынган. Бу, әлбәттә, күпчелек әсәрләрнең югалуына, күләмнәре кимүгә китергән. Без язма текст аша укый торган дастаннарның бер өлеше – борынгы эпосның кыскача эчтәлеге, дип атау да дөреслектән ерак түгел. Аерым тезмә өлешләре җыр булып киткән дастаннар да бар.

Татар халкының дистә гасырлар элек ислам динен кабул итүе, язулы һәм китаплы булуы, аның дастаннарына да тәэсир итми калмаган. Җырау-чичәннәр иҗатын китап алыштырган. Шул ук вакытта ислам диненең шаманчылыкны тыюы да әлеге иҗат ияләрен эзәрлекләүгә китергән. Чөнки һәр җырау яки акын күпмедер дәрәҗәдә шаман яки күрәзәче вазифасын да башкарган. Мәсәлән, «Идегәй» дастаны аша исеме безнең көннәргә

килеп җиткән Субра җырауның башкалар белмәгәнне белүе, киләчәкне һәм үткәнне күрә алуы тасвирлана.

Дастаннарны башкаруның үзенең күптөрле шартлары һәм тыюлары булган. Әлбәттә, иң беренче шарты – чичәнлек традицияләренә, импровизацияләү сәләтенә ия булу. Җырау булу – Күкләр яки Тәңре тарафыннан бирелгән сәләт буларак бәяләнгән. Көннең яки елның теләсә кайсы вакытында да дастан сөйләмәгәннәр. Аерым әсәрләрдә бирелгән информация буыннан-буынга күчеп, күпмедер дәрәҗәдә язылмаган тарих ролен дә башкарган.

Эпос яки дастаннарның барлыкка килә башлавы ыруглык җәмгыяте һәм ыруглык мөнәсәбәтләре җимерелә башлаган чорларга карый. Әмма соңгырак чорларга караган текстларда да борынгы ышанулар белән үрелгән мотивлар (дөнья яратылу, күкләр, җир һәм җир асты дөньялары турындагы космогоник карашлар) саклана. Борынгы дастаннарның күбесе мифларга таяна, мифологик ышануларның эзләрен саклый. Галимнәр эпос жанрының бер башлангыч чыганагы мифлар булса, икенче чыганагы, бигрәк тә соңгырак чорда, тарихи риваятьләр булганлыгын күрсәтәләр. Архаик эпоста эпик вакыт – мифик дәвер һәм шул ук вакытта ыру-кабиләләргә хас яшәеш нормалары, борынгы йолалар, кабиләара бәрелешләр, табигатьнең кырыс стихиясен һәм төрле явызлыкларны гәүдәләндергән мифик көчләргә каршы көрәш тасвирлана. Мондый көрәш-бәрелешләрдә, кагыйдә буларак, үзара дошманлашып яшәгән дуаль система сурәтләнә, ул «бу дөнья» яки «үз җире» белән «теге дөнья» яки «чит-ят җирләр» «арасында хөкем сөргән каршылык рәвешендә күрсәтелә. Теге дөньяда яшәүче дошман көчләр, гадәттә, мифик-демоник көчкә ия яки куркыныч зат итеп бирелә. Эпос каһарманы шул көчләрне җиңү яки буйсындыру исәбенә тормышта тәртип, гармония урнаштыру өчен көрәш алып бара. Дошманын җиңәргә аңа батыр аты, куәтле коралы ярдәм итә.

Төрки фольклорда капма-каршылыкkка корылган дуаль система күпчелек очракта никах белән бәйле сюжетларда чагылыш таба. Герой үзенең кәләшен икенче дөньядан – ятлар дөньясыннан ала, аны эзләп параллель дөньяга барып чыга, төрле авыр сынауларны уза, «теге дөнья» вәкилләре белән көрәшә. Эпик герой өчен бары үзе яшәгән территория генә «үз» дөньясы булып, билгеле бер чикне узуга «ят», икенче дөнья башлана. «Ят» дөнья – җир асты ( «Йиртөшлек»), су асты («Түләк») дөньялары булырга, яки елга, дәрья аръягында («Алып Манаш») урнашырга мөмкин. Күрше территорияләр дә «ят» дөньяга карый, ул герой яшәгән территория белән янәшә, ыру агачы Байтирәкне яки Байкаенны узгач башланырга да мөмкин («Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу»).

Идеаллаштырылучы эпик герой еш кына могҗиза белән туа. Ул – ярым кеше, ярым илаһи зат. Герой, анадан туу белән җир, кешеләр дөньясына караса да, тууына илаһи көчләр сәбәпче булу, аның гади кеше түгеллеген күрсәтә. Бала тууда атаның роле илаһи затка бала сорап мөрәҗәгать итүгә, ягъни илаһият белән ике арада арадашчы булуга кайтып кала. Эпик геройның гадәти кеше булмавын күрсәткән билгеләре дә бар: әйтик, башындагы алтын чәч толымы («Кузы-Көрпәч»), аркасындагы яки маңгаендагы мөһере («Алпамыш»). Аның үлемсезлеге яки гадәттән тыш үлеме дә геройны гади җир кешеләреннән аерып куя («Ак Күбәк»).

Дастаннарда халыкның этник тарихы, тормыш-көнкүрешенә бәйле үзенчәлекләре, йолалары, гореф-гадәтләре чагылыш таба. Әмма, табигый, тарихи дастан тарих эзеннән генә бармый. Сәнгатьчә эшкәртүгә дучар ителгән әлеге төр эпоста да уйдырма мотивлар, мифологемалар урын ала. Хәтта тарихи прототиплары булган эпик геройларның шәҗәрәсе дә илаһи зат яки идеаллаштырылган хөкемдардан башлана. Эпик геройның ата-бабалары турында да легендар характерда информация бирелә. Мәсәлән, Идегәй турындагы дастаннарда Идегәйнең шәҗәрәсе изге Баба Төкләскә барып тоташа. Икенче

яктан анасы Пәри кызы булу да Идегәйнең гадәти булмавын исбатлый.

Татар дастаннары арасында эпос жанры формалашуның һәм үсешенең бөтен этапларыннан мисалга китерерлек әсәрләр саклана. Атап әйткәндә, иң борынгы чорга яки төргә караган әкияти-мифологик дастаннар да («Йиртөшлек», «Түләк»), архаик яки героик классик эпос та («Ак Күбәк»), тарихи эпос та («Гайсә улы Амәт», «Идегәй») һәм романик, ягъни мәхәббәт дастаннары да («Кузы-Күрпәч белән Баян-Сылу») бар. Себер татарларының «Әйтүкә җырлары»н исә ахырга кадәр формалашып бетмәгән романик дастан үрнәге дип карарга мөмкин.

Феодализм дәверендә эпосларның бер өлеше романик төсмер ала, ягъни, героика кимеп, көнкүреш һәм мәхәббәт темасын тасвирлау беренче планга чыга. Романик характердагы мәхәббәт дастаннарында егетнең өйләнергә читтән кыз яки үзенә аталган кәләшен эзләп юлга чыгуы, һәм төрле каршылыклар, авырлыклар белән бәйләнгән никах сынавы үтүе һәм күпчелек очракта гашыйклар язмышының фаҗигалы финал белән тәмамлануы тасвирлана. «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны – моның ачык мисалы.

Дастаннарда халыкның узган тормышын, атап әйткәндә, материаль культурасының аерым якларын, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, башка халыклар белән бәйләнешләрне, этник гореф-гадәтләрне, йола-ышануларны өйрәнү өчен кыйммәтле материал саклана. Аларда халык тормышының төрле этаплары белән бәйле мәгълүматлар, башка чыганакларда сакланмаган әһәмиятле һәм кызыклы тарихи детальләр теркәлгән. Дастаннарда гаилә-көнкүреш, хуҗалык итү белән бәйле йола, гореф-гадәтләр, ышанулар турында да материал табарга мөмкин. Бигрәк тә туй-никах, бала туу, аңа исем кушу, күмү йолалары буенча мәгълүматлар шактый.

Себер татарларының дастаннарын җыю һәм өйрәнү тарихы XIX йөздә академик В.В. Радлов исеме белән башланып

китә. Атаклы тюрколог, этнограф, археолог 150 дән артык фәнни хезмәтләр авторы Вильгельм Фридрих Радлофф 1837 елда Берлинда туа. Берлин университетының философия факультетында укыганда Шәрык телләре белән кызыксына башлый. Фәлсәфә буенча диссертация яклаганнан соң, Урал һәм Алтай телләрен өйрәнү максатында, 1958 елда Россиягә килә. Бераздан Барнаул тау училищесына немец һәм латин телләре укытучысы итеп билгеләнә. 1959 елда Россиягә тугрылык турында ант эчә. Һәм шул көннән Василий Васильевич Радлов исемен ала. Барнаулда эшләү дәверендә җирле төрки халыкларның телләрен һәм фольклор әсәрләрен өйрәнергә керешә. Шул ук максат белән галим 1960 елның җәеннән башлап һәр ел төрки халыклар яшәгән өлкәләргә экспедицияләргә чыга. Алтайда эшләгән дәверендә барлыгы 10 экспедициядә булып, алтай, телеут, шор, коман, тува, казакъ, кыргыз, абакан татарлары (хакаслар), себер татарлары һәм кытайларның фольклорын һәм тел үзенчәлекләрен чагылдырган материаллар туплый. 1866 елдан үзенең халыктан язып алган материалларын бастыра башлый. 1866–1870 елларда «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи» дигән унтомлыкның беренче өч томы дөнья күрә. 1872 елда татар фольклоры өчен хәзерге көнгә кадәр иң әһәмиятле чыганакларның берсе булган дүртенче том – «Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар» җыентыгы басылып чыга. Бу күптомлык үзләрендә тупланган материалның күләме белән дә, фәнни һәм гамәли яктан да тиңдәшсез хезмәт була. Дүртенче томда себер татарларыннан унтугыз авылда җыелган йөз унбер әсәр урнаштырылган. Алар арасында дастаннар, әкиятләр, җырлар, риваятьләр бар. «Ак Күбәк», «Мешәк Алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш Мәргән» кебек дастаннар нәкъ шушы томга кергән булу аркасында гына безнең көнгә кадәр сакланып калганнар.

Бу хезмәт – татар халык авыз иҗатын тикшерүчеләр өчен дә, укучы өчен дә кыйммәтле хәзинә. Томга язылган кереш сүздә себер татарлары турында белешмә һәм китапта урын алган материалларның ни рәвешле җыелуы турында мәгълүмат бирелә. Шунда ук В.В. Радлов себер татарларының фольклорын җыюның катлаулы эш булуы турында да язып калдырган: «Халык риваятьләре – ата-бабаларның гамәлләре турында мәгълүмат саклаган әкиятләр, җырлар яшисен яшәгән картлар күңелендә генә сакланып калган. Бары алар гына үзләренең яшь вакытлары – халык рухы ата-бабаларның батырлыкларын мактаган җыр һәм әкиятләрне башкарырга көч биргән вакыт турында изге хатирәләр саклыйлар. Хәзерге буын, күбесенең эчтәлекләре аңлашылып җитмәсә дә, «Мөхәммәдия»не, Әхмәт Ясәви хикмәтләрен, Мир Али Ширне җырлыйлар.

Югарыда әйтелгәннәрдән халык әдәбияты үрнәкләрен җыюның никадәр зур хезмәт таләп итүе аңлашыла. Муллалар авыл халкына еш кына минем үтенечләрне үтәмәскә киңәш итәләр иде, һәм мин картлардан берәрсен таба алган очракта да, аларның яшьләре белән бәйле җитешсезлекләре һәм күп сөйләшүләре язып алу эшен катлауландыра иде. Шул рәвешле, мин нәрсә ишетсәм шуны, җыр һәм риваятьләрнең иң әһәмиятсез өзекләрен дә язып барырга мәҗбүр булдым» .

XIX йөз башында татар дастаннары турында беренче фикерләр күренә башлый. Авторлар әлеге жанр үрнәкләрен дастан дип атамасалар да, «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек әсәрләрнең тәрбияви һәм эстетик әһәмиятен күрсәтеп, аларга югары бәя бирәләр. Г. Тукай «Таһир-Зөһрә», «Йосыф» китаплары турында, «кечкенә чагында укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер» дип яза.

XX гасырның егерменче елларында дастаннарга нигезләнеп язылган әдәби әсәрләр дөнья күрә. 1916 елда Ф. Бурнаш «Коркот» поэмасын яза, «Таһир-Зөһрә» трагедиясен иҗат итә. Шул ук елда «Аң» журналында Мирхәйдәр Фәйзи тарафын-

нан әдәби эшкәртелгән «Җик Мәргән» дастаны басылып чыга. К. Юлдаш укучыларга «Чура батыр» дастанын тәкъдим итә. Казан педагогия институты доценты Нигъмәт Хәким 1919 елда Себердә Ситдыйк Зәйнетдиновтан язып алып, «Идегәй дастанының әдәби эшкәртелгән вариантын төзи.

1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачыла. Әлеге институтта башта фольклорны өйрәнүче төркем оеша, соңрак ул фольклор секторына әйләнә. 40 елдан татар фольклорын системалы рәвештә өйрәнү, даими рәвештә фәнни экспедицияләргә чыгу башланып китә. 1940 елда Хәмит Ярми җитәкчелегендә В.В. Радлов эзләре буйлап оештырылган экспедиция вакытында күпсанлы фольклор материалы туплана. Җыелган әсәрләр арасында «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанының бер варианты да бар.

XX гасырның 80 нче елларыннан башлап татар эпосына мөнәсәбәтле эшчәнлек институтта ике юнәлештә алып барыла. Бу – беренчедән, эпос үрнәкләрен фәнни яктан тикшерү, анализлау, икенче яктан, татар халык дастаннарын аерым җыентыклар итеп бастырып чыгару. Әлеге жанрны өйрәнү эше ике зур галимнең эшчәнлеге белән бәйле. Ф.И. Урманчеев үзенең тикшеренүләрендә эпик мирасыбызны, дастаннарыбызны төрки эпосның аерылгысыз бер өлеше буларак карый. Галимнең татар эпосына багышланган зур фәнни хезмәте 1984 елда дөнья күрә. Шул ук елны Ф. Әхмәтова татар халык дастаннарын җыйнап, аерым том әзерләп бастыра. Ф.В. Әхмәтованың дастаннарыбызның бүгенге торышын яктырткан, аларны башка төрки халыклар эпосы белән чагыштырган фәнни мәкаләләре дә бар.

Бу хезмәтләр әлеге ике шәхеснең дистә еллар алып барган фәнни тикшеренүләренең, эзләнүләренең бер зур нәтиҗәсе булып тора. Бу урында, олуг фольклорчы галимнәр – Хәмит Ярми, Фатих Урманчеев һәм Флора Әхмәтованың Себер тумалары булуын әйтеп узу урынлы булыр.

Хәзерге вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре татар дастаннарын фәнни яктан өйрәнү, аларны халыкка чыгару буенча зур эшчәнлек алып баралар. И.Г. Закированың «Болгар чоры халык иҗаты» (2001), «Эпическое творчество периода Золотой Орды (2011) монографияләрендә «Алпамыш», «Түләк», «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу». «Идегәй», «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгына кергән дастаннар анализлана. Л.Х. Мөхәммәтҗанованың беренче монографиясе татар халкының «Чура батыр» дастанын башка төрки версияләр белән чагыштырма планда тикшерүгә багышланса, «Татарский эпос. Книжные дастаны» (2004) һәм «Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары» (2018) китапларында татар халкының китаби дастаннар традициясе өйрәнелә.

Дастаннарга 25 томлык «Татар халык иҗаты» академик җыентыгында ике том – «Китаби дастаннар» (төзүчесе Л.Х. Мөхәммәтҗанова) һәм «Дастаннар» (төзүчесе И.Г. Закирова) багышлана.

Бу китапта дастан текстлары үзләренең көйле өлешләре, ноталары белән тәкъдим ителә. Китапта татар халкының иң популяр мәхәббәт дастаннары – «Таһир-Зөһрә», әлеге дастанның Себер варианты «Таһир менән Сәүрә», «Бүз егет», «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу», «Сәйфелмөлек» дастаннары тәкъдим ителә.

*И. Закирова*

## Кузы Көрпәч

Борын-борын заманда Ак хан белән Кара хан булган иде. Көннәрнең бер көнендә Ак хан белән Кара хан урманга күчеп киткәннәр иде. Ак хан да сиксән кеше алган, Кара хан да сиксән кеше алган. Киткән чакта бичәләре айлы-көнле калганнар. Киткәли йөргәндә сөйләшкәннәр: «Әгәр дә ул булса, Кузы Көрпәч дип исем бирербез, ә кыз булса, Баянсылу дип исем бирербез», – дигәннәр. Бер көнне Ак хан белән Кара хан кайтмакчы булганнар. Бер айлык юлны бер көнне киткәннәр, ике айлык юлны ике көн киткәннәр. Юлда кайтып барганда бер таз кол әйткән: «Әй, Ак хан, улың бар, ә Кара ханның кызы бар», – дип.

Ак хан «Улым бар!» дип куанып чапканда, ат өстеннән егылып төшеп, муены сынып үлгән. Кара хан, Ак ханны юлда күмеп, кайгы-хәсрәт белән йөз алтмыш кешене ияртеп, өйгә кайтып кергән. Өйгә килсә, Ак ханның улы, Кара ханның кызы булган. Ак ханның улына Кузы Көрпәч, дип исем кушканнар, ә Кара ханның кызына Баянсылу дип исем кушканнар. Ак ханның улы Кузы Көрпәч бер кунып, бер яше яшәгән[1]. Кара ханның кызы да алай яшәгән.

Кузы Көрпәчкә сигез-тугыз яше вакыт чамасында ягы[2] атыша башлаган. Унике яше тулгач, атасының ягысын алып, су ягасына[3] төшкән. Караса, су ягасында бер бичә ак көнәк[4] белән су чыгарып утыра. Кузы Көрпәч әйткән: «Ә, көнәгеңә ягы белән атаем!» – дип. Бу сылу хатын әйтә: «Ай, пышың курыгыр[5]! Минем көнәгимә атканчы, әртә[6] киткән бичәңне истәп[7] китәр

---

[1] Бер яшькә җиткән.

[2] Ягы – ук.

[3] Ягасы – кырые.

[4] Көнәк – чиләк.

[5] Пышың курыгыр – башың корыгыры.

[6] Әртә – иртә.

[7] Истәп – эзләп.

иден!» – диде. Кузы Көрпәч су йагасыннан килеп, инәсеннән сораган: «Инәм, минем әртә киткән бичәм бармы?» – дип.

Инәсе әйтте: «Ә, балам, синең әртә киткән бичәң юк», – дип. Ул көнне таз колның балалары ашык уйнагалы чыккан. Кузы Көрпәчкә унике яшь, ә таз колның балаларына егерме яше артык булган. Аларны күреп, Кузы Көрпәч тә чыккан, Кузы Көрпәч ашыгы пүтүнләп[1] үтеп киткән. Икенче көнне тагы таз колның балалары ашык уйнаганнар. Таз колның балалары мыскыл иткәннәр: «Безнең ашыкларны тотып алганчы, әртә киткән бичәңне истәп[2] китәр иден!» – диделәр.

Әртә киткән бичәсе Кара ханның кызы Баянсылу булган. Бу туган вакытта Ак ханның бичәсе Баянсылуга соргалаштырып[3] куйган булган.

Ак ханның улына өч яше тулганнан соң, инәсе Кара ханның бичәсен кызы белән кунакка чакырган. Кара ханның бичәсе кызы белән килеп, өйгә индеме[4] Кузы Көрпәчкә: «Кызымны бу балага бирмәм!» – дип әйткән дә кайтып киткән.

Үзенең өенә килгәннән соң, Кара ханның бичәсе: «Кызыбызны алып китәек Кара дәрьяның ягына[5]! Шул балага бирмик», – дигән. Аннан соң Кара хан кызы Баянсылуны Кара дәрья ягына алып киткән. Моны әйткәннәр: «Әртә киткән», – дип.

Йә, кире таз кол балаларына кайтаек! Таз кол балалары Кузы Көрпәчкә диде: «Син инәңнән кауырмач куйырт! Кауырмачны кашык белән дә алма, кыйгач белән дә алма, табасыннан ал!» – дип. Аннан соң таз кол балалары әйткән: «Кашык белән бирсә, әйт: кашык йулы карсак[6], дип әйт», – дигән. – «Кыйгач[7]

---

[1] Пүтүнләп – бөтенләй.

[2] Истәп – эзләп.

[3] Соргаштырып – ярәшеп, сөйләшеп.

[4] Индеме – кердеме.

[5] Ягы, яга – яр, елга яры.

[6] Карсак – түбән, кыска.

[7] Кыйгач – аш чүмече.

белән бирсә, әйт: кыйгач юлы кыйшык, дип әйт!» – дигәннәр. – «Табач[1] белән алып бирсә, ул вакытта эссе кауырмачны табачына кысып, табачын көйдер!» – дип. Аннан: «Анда инәң әртә киткән бичәңне әйтер», – дигәннәр.

Кузы Көрпәч кайтып, инәсеннән кауырмач кауырткалы әйткән: «Ашагалдым[2], башка аш кирәкмәс», дигән.

Инәсе кауырмач кауырган уә Кузы Көрпәчкә кашык белән эссе кауырмач биргән. Кузы Көрпәч алган юк: «Кашык йулы карсак», – дигән. Кыйгач белән биргән, «кыйгач юлы кыйшык», – дип, аны да алган юк. Аннан кулы белән биргәндә, инәсенең кулын кысканда әйткән: «Әйт, – минем әртә киткән бичәм кайда? Бармы?» – дип. Инәсе әйткән: «Юк». Аннан инәсе әйткән: «Әйтсәм, әйтим! Әртә киткән бичәң – Кара ханның кызы Баянсылу, ул Кара дәрьяның йагына киткән, хәзер аны истәсәң дә тапмассың», – дигән.

Кузы Көрпәч әйткән: «Мин истәп киткәлдим, миңа рөхсәт бир», – дип. Кузы Көрпәчкә хәзер унҗиде яшь булган, ди. Инәсе җибәрмәдеме, Кузы Көрпәч әйтте: «Мин китәем!» – дип. Кузы Көрпәч атасыннан калган акбүз атын, кылычын алды. Инәси сыгыт сыктады[3], әйтте: «Мин ятып төш күрәем! Аннан соң әйтирим!» – диде.

Инәсе ятып бер төш күрә башлаганда, улы уятты: «Тор, тор, инәм!» – дип. Инәсе торгач, бәет әйтте:

Имәннән таяк бөгәрбез, балам,
Илдән илгә йөрербез, балам.
Илдә бер матур тапсак,
Атын Баян куярбыз, балам!

---

[1] Табач – уч.
[2] Ашагалдым – ачыктым.
[3] Сыгыт сыктады – елау елады.

Кузы Көрпәч әйтте:

Каеннан таяк бөгәрбез, инәм,
Илдән илгә йөрербез, инәм.
Илдә бер матур тапсак,
Аты Баян булса да, үзе дә
Баян булмас, кой, инәм!

Инәсе аннан әйтте: «Әй, балам, рөхсәтем юк, утыр, балам, күкрәгемнең сөтен саваем. Әгәр сөте авызыңа җитсә, ол вакытта китәрсең».

Инәсе түрдән утырып, сауган сөте Кузы Көрпәчкә җитмәгән, чөнки инәсе сөтен атып кына җибәргән. Аннан инәсе әйткән: «Миннән рөхсәт юк», – дип. Кузы Көрпәч әзерләнгән дә әзерләнгән, аннан соң рөхсәт сораган: «Инәм, рөхсәт ит, мин китәем!»

Инәсе әйткән: «Хәзергә рөхсәт юк, мин тагы ятып төш күрәем!» – дигән. Инәсе төш күргәле яткан. Бер-ике сәгатьтән соң Кузы Көрпәч тагы уятты: «Мин китәем, инәм!» – диде. Инәсе торып әйткән: «Әй, балам, төшемне төш итмәдең, рөхсәт юк», – диде.

Инәсе торганнан соң: «Балам, утыр, мин тагын түрдән утырып сөтем саваем! Әгәр күкрәгем сөте авызыңа җитсә, китәрсең», – дигән.

Аннан Кузы Көрпәч утырган. Инәсе урындыктан күкрәген сауган, сөте якынлап киткән.

Аннан соң инәсе бәет әйтте:

Әйләнеп чыкмас, ай, диңгез балам,
Аныклап ничек күчәрсең, балам?
Тычкан үтмәс чатырман, балам,
Аныклап ничек кичәрсең, балам?

Кузы Көрпәч җавап бирде:

Әйләнеп чыкмас, әй, диңгез, инәм,
Камчым салып чыгармын, инәм,

Тычкан үтмәс чытырман, инәм,
Камчым салып чыгармын, инәм.

Аннан соң да инәсе рөхсәт бирмәде. Кузы Көрпәч аш ашамаен, су эчмәен йүтип[1] калды. Инәсе тагы төш күргәли ятты. Кузы Көрпәч тагы тиз генә уятты: «Инәм, рөхсәт бир!» – диде.

Инәсе тагы: «Әй, балам, ятырга бирмәдең, төшемне төш итмәдең. Утыр, балам, тагы сөтемне савыйм», – дип әйтте. Аннан сөтен сауды, янә авызына кермәде. Аннан инәсе әйтте: «Әй, балам, рөхсәт юк, тагы бер ел тормагың бар», – дип. Ә Кузы Көрпәч бөтенләй әзерләнеп куйган булган. Акбүз атка атланып, атасы Ак ханнан калган кылычын, угын, камчысын, мылтыгын алып чабып китте. Ә инәсе, күкрәген чыгарып, чәчен йолкып сыктап калган. Инәсе карганып әйткән: «Барган юлың бар булсын, кайткан юлың юк булсын!» – дигән. Кузы Көрпәч ул аяктан ул китте, бу аяктан бу китте[2].

Бер урманга килеп, бер киекне үтереп тә пешереп ашады. Аннан әйләнеп чыкмас ай-диңгезгә килде. Кузы Көрпәч бу диңгезнең өстенә камчысын салганда су бүленеп китте. Тычкан үтмәс чытырманга кылычын салып чыгып киткән. Аннан соң тагы ул аяктан ул китте, бу аяктан бу китте. Аннан соң кырык бүрегә очрады. Кырык бүрене ук белән аткалы көсләтсә[3]: «Инәң минмен», – дип аттырмады. Аннан бер аюга очрады. Аю да: «Атма, балам, инәң минмен», – дип аттырмады.

Аннан Кузы Көрпәч инәсенә: «Инәм, рөхсәт бир!» Инәсе рөхсәт бирмәде. Кузы Көрпәч тагы табып чыгып киткән. Инәсе тагы карганып утырып калган: «Барган юлың бар булсын, кайткан юлың юк булсын!» – дип.

---

[1] Йүтип – йотып. Ашамый, эчми, йотып калды. Чарасызлыктан килешү.

[2] Ул аяктан ул китте, бу аяктан бу китте – Себер татарлары фольклорында очрый торган әйтем.

[3] Көсләтсә – төзәү, төбәү.

Алай та иттем, тыңламадың, балам,
Болай та иттем, тыңламадың, балам.
Китәртәй йулың, пулсын, балам,
Кайтыртай йулың пулмасың, балам.

Кузы Көрпәч ул аяктан ул китте, бу аяктан бу китте.

Бер заманда Кузы Көрпәч ике тау арасына килде. Анда бер таз колга килеп җитте дә сәлам бирде. Кол: «Балам, синең күзең утлы, буең саллы. Балам, син кайсы илләрдән, кайсы җирләрдән килдең?» – дип сорады. Кузы Көрпәч: «И таз кол, Кара ханның халыгын, аның кызы Баянсылуны эзләп килеп утырам», – дип әйтте.

Дөя багучы кол дөя суеп ашатты. Кузы Көрпәч ашаган вакытта олы сөяге авызыннан, кече сөяге борыныннан чыкты. Кол әйтте: «Моннан барырсың елкычы колга, аннан сорарсың», – диде. Аннан тагы Кузы Көрпәч ул аяктан ул китте, бу аяктан бу китте, барды елкычы колга.

Елкычы кол әйтте: «Балам, син кайдан килгән баламсың?» Кузы Көрпәч: «Мин Кара ханның кызы Баянсылуны истәп килдем», – дип әйтте. Бу елкычы кол әйтте: «Без Кара ханның халкыбыз, безне Кара хан безнең җиребездән аерып китергән. Моннан ары сыерчы колга барсаң, аннан сорарсың», – дип әйтте.

Кузы Көрпәч, акбүз атка атланып, сыерчы колга китте, барып сәлам бирде. Сыерчы кол: «Кайдан йөргән баласың?» – диде. Кузы Көрпәч: «Мин Кара хан кызы Баянсылуны истәп килдем. Ул еракмы?» – диде. Сыерчы карт әйтте: «И Кара ханның халыгын истәп килсәң, моннан ары куйчы колга барырсың, анда Баянсылуның куйлары бар», – диде.

Аннан куйчы колга китте. Куйчы колга барганнан соң, сәлам биргәч, куйчы кол сорады: «Кайдан йөргән баласың?» – диде. Кузы Көрпәч әйтте: «Мин Баянсылуны истәп килдем», – диде. Куйчы кол әйтте: «Бу Баянсылуның куйлары», – диде. Кузы

Көрпәч «Тукта, маңгаенды цәргәй[1] кунып утыра, мин аны үтерәем!» – дип чирткән. Әлеге таз кол анда үлгән. Киемен чиштереп алып, үзе киеп, таз колны, тирән казып, тәпә күмеп[2] калдырды.

Киемене киеп, үзе куй багып, Баянсылуның малын ябып, таз кол булып, Баянсылуның ашханәсенә инеп утырды. Аның инеп утырганда, Баянсылу әйткән: «Бу таз колга нәмә булган? Сыер сава торган вакыт түгелмени?» – дип.

Кузы Көрпәч, көнәк алып, сыер саугалы чыгып киткән. Кузы Көрпәч син саугалы утырганда теге сыерның да, бу сыерның да цоцыгын[3] өзгәләп, кире ашханәгә инеп утырды.

Баянсылу тагы: «Бу таз колга нә булган? Бозау эчерә торган вакыт түгелмени?» – дип кайгырды. Кузы Көрпәч, су алып чыгып, бозау алдына көнәк[4] куйды. Бозаулар эчмәде. Инде Баянсылу әйтте: «Эч, бозавым, эч, дигәндә эчдигән түгелмени?» – дип. Кузы Көрпәч, аннан соң алып, бозауларны эчерде. Бозауларны эчереп бетергәннән соң, әлеге ашханәгә инеп утырды.

Бер көнне тыңлап утырса, Баянсылуны Кара Көккәлнең улына биреп, туй ясагалы йөргәннәр болар. Аннан Кузы Көрпәч бер ап-ак куй баласын тотып, үзенең алтын йөзеген куй баласының колагына киертте. Баянсылу кырык кысагы[5] белән үзенең сараенда утырды. Кузы Көрпәч өйрәтте әлеге ак күзәгә[6] мондый бәет әйтергә:

Сөенче, Баян, сөенче, Баян!
Сөенчеләрең миндәдер, Баян!

---

[1] Цәргәй – чебен.

[2] Тирән казып, тәпә күмеп – мәетне җирләүне аңлаткан, курган ясап күмүнең эзләрен саклый торган гыйбәрә.

[3] Цоцыгын – сосок, имчәк башы.

[4] Көнәк – чиләк.

[5] Кысак – дус кыз.

[6] Күзә – кузы, сарык бәрәне.

Әлеге ак күзә Баянсылуның сараенда, Баянсылуның алдына килеп, тып-тып сикерде. Бу сарайда кызлар белән бергә Баянсылуның җиңгәсе: «Бу куй баласына нәрсә булган?» – дип, кайчы белән атты, әлеге ак куй баласы колагындагы алтын йөзек төшеп китте. Бу йөзектә Кузы Көрпәчнең аты булган. Баянсылу бу йөзекне күрмәде дә, белмәде дә. Бу йөзекне җиңгәсе алып, кесәсенә салып куйды. Әлеге җиңгәсе бу йөзекне Баянсылуның агасына күрсәтте дә әйтте: «Ул Кузы Көрпәчне үтерергә кирәк», – дип әйтә.

Аннан ит пешергәннәр, туй башларга дип. Кузы Көрпәч, таз кол булып, өйдәге пычакларны җыеп ташлаган. Пычакларны ташлаганнан соң, Кузы Көрпәч, таз кол булып инеп, Баянсылуга үзенең пәкесен бирде: «Мә, минем пычагым», – диде. Баянсылу пәкене алып күрсә, пәке сабында Кузы Көрпәчнең исеме язылган булды. Баянсылу Кара Күккелнең улына бармады. Аннан үзенең сараенда кырык кысакка әйтте: «Кузы Көрпәч килгән бит, ничек тә булса куй багучы таз колны китерегез! Мин Кара Күккелнең улына бармам! Мин төшемдә Кузы Көрпәчне күреп йөргәнем, аңа бармакмын! Кузы Көрпәчне китерең!» – дигән.

Аннан әлеге таз колны алып килгәннәр. Ул Кузы Көрпәч булган. Аны Баянсылу каршы отырлап[1] алган. (Ә Кара хан бу турыда бер нәмәне белгән юк.) Аннан соң Кузы Көрпәчне бер аулак бүлмәгә индергән. Анда сөйләшеп кундылар. Бу бүлмәгә шәм яктысы кирәкмәс булган. Кузы Көрпәчнең чәчендәге алтын мунцак[2] кояш кебек яктырткан:

Аранда сыер мөңридер, Баян,
Көн таң атканга охшыйдыр, Баян!

---

[1] Отырлап – каршылап.
[2] Мунцак – муенса.

Баянсылу каршы әйтте:

Аранда сыер мөңридер, Кузый,
Ач пәриләргә аш булсын, Кузый!

Кузы Көрпәч тагы:

Аранда куйлар мөңридер, Баян!
Көн таң атканнарга охшыйдыр!

Кояш югары күтәрелгәч, Баянсылу Кузы Көрпәчне сандыкка япкан. Япкан вакытта Кузы Көрпәчнең бер толым чәче алтын гәүһәр мәрҗән белән тышта калган. Баянсылуның бүлмәсенә җиңгәсе керсә, сандыктан толым чыгып калганын күрде дә чәчен кисеп алды. Әлеге җиңгәсе чәчне Баянсылуның агасына илтеп бирде.

Баянсылуның агалары, җыелышып, Кара хан белән сөйләшәләр. Кара хан кушты: «Арацан-карацан[1] пешерегез». Аннан тур уртасында ора[2] казытты. Бу ораның өстенә ак киез түшәтте. Аннан кич була, Кара Көккәлнең туен башладылар. Әүвәл Кузы Көрпәчне чакырдылар, аннан бөтен халыгын чакыралар да түрнең цүрә[3] ягында утырталар. Ә Баянсылу Кузы Көрпәчне өйрәтеп җибәргән: «Түр уртасындагы ак киезгә утырма! Кияүнең урыны тәкцәккә[4] утыр!» – дип әйтеп өйрәткән.

Кузы Көрпәчне орага егар өчен, Баянсылуның бер агасы барып чакырды: «Кияү сине чакырды», – диде. Баянсылу тагын өйрәтеп җибәрде: «Арацан-карацан бирсә, «үземнең өлешем» дип эчмә, ә «минем өлеш» дип эч», – диде.

Аннан Кузы Көрпәч килде, Кара хан, аның халкы, яхшы итеп отырлап алдылар. Кузы Көрпәчкә түргә утыргалы әйттеләр.

---

[1] Арацан-карацан – сөттән куылган эчемлек.

[2] Ора, оро – кое.

[3] Цүрә, чүрә – сул

[4] Тәкцәк – өй почмагы.

Ә Кузы Көрпәч «Кияүнең урыны тәкцәк», дип, тегесен тегендә, монысын монда төртеп чәчеп, тәкцәккә утырды. Аннан, арацан-карацан китереп, иң әүвәл Кузы Көрпәчкә бирделәр, Кузы Көрпәч: «Баянсылуның өлеше», – дип эчеп куйды.

Аяк[1] икенчесен әйләнеп килде, ә Кузы Көрпәч эчмәде, «үземнең өлешем» дип, «эч!» дип, эчәргәле әйттеләр. Сукмакчы булганнар, ә Кузы Көрпәч курыкмады. Аннан соң тагы: «Инәмнең өлеше», дип эчеп куйды. Аннан өченче аяк килгәндә: «Йа, көннәрем булсын, үземнең өлешем!» дип эчеп куйган.

Арацан-карацан эчеп утырганда Баянсылу сиксән атның иярләренең канцыгасын[2] кисеп куйган, Кузы Көрпәч өчен акбүз атның иярен калдырган. Кузы Көрпәч полгылап[3] җырлый башлаганда, Баянсылу Кузы Көрпәчнең битенә кулъяулык ташлады.

Кузы Көрпәч тиз генә чыкты да акбүз атка чабып чыгып китте, ә Баянсылу акбүз атны тышта тотып саклаган. Ханның халкы чыгып: «Кузы Көрпәчне тотыгыз, тотыгыз!» – дип кыйгылашып[4] калды. Бу сиксән ат Кузы Көрпәчне ялангач[5] алып барып үтерер өчен әзерләнгән булган. Ханның кешеләре чыгыпчыгып атка атланган да аттан баш табан егылып калган. Кузы Көрпәч чабып утырса, тимер күпердә бер бала: «Ай, егет, тезеңә ук ата куям!» – диде.

Кузы Көрпәч: «Йа, ук белән атканга нәмә булмак?» – диде дә аттыра куйды. Ә ук тезеннән ерып китте. Аннан Кузы Көрпәч бер як пойдир[6] төбендә ятты, ул аякка баса алмады. Аннан башка як пойдирнең өстенә кечкенә кошчык кунды. Бу кошның канатына бер хат язып бәйләп, Баянсылуга кайда ятканын белдерде.

[1] Аяк – чынаяк, кәсә.

[2] Канцыгасы – иярне беркетә торган бау яки каеш.

[3] Полгылап – кизәнеп, болганып.

[4] Кыйгылашу, кыйгулашу – кычкырышу, талашу.

[5] Ялангач бу очракта: коралсыз килеш.

[6] Пойдир, пой, бой – су буе, яр.

Бу кош Баянсылуга хатны китерде. Баянсылу бу хатны огыды[1] да, Кузы Көрпәчкә хат язып, бер бавырсак җибәрде. Баянсылу икенче көнне янә канатның астына алтын җеп белән бавырсак бәйләп, Кузы Көрпәч өчен бер бүз тургайны җибәрде.

Көннәрнең бер көнендә җиңгәсе белән Баянсылуга: «Әйдә! Өс киемнәребезне алыштыраек!» – диде. Аннан киемнәрен алыштырдылар. Әлеге кошчык, Баянсылу дип уйлап, җиңгәсенең кулына инеп утырды. Аннан әлеге җиңгә бу кошны кысып тотып болгады: «Әйт, Кузы Көрпәч кайда!» – дип.

Ә кош әйткән юк. Аннан соң Баянсылуның агалары тармачы[2] эзләп, шәһәргә киттеләр. Шәһәрдә бу тармачы әйтте: «Ул кошны мичкә ташлаң, мич эчендә “чук” дип үлсә, ул Кузы Көрпәчнең як пойдирнең төбендә булырсыз[3]», – дип. Аннан Кузы Көрпәчне үтерер өчен Кара ханның бөтен халкы ат-ияр менеп киткәннәр. Баянсылу, сарай тышына чыгып, чардакка менде дә, аларга зар әйтте:

Сыер менгән сыерланган яр-яр!
Тай менгән тайланган яр-яр!
Инде туган кызыңның аягын чапкан биядәй
Кара Көккәлнең улына бирерсең, –
Кычкырган торнадай, –

дип, атасына әйткән дә, үзе Кузы Көрпәчне эзләп киткән.

Кара ханның сиксән кешесе Кузы Көрпәчне үтерергә иткәннәр, үтерә алмыйча, кыйнап бетергәннәр. Аннан ул кыйнадылар, бу кыйнадылар. Аларның кыйнавына түзалмыйча Кузы Көрпәч әйткән: «Болай минем җанымны ала алмассыз, минем табан астында үз кылычым бар, аны алып пау аслаң[4]!» – дигән.

---

[1] Огыды – аңлады, ишетте.
[2] Тармацы – багучы.
[3] Булырсыз – табарсыз.
[4] Пау аслау, бауслау – бугазлау, сую.

Аннан Кузы Көрпәчне үзенең кылычы белән үтергәннәр. Кара ханның халкы Кузы Көрпәчне үтереп кайткач, Кара хан куанычына хәбәр кешесенә байлык биргән. Кара хан Баянсылуны куаныч белән Кара Көккәлнең улына яңадан туй ясагалы йөргәндә, Баянсылу, аның кысагыннан һәммәсенә өч йөз акча биреп, энҗе-мәрҗән алып, кырык кысагын алып, Кузы Көрпәчкә китте. Ә кызларына әйтте: «Йөрегез, кызлар, йөрегез!»– дип алып чыгып китте. Китеп барганда бәет әйткән:

Йөрегез, йөрегез, кызлар,
Йөрешәек, кызлар,
Мәрвәр-мәрҗән
Тәришәек[1], кызлар! –

дип, мәрвәр-мәрҗәнне уңга-сулга чәчә барган, ә кызлар бу мәрвәр-мәрҗәнне тәришип, юлда кала барганнар. Баянсылу бара-бара, кызларын алдап, юлда мәрвәр-мәрҗәнне җыйдырып, ялгыз үзе калган.

Берүзе барып, Кузы Көрпәчнең янында моңланып, Кузы Көрпәчнең кесәсеннән алтын саплы пәкесен алып, очлы ягы белән үзенең йөрәгенә сайып[2], Кузы Көрпәчне кочаклап, Баянсылу анда үлде. Үлгәннән соң, кырык кысагы артыннан куып килеп җиттеләр.

Кара Көккәлнең улы, Баянсылуны куып барып, әлеге алтын саплы пәкене алды, очлы ягы белән үзене сайып, Баянсылуны кочаклап, ул да анда үлде.

Баянсылуның атасы-инәсе белеп, куып килеп керделәр. Аннан Кара хан халыгына боерды сарай эшләтергә. Баянсылуны бу сарайга күмделәр. Сарайның ай ягы – алтын, көн ягы көмеш булган. Ә Кузы Көрпәчкә елганың икенче ягында андый ук сарай эшләделәр. Кузы Көрпәч өстенә һәм Баянсылу өстенә чык-

---

[1] Тәришәек, тәришип, тиру – чүпләп җыю, чәчелгән әйберне җыеп алу.
[2] Сайып – чәнчеп (пычак).

кан агачлар икесе су аша кушылып куйган, ә Кара Көккәлнең улының өстенә тигәнәк чыгып, икесенең аергалы үсеп утырды.

Ул суның эчендә ап-ак ике үрдәк көн-таң атканчы кушылгалы итеп, кушыла алмыйлар, көн-таң атып китәдер, аларга бер яман кош, кушылгалы бирмичә, аерып ташлыйдыр. Болар хәзер дә ул суда яшәйделәр.

*1950 елда Новосибирск өлкәсе Бараба районы Тамдау авылында Сәлим Батыр улы Урусовтан (1875 елда туган) төрки телләр галиме Л.В. Дмитриева тарафыннан язып алынган.*

*Дмитриева Л.В. Язык барабинских татар.*
*Л., 1981. – С. 32–40.*

## «Кузы-Күрпәч һәм Баян Сылу» дастаныннан назым

### *Әнисе җыры*




Әнисе:

Алай та иттем, тыңламадың, палам,  
Болай та иттем, тыңламадың, палам.  
Китәртәй йулың, пулсын, палам,  
Кайтыртай йулың пулмасың, палам.

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Мусина Фатыймадан (1900 елгы) һәм Рәфикова Хәбибҗамалдан (1899 елгы) Илгиз Кадыйров тарафыннан язып алынган һәм нотага төшерелгән.*

## Кузы Көрпеч

Борынгы заманда ике хан булды. Берсе Ак хан, берсе Кара хан булды. Аларның икесенең хатыннары корсаклы булды. Икесе мәслихәт кылдылар Кара хан белән Ак хан: «Безнең ике хатыныбыз корсаклы булды, дөньяга туса, берсе кыз, берсе ул булса, алыштырырбыз»*.

Ике хан ак киек[1] көтәргә киттеләр. Аулап бардылар, Киек үтерделәр. Аннан кайттылар.

Анда, йортка җитсә, хатыннары балаларын тапканнар. Бер баласы Ак ханның ул булды, бер баласы Кара ханның кыз булды.

Төздән[2] йортка кайтып җиттеләр. Ак ханның аты егылып төште, иясе Ак хан муены сынып калды. Ак ханның хатыны сыгыт[3] булды, кайгырды. Кара ханның халкы мәлис[4] булды, сөенде, туй ясады. Ак ханның улын Кузы Көрпеч дип, Кара ханның кызын Баянсылу дип атадылар.

Ак ханның улы өч яшәр булганда, Кара хан киявен чакыра инәсе белән. Ишектән инеп килер иде, Кара хан утырып күрде аны: ишекнең янында игәр эт[5] ятыр, аңа Кузы Көрпеч таянды. Кара хан:

– Ишекнең янында яткан игәргә таянган Ак ханның улына мин кызымны ник вәгъдә кылдым бирергә? Инде бирмәм! – күңелендә тотты.

Ак ханның хатыны белмәде аны. Сыйлады, хөрмәт итте, аннан соң өенә кайтты. Ике кунганнан соң, Кара хан пузып[6] китте иле белән. Ак ханның хатыны ятып калды йортында. Ак ханның хатыны, Кара ханның пузганын огып[7], килде аңа:

---

[1] Ак киек – кыйммәт тиреле җәнлек.
[2] Төз – урман, дала, кыр.
[3] Сыгыт – елау.
[4] Мәлис – мәлеис – шат.
[5] Игәр эт – ау эте.
[6] Пузып – китү, күчеп китү.
[7] Огып – ишетеп, аңлап.

– Ник киттең илеңне ташлап?

Кара хан әйтте:

– Ишеккә яткан игәргә таянган хан улына кызымны бирмимен.

Ак ханның хатыны иле белән ятып калды.

Кузы Көрпеч ун яшьлек булды. Аннан соң балалар белән ладышка[1] атышыр булды. Балаларның ладышкасын отар булды, отса да алыр, отмаса да алыр. Бер зур бала әйтте:

– Син үәнлек[2] кылдың! Үән булсаң, Кара хан кызын качырып киткән, ул атаң заманында әйттергән хатының* булган. Андый батыр булсаң, җитеп алгыл аны хатын итеп! Кузы Көрпеч борын аны окмады. инде огып иди. Ул баладан сорады:

– Ул кая киткән?

Ул бала әйтте аңа:

– Моның күчеп киткән юлында каен агачы чыгып калды[3]. Чыгып киткән юлы будыр, – дип әйтте. Инде Кузы Көрпеч алардан сорады:

– Ни хәйлә булыр? – диде.

– Хәйлә шулдыр, – диде бала, – инәңә кер, инәңә әйт, карным ачып йөри, – дип әйт! Кузы Көрпеч әнисенә керде.

– Карным ачып йөри, – дип әйтте.

Инәсе кая багып әйтте:

– Көңчегеңә[4] богдай куыртып аша, – дип әйтте.

Кузы Көрпеч янә әйтте әнисенә:

– Көңчегеңнән мин туган имәс, синнән туган мин, үзең куыр богдайны, көнчегенең ашы миңа ярамый.

Әнисе торды, богдай куырды, пешә башлады. Тыштан балалар кыйгырды[5] тәрәзәдән:

---

[1] Ладышка – кузна.

[2] Үәнлек – батырлык, пәһлеванлык.

[3] Каен агачы чыгып калды – күптән булган хәл дигән мәгънәдә.

[4] Көнчек – кәнизәк, хезмәтче хатын-кыз.

[5] Кыйгыру – кычкыру.

– Кузы Көрпеч, өйдән чык, угы-ягыңны[1] ал! – диде.

Кузы Көрпеч угы-ягысын алды, әнисенә әйтте:

– Богдайдан алып бир, ашап чыгыйм!

Әнисе калак белән состы, бирде. Бала әйтте:

– Калактан эчмәем, йимәем[2].

Әнисе кыгыч[3] белән состы, бирде. Йимәде тагы бала..

– Кулың белән богдай сосып бир миңа! – дип әйтте әнисенә.

Әнисе кулы белән сосып бирде, әнисенең кулын бодай белән тотты. Әнисе:

– Кулым көйде! – дип әйтте. Аннан соң әнисенә әйтте:

– Минем хатыным кая китте? Дөресен әйт!

Әнисе әйтте:

– Кечкенә чагыңда, яшең җитмәгәндә кем әйтте?

Баласы әйтте:

– Мин инде куамын, син миңа азык шайла[4]!

Әнисе азык әзерләде. Инде әнисеннән баласы сорады:

– Миңа менәр ат бармы?

Әнисе янә әйтте Кузы Көрпечкә:

– Атаңның акбүз аты бар, йөгәне бар аның, ияре бар аның. Атаңның шае[5] бар, кылычы бар, саудагы[6] бар, йыдасы[7] бар.

Азык белән булды, шае белән булды, инде Кузы Көрпеч куып киткәли итте.

Әнисе әйтте:

– Тукта! Мин төш күрим синең китә торган юлыңа!

Түренә бер ястык ташлады, аңа әнисе ятты, Әнисе йоклап калды. Күп яткач, Кузы Көрпеч әнисен уятты.

---

[1] Угы-ягы – ук-җәя.
[2] Йимәем – ашамыйм.
[3] Кыгыч – туз кашык.
[4] Шайлау – әзерләү.
[5] Шай – ярак, сбруй.
[6] Саудак – садак, ук савыты.
[7] Йыда – сөңге.

– Яттың озак, – диде, – минем юрыгымны[1] кыскартма!
Әнисе торды:
– Ни күрдең, әнием, төштә?
Әнисе әйтте төшәгән төшен:

– Бүгендә яман төш күрдем, балам,
Өем артында Бай тирәк[2] күрдем, балам,
Өй өстенә егылды, балам,
Ишегем алдында сары елан, балам,
Юлыңа сузылып ятты, балам!

– Бүгендә яман төш күрдең, инәй,
Өем артында Бай тирәк, инәй,
Илемгә егылып калгайлы, инәй,
Ишегең алдында сары елан, инәй,
Юлымга сузылып калгайлы, инәй!

– Бүгендә яман төш күрдем, балам,
Уйның[3] утыз бүресе, балам,
Аннан кайдан чыгарсың, балам?
Кырның кырык бүресе, балам,
Аннан кайдан чыгарсың, балам?

– Бүгендә яман төш күрдең, инәй!
Уйның утыз бүресенә, инәй.
Утыз йебә[4] шай[5] булыр, инәй,
Кырның кырык бүресенә, инәй,
Кырык йебә шай булыр, инәй.

---

[1] Юрык – йөрү, юл.

[2] Бай Тирәк – ыру агачы, төрки мифологиядә ике дөнья арасында үскән агач.

[3] Уй – түбән җир, иңкү җир.

[4] Йебә – сөңге.

[5] Шай – таман.

– Бүгендә яман төш күрдем, балам,
Тычканнар үтмәс карурман, балам,
Аннан ничек чыгарсың, балам?
Атлар әйләнмәс ала тау, балам,
Аннан кайдан чыгарсың, балам?

– Бүгендә яман төш күрдең, инәй,
Тычканнар үтмәс карурман, инәй,
Алмас булатым белер (аны), инәй.
Атлар әйләнмәс ала тау, инәй,
Алмас булатым белер ул, инәй.

Әнисе өйдә калды, Кузы Көрпеч китте, хатынын куып. Юлда уйның утыз бүресе килде, кырның кырык бүресе килде. Кузы Көрпеч кылыч белән аларны үтерде. Аннан ары китте, кара урманга барды, кара урманны кисте кылыч белән, юл ясап чыкты аннан. Аннан ат әйләнмәс ала тауга барды, кылыч белән чапты, җимерде, юл ясап, үтеп китте. Аннан үткәч, юлы чүлгә чыкты, кочкачак[1] очмас коба[2] чүл булды, анда бер козгынны күрде, әйтте:

Атам диим сине, козгын,
Анам диим сине, козгын,
Кара ханның өе кайдадыр, козгын?
Кара таш өй кайдадыр, козгын?

Козгын әйтеп ята:

Атам дисәң мине, балам,
Анам дисәң мине, балам,
Кара хан үтерсә сине, балам,
Кашыкча каныңны эчәрмен, балам.

[1] Кочкачак – чыпчык.
[2] Коба – кара-кучкыл чия төсе яки аксыл сары төс.

Кузы Көрпечнең ачуы килде, угын тартып алып атты козгынны. Козгын төште, үлде. Аннан соң Кузы Көрпеч Кара ханны куып бара.

Саескан очмас сары чүлгә килде, анда саескан очып килде. Аны күрде Кузы Көрпеч, аны күргәч, сорады аннан:

Атам диим сине, саескан,
Анам диим сине, саескан,
Кара ханның өе кайдадыр, саескан?
Кара таш өй кайдадыр, саескан?

Аңа саескан әйтеп ята:

Атам дисәң мине, балам,
Анам дисәң мине, балам,
Кара хан үтерсә сине, балам,
Кашыкча кара каныңны эчәрмен, балам.

Аннан соң Кузы Көрпечнең ачуы килде, угын алды, атты саесканны, саесканның башын өзеп сыргады[1].

Аннан соң китте Кузы Көрпеч, китеп барды бер дәрья ягасына, бер байтирәкнең төбенә төште атыннан. Атының иярен алды, атының йөгәнен сурду[2], агытты[3] атны, иярен ястады[4], тугымын[5] түшәде, ятты. Кара кеш тунын өстеннән ябынып йоклап ятты. Алты ай анда йоклады, көзгә җитте. Көз вакытында кара кеш тунынннан үлән топла[6] чыкты. Кыш көнендә дәрья бозы туңды. Аты симерде, килде, Кузы Көрпечнең баш ягында тор-

[1] Сыргау – (чыргау) – сөру, ыргыту.
[2] Сурду – ычкындырды.
[3] Агыту – бушату.
[4] Ястау – ястык итү.
[5] Тугым – тирлек.
[6] Топла – үтәли.

ды, тынды[1] иясенең тунын. Тун суелып, аягына егылды, уянды иясе. «Пы! Күп йокладым», – дип торып килде.

Аннан торып атының йөгәнен катты[2] башына, иярен әртләде[3] өстенә, аннан шайланып, кесәсеннән булат кадауларын[4] алып, атына дага какты. Аннан дәрьяның аръягына туры китте, бер көндә чыкты дәрьяның аръягына.

Анда Кара ханның олы улының малына чыкты, аның колларында кунак булган. Коллары әйтте:

– Хан улы би килде, би улы мырза килде, аңа мал суярга кирәк. Суйдылар бер куйны, ашаттылар пешереп. Анда кунак булып кунды Кузы Көрпеч. Иртән торды, тагы ашаттылар. Кузы Көрпеч сорады:

– Инде моннан ары кеше бармы? Еракмы?

Коллары әйтте:

– Кара ханның кече улының малын багып ятканнарга бер көн юл бар. Аларга барып кунак булырсың.

Аннан китте Кузы Көрпеч, бер көндә җитте колларга. Коллар әйтте:

– Ханның улы, би кайдан килде? – диделәр.

Бер мал суйдылар ашатырга, ашаттылар аңа. Кунды берне алар белән. Иртә белән тагын ашаттылар. Ул коллардан тагы сорады Кузы Көрпеч:

– Еракмы ил моннан ары?

Ул коллар әйтте:

– Моннан барсаң, ярым көндә җитәрсең. Баянсылу куен бага торган колына барырсың.

Аннан ары тагы китте юлга чыгып, көн ярымында барды.

– Бу кемнең куе? – дип сорады Кузы Көрпеч.

---

[1] Тыну – иснәү.

[2] Кату – киертү.

[3] Әртләү – тартып бәйләү.

[4] Кадау – кадак.

Кол әйтте:

– Баянсылуның куе.

Атыннан төште, колының башын чиртеп сыргады[1], үтерде. Киез калпагын аның үзе киде, колның тунын алып тагы киде. Үзенең акбүз атын агытты, үзенең тунын, киемен җыеп ташлады. Ул куйларын үзе кечкенә булып багып йөрде. Борынгы карт куйлар Кузы Көрпечне таныды, кайтып йөрделәр Баянсылуга. Баянсылуның тәрәзәсенә килде, чарлады[2]. Баянсылу аны күрде, әйтте куйга:

Какылдашкан күп карга
Карымның маен салдасын[3]!
Илдә калган минем ир Кузым
Инде бер искә төшәрме, кәүр?[4]

Бүкелдәшкән күп бүре
Бүремнең маен салдасын!
Илдә калган минем ир Кузым
Инде бер искә төшәрме, кәүр.

Кич булды, малын әйдәп килде Баянсылуга. Өйнең артында елга, әйре[5] бар иде. Куй килде аңа, торды, ары җилде[6], бире җилде. Кузы Көрпеч пошыкты[7] куйга, ботыннан тотты, боты сынды, әйренең ар ягына атты. Баянсылу күрде аны чыгып.

– Таз кол, ни эшең? – дип әйтте: – Әйтә торган сүзең бар, аны әйт! – диде:

---

[1] Сыргау – атып бәрү, ыргыту.
[2] Чарлау – кычкырып чакыру.
[3] Салдау – талашып алу.
[4] Кәүр – гәвер, кяфер.
[5] Әйре – елга.
[6] Җилде – ташланды, ыргылды.
[7] Пошыгу – куркыту.

Кичәләрең[1] кичелсен[2],
Кичмәгәнең калсын!
Кузы Көрпеч куйга әйтте:
Кичеләрең кичелсен!
Кичмәгәнең калсын!

Бу сүзен әйткәннән соң куй кичте[3]. Кузы Көрпеч килде Баянсылуның өенә. Баянсылу аңа әйтте:

– Сыерны сау! – диде.

Кузы Көрпеч сауды аны, сыерның цоцугын[4] тартты, өзде цоцугын, ташлады. Баянсылу чыгып күрде аны. Баянсылу әйтте:

– Таз кол, акылың бармы? Сыерның цоцугын ник өздең?

Саулары савылсын,
Савылмаганы калсын!

Өйгә керде, көн кич булды. Баянсылу ястык салды, түшәк салды, ятты.

– Таз кол, – диде, – табанымны яла йокларга.

Кузы Көрпеч чыкты өйдән, бер сыерның телен өзде, өйгә кереп аның белән табанын ялатты. Аягын кайра[5] тартты Баянсылу:

– Телең каты! – дип әйтте.

Кузы Көрпеч янә чыкты өйдән, бер игәр телен өзде, өйгә кереп, аның белән табанын ялатты. Ялатты, йоклады. Таз кол ята торган урынына, ишек янына барып, ятып йоклады анда. Алтын ураган толымын чыгарып куйды, киез такыясыннан[6]. Төн уртасында уянды Баянсылу, өйнең эче ярык[7] булган.

---

[1] Кичә – аша, үтә.
[2] Кичү – кичерү, гафу итү.
[3] Кичте – гафу итте.
[4] Цоцук – имчәк.
[5] Кайра – кире.
[6] Такыя – бүрек, баш киеме.
[7] Ярык – якты.

– Көн өстеннән чыкканым юк, – дип тышка чыкты.

Көн төн булды, караңгы тышта. Сыер белән куйга тиеп егылды Баянсылу. Өйгә инде, Кузы Көрпечне күрде. Баянсылу әйтте:

– Әниемнән туган сиңа боерган иде.

Түшәгенә Кузы Көрпечне бергә яткырды. Анда йокладылар. Иртән көн тан атты, Баянсылу әйтте Кузы Көрпечгә:

Аран[1]да куйлар мәңрәште, Кузым!
Көн чыкканнарга[2] ошаттым, Кузым!
Көн чыкканнарга ошаттым, Кузым!

Кузы Көрпеч әйтеп ятты:

Аранда куйлар мәңрәшсә, Баяным,
Ач бүреләргә аш булсын, Баяным!
Һавада тургайлар сырлашса[3], Баяным,
Ач кыйгыракларга[4] җим булсын, Баяным.
Ай чыкмакларда көн чыксын, Баяным!
Так куеннардан җан чыксын, Баяным!

Анда тордылар икәү хатын-ир булып. Кызның атасы Кара хан борын кызын Када Калмакка биргән икән. Кыз аны сөймәде, явытмады[5]. Яланнан кайтыр иде, кызын күргәне юк.

Бер көн Кара Калмак Кузы Көрпечнең килгәнен күреп калды. Кара Калмак барып Кара ханга әйтте:

– Кызыңның ире Кузы Көрпеч килде, кызың белән көн күреп тора.

---

[1] Аран – абзар.
[2] Көн чыгу – кояш чыгу.
[3] Сырлашу – җырлаша.
[4] Кыйгыр, кыйгырак – карчыга.
[5] Явытмау – явык (якын) итмәү.

Кара хан Кузы Көрпечне – киявен чакыра. Арацан[1] пешерде, корацан[2] пешерде. Чакыртты, бер кешене җибәрде.

– Кара хан кайнатаң чакырып ята сине, – диде.

Аның әйтүенә бармады. Кайтарды илчене. Илче кайтты ялгыз.

Кара хан тагын ике илче җибәрде. Алар белән сөйләшмәде Кузы Көрпеч. Кайтты тагын икәү Кара ханга.

Кара хан инде өч кеше җибәрде Кузы Көрпечгә, аны алып килсен дип.

Инде Баянсылу Кузы Көрпечгә әйтте:

– Инде баргыл! – диде. Аннан яхшы тунын кидерде, шаматты[3] ирен:

– Анда барсаң, эчмәкел аракы! Исерсәң, үтерерләр, – диде.

Кузы Көрпеч инде барды, Кара ханга җитте, урынга утыртты, сыйлап ята аны.

Кузы Көрпеч Баянның сүзен онытты, әйтте:

– Сыйлап ята. Баянның куе-сыеры эчә, эчсә дә исерми, – диде, – мин дә эчим!

Кузы Көрпеч эчте, исерде. Кара хан инде йөз чирү шайлады, Кузы Көрпечне үтерергә ниятләнде.

Аннан соң озак булды. Баянсылу атасының өенә барды. Тыштан күрде Баянсылу ирен, Кузы Көрпеч исергән булган. Баянсылу ирен уятырга санады[4]. Шиләгәйне[5] чыгарды, шиләгәй аның йөзенә төште. Уянды Кузы Көрпеч. Уң кулында йөз кешене яба басты, ике кулына ике йөз кешене яба басты. Өйдән чыкты, Баянсылу белән өенә барды. Атын китерде, тунын китерде. Ир шаен китерде.

---

[1] Арацан – исерткеч эчемлек, сөттән 2 тапкыр куылган.

[2] Корацан – шул ук (дүрт тапкыр куылган).

[3] Шамату – кисәтү.

[4] Санау – исәп итү, тиеш табу.

[5] Шиләгәй – селәгәй, төкерек.

– Инде йорттан чыгып киткел! – диде. – Син исердең, – диде, – инде сине пазып[1] үтерер, – диде.

Атына менде, урам белән китте.

Ул шәһәрнең алдында елга-әйре бар иде, таш белән күперләгән. Ул күпер астыннан чыкты бер таз кол. Ук-ягасын тотканча чыкты. Угының соганы[2] энәдәй, булды, аның башы агулы иде.

Ул таз кол әйтте:

– Тезеңне ялангачлап күрсәт миңа, мин атыйм! – диде.

Кузы Көрпеч тезен күрсәтте. Таз кол җәясен алды кулына, агулы соган белән атты, соган Кузы Көрпеч тезенә тиде. Кузы Көрпеч әйтте:

– Анамнан тугам итемдә[3] һичнәрсә авыртканы юк, син авырттың.

Камчы белән пошыгып[4], таз колны күпернең астына индерде.

Кузы Көрпеч китте, чүлгә барып ятты. Бер цок[5] байтирәк агачның төбендә ятты, атын бушатты. Кузы Көрпечнең ите шешенде. Бер кунды, ике кунды, өч кунды. Баянсылу бер асрау[6] тургай кошын җибәрде, тургайга әйтте:

– Кузы Көрпеч килмәгәне озак булды. Син бар, тургаем! Кая барганын эзләп күр! Белергә кирәк! – диде.

Тургай эзләп китте, чүлгә очып барды, тапты. Тургай цок байтирәккә кунды. Бүз тургайны Кузы Көрпеч күрде. Кузы Көрпеч әйтте:

– Баянсылуның бүз тургае булсаң, карыным ачып ятам, аш китергел миңа! – диде.

---

[1] Пазып – тотып.

[2] Соганы – очы.

[3] Ит – тән.

[4] Пошыгу – кизәнү, куркыту.

[5] Цок – куе.

[6] Асрау – ашатып торган, карап торган.

Кайтып барды бүз тургай Баянсылуга.

– Баянсылу, иреңне таптым, карыным ачты, аш китер, дип әйтте.

Баянсылу икенче көнендә ян канатына алтын җеп белән бавырсак бәйләп элде, бүз тургайны җибәрде. Анда барды тургай, Кузы Көрпечкә ике күз[1] бавырсак белән ашатты.

– Тагы килтер! – диде.

Тагы ике күз бавырсак янә алып барды янына, аны ашатты.

– Тагы килтергел! – диде.

Ул көнне тургай кайтса, Баянсылуның җиңгәсе Баянның башын багар иде. Бакса, тургай килеп, җиңгәсенең куенына керде, җиңгәсе тургайны тотып алды. Баянсылу кош тотканын белмәде. Баянсылу җиңгәсенә әйтте:

– Өйгә кайт инде!

Җиңгәсе кайтып ул тургайны үзенең өенә алып барды, йонын йолыкты.

– Әйт миңа, тургай, – диде, – Кузы Көрпечне таптыңмы?

Йонын йолыкса да, тургай әйтмәде. Әйтмәгәнгә бу кошны үтерделәр, тишкә[2] чәнчеп, бер янын пешерделәр утка. Бер яны пешкәч, янә бер янын утка куйдылар, тиресе пешеп колҗалды[3], ярылды. Аннан тавыш килде: «Чук байтирәкнең төбендә ятыр».

Эзләтеп карт кешеләрдән сорады Кара хан:

– Ул җирне күргән кеше булдымы бу җирдә?

Бер карт әйтте:

– Чүл уртасында бер байтирәк бар, – диде.

Кара хан җиде йөз чирү шайлап эзләп барды. Егетләр Кузы Көрпечне тоттылар, аннан соң үтерделәр. Сарай киртмә өй ясап, аның эчендә Кузының сөяген ябып куйдылар. Ул өйне ишекләп куйдылар, ишеген ябып куйдылар.

---

[1] Ике күз – ике бөртек.

[2] Тиш (шеш) – чыбык, чәнечке.

[3] Колҗалу – кабару.

Болар йортларына кайтып бардылар, Кузы Көрпечне үтердек, дип масайдылар. Баянсылу атасы үтереп киткәнен окты[1], инде яхшы тунын киеп ясанды, яхшы калфагын киде, атасына килде.

Аргалап барып ни аттың, атай?
Мараллар атып килдеңме, атай?
Маралларның ите татлы дип, атай,
Миңа нисен китердең, атай?

Угалап[2] барып ни аттың, атай,
Азаулар[3] алып килдеңме, атай?
Азауларның ите татлы дип, атай,
Шыр алгаларын[4] китердеңме, атай?

Атасы кызына әйтте:

Каеннан таяк алырбыз, Баян!
Халыкта сылу талдарбыз[5], Баян!
Халыктан сылу табылса, Баян,
Атын Кузы Көрпеч атарбыз, Баян!

Имәннән таяк алырбыз, Баян!
Илдә сылу талдарбыз, Баян!
Илдән сылу табылса, Баян!
Исемен Кузы дип атарбыз, Баян!

Кыз әйтә:

Атны син тотып китерсәң, атай!
Алтынлы нукта катарсың[6], атай!

---

[1] Окты – ишетте.
[2] Угалап – ишетеп барып.
[3] Азау – колын
[4] Алга – итнең бер өлеше булырга мөмкин. Төгәл мәгънәсен тапмадык.
[5] Талдау, талдару– эзләү.
[6] Кату – киертү, тагу.

Аттан атка катарга, атай,
Алтынлы нукта минме идем, атай?

Өернең байталын[1] өергә син кушсаң, атай,
Өергә аны кушарга айгырың булса, атай!
Өердән өергә кушарга, атай,
Өерсәк байталың минме идем, атай?

Агасына китте кыз, олы агасына килеп, Баянсылу әйтте:

Угалап бардың, ни аттың, агай?
Аюны алып килдеңме, агай?
Аюның ите татлы дип, агай,
Миңа нисен китердең, агай?

Угалап бардың, ни аттың, агай?
Ак киекләр атып килдеңме, агай?
Ак киекнең ите татлы дип, агай,
Миңа нисен китердең, агай?

Агасы кызга әйтте:

Каеннан таяк алырбыз, Баян!
Халыкта сылу талдырбыз, Баян,
Халыкта сылу табылса, Баян,
Атын Кузы дип атарбыз, Баян.

Имәннән таяк алырбыз, Баян,
Илдә сылу алырбыз, Баян,
Илдән сылу табылса, Баян,
Исемен Кузы дип атарбыз, Баян!

Кыз әйтә агасына:

Каеннан таяк алдырсаң, агай,
Халыкта сылу талдырсаң, агай,

[1] Байтал – колынламаган бия.

Халыктан сылу табалсаң, агай,
Акылы Кузыга җитмәс куй, агай!

Имәннән таяк алдырсаң, агай,
Илдә сылуны талдарсаң, агай,
Илдән сылуны табалсаң, агай,
Акылы Кузыга җитмәс куй, агай.

Илнең сылуы ярамас, агай,
Акылы Кузыга җитмәс куй, агай,
Мине дә сөйсәң, үзең ал, агай,
Сылу җиңгәмә көндәш булыйм, агай!

Агасы ул сүздән пошыкты, угын капты, ягысын тартып сеңлесен атты, алтын такыясын бер янын кисә[1] атты. Качып чыкты Баянсылу, өенә кайтып барды. Яхшы туннарын киде, яхшы такыясын киде. Кырык кызагы[2] кыз булды аның, аны җыеп алды өенә. Бер алтын саплы пәкене җиңенә алды. Кырык кыз белән чирү киткән юлга төштеләр. Киттеләр, бер чүлгә чыгып киттеләр. Юлда энҗе-мәрҗән чәчте, кырык кызагы аны тирип[3] калдылар юлда.

Баянсылу китте. Кырык кызаклар янә куып җиттеләр. Аннан бара торгач, бер чүл үткәч, тагын Баянсылу калган энҗе-мәрҗәнен җиргә чәчте, кырык кызагы тагын аны тәрип калдылар. Баянсылу янә узып китте, кырык кызаклары янә кудылар. Баянсылу җитте Кузы Көрпечнең сараена, кырык кыз килгәнче ишеген ачты, керде. Үлеп яткан ирнең тунын ачты, куенына керде, алтын саплы пычакның сабын ирнең түшенә куйды, ирне кочаклап, пычакның безе үз түшенә керде. Үлде Баянсылу.

---

[1] Бер янын кисә – бер ягын аркылы.
[2] Кызак – кыз.
[3] Тирү – җыю.

Үлгәннән соң кырык кызак артыннан куып килеп җиттеләр, үлгәнен күрделәр. Кырык кызак кайтып барды Кара ханга, кызының үлгәнен әйттеләр. Кара хан әйтте:

– Ике әт[1] сөеште, үлсә дә куймамын, аларны бер җирдә аерырмын, – диде.

Инде ата-анасы килде үлгән җиренә, икесен ике җиргә аерып гөмбәз ясап күмделәр.

*1860 елларда Тәрәнә авылында (хәзерге Новосибирск өлкәсе Уба районы) академик В.В. Радлов тарафыннан язып алынган.*

*Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен,живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. С. 9–20.*

[1] Әт – балигъ

## Баян белән җиңгәсе диалогы




Җиңгәсе:

Кара та атлар кешнәсә, Байаны,
Таң атмакларга ошайтыр, Байан, тите…

Баян:

Кара та атлар кешнәсә, җиңгәй,
Так куйыннарта йан чыксын, җиңгәй, тите…

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Байкова Зөһрәдән (1900 елгы) Илгиз Кадыйров тарафыннан язып алынган һәм нотага төшерелгән.*

## Кузы Көрпеч белән Баян Сылу

Акхан белән Карахан көтмештә[1] булалар. Караханга кешкәрнәй күп эләкми. Шуңа алар бергәләп көтмәк булалар, дуслашасылары килә. Өйдә хатыннары корсаклы калган була. «Ул булса – дус итәбез, кыз белән ул булса – ярәшәбез», дип сөйләшәләр.

Шуннан соң көтмешләре уңышлы китә, алтын йонлыларын да, кыйммәтлеләрен дә тоталар. Шактый табыш белән кайтырга чыгалар. Юлда халык җыелып, аларны каршы алырга чыккан була. Карахан хатыны кыз тапкан, Акхан хатыны ул тапкан. Акхан шатлыктан атын чаптырып киткән дә таудан төшкәндә егылып үлгән.

Карахан кайта, Акханны күмәләр. Балаларга Кузы Көрпеч белән Баян Сылу дигән исемнәр кушалар. Балалар зурая төшкәч, Карахан Акхан хатынын чакырып ала, улы белән вәгъдәләшер өчен. Караханның Лакман исемле эте булган. Кузы Көрпеч, өйгә кергәч, таеп егыла да, кулы эт савытындагы ашка төшә. Малай кулын ялап куя. Моны күреп торган Карахан:

– Эт ашын ялаган кешегә кызымны бирмәячәкмен! – дип, халкын алып күчеп китә.

Баян Сылуны яшерәләр.

Кузы Көрпеч зурая, палван[2] булып үсә. Иптәш малайларының кулларыннан тотса, куллары сына, сагаларын[3] алып китә. Кыерсытылган малайлар аңа:

– Әйбәт кеше булсаң, үзеңнең кызыңны табар идең! – диләр.

Кузы Көрпеч бер әбидән сорый:

– Кем ул кыз? Бармыни? – ди.

Әби әйтә:

– Бар, – ди, – син аны әниеңнән сора.

---

[1] Көтмеш – аучылык, сунар.

[2] Палван – пәһлеван, батыр.

[3] Сага – кузна.

Әйтмәсә, куырмач[1] куырт та кулын пешер, – ди.

– Һавада аккошлар очып тора,
Аткырлар[2] атып кала,
Ата алмаганнар ятып кала,
Куырмач куыр, әни, –

ди Кузы.

Әнисе куыра, кыйгач[3] белән бирә, алмый Кузы:

– Кыйгы белән юл кыек,
Табак белән юл такыр,
Кулың белән бир, – ди.

Әнисе кулы белән биргәндә, Кузы әнисе кулын кысып тота. Кызган бодай белән учын пешереп:

– Бармы минем кызым? Кайда ул? – ди.

Әнисе:

– Бар, – ди, – Баян Сылу исемле. Бик еракта, – ди.

Кузы Көрпеч кызны эзләп китәргә җыена. Әтисенең акбүз атын ала, иярен, камчысын ала. Әнисе җибәрми.

– Урманның утыз бүресе, балам,
Аны ла ничек чыгарсың, балам?
Кырның да кырык аюы, балам,
Аны ла ничек чыгарсың, балам?

Кузы:

– Урманның утыз бүресенә, анам,
Кырның ла кырык аюына, анам,
Атамның бер угы шайдыр[4], анам.

---

[1] Куырмач – кыздырган бодай, я башка орлык.
[2] Аткыр – төз атучы, яхшы атучы.
[3] Кыйгач – туз кашык.
[4] Шай – таман.

Әнисе:

– Илдән лә илгә йөрербез, балам,
Илдән бер матур табарбыз, балам.
Илдә бер матур тапсак, балам,
Исемен Баян кушарбыз, балам.

Кузы:

– Илдән лә илгә йөрербез, анам,
Илдә бер матур табарбыз, анам,
Илдә бер матур тапсак та, анам,
Исемен Баян кушсак та, анам,
Үзе лә Баян булмас куй, анам.

Кузы юлга җыена.

– Тукта, балам, – ди әнисе, – сабыр ит, берничә ел көт, әле кимерчәгең катмаган, – ди.

– Менә кавырсын[1] кыстырып китим, кавырсыннан кан тамса, үлгән булырмын, – дип китеп бара Кузы.

Юлда аңа бүреләр очрый. Бер бүрене атарга итсә, әнисе булып әйләнә.

– Китмә, улым, – дип ялына. – Утыр әле теге түңгә[2], ди, сөтемне савыйм, авызыңа төшсә, китмәссең, – ди.

Сөтен сава, Кузының авызына төшми, читкә китә.

Кузы юлын дәвам итә. Тагын аюлар очрый аңа. Атарга итсә, әнисе булып әйләнә. Тагын түңгә утырта, сөтен сава, тагын авызына төшми.

Әнисе:

– Күз күрмәгән кара карагай, балам,
Аны ла ничек үтәрсең, балам?

Кузы:

– Күз күрмәгән карагайны үтәргә, анам,
Атамның акбүз аты шай, анам.

---

[1] Кавырсын – каурый.

[2] Түн – түмгәк.

Әнисе:

– Идел лә суы бар диләр, балам,
Аны ла ничек чыгарсың, балам?

Кузы:

– Идел лә суын үтәргә, анам,
Атамның бер камчысы шай, –

дип китеп бара.

Бер ат көтүенә очрый.

– Кем көтүе? – дип сорый көтүчедән.

– Карахан өере, – дип җавап бирә көтүче.

– Бер атыңны суй, – ди Кузы Көрпеч.

– Җиде ел колынламаган бия бар, шуны суям, – ди көтүче, – тик ничек тотарга белмим.

Кузы Көрпеч тотып китерә. Атны колаклы айман[1] казанда пешерергә куйдыра. Үзе җиде көн, җиде төн йоклый. Ит пешкәч, уяна. Бер бияне ашап бетерә, ите бер якка, сөяге бер якка оча тора, җилеген ашый, сөяген борынынннан чыгара тора. Көтүче куркып кала:

– Йөзең саллы[2], күзең нурлы, кайдан син? – ди.

– Улсызга ул, кызсызга кыз булырга барам, – ди Кузы Көрпеч.

Алга таба китә бу Баянын эзләп. Сыер көтүенә очрый. Көтүчегә сәлам бирә.

– Йөзең саллы, күзең нурлы, каян киләсең? – ди көтүче.

– Улсызга ул булам, кызсызга кыз булам. Моннан ары нинди көтүләр бар? – ди.

– Баян Сылу көтүе, бозау, сарык көтүе, – ди көтүче.

Монда бер үгез ашап, тамак туйдырып китә.

Сарык көтүенә барып җитә. Сәлам бирә.

– Улы юкка ул, кызы юкка кыз булам, бу кем көтүе? – ди.

– Баян Сылу көтүе, – ди көтүче.

---

[1] Айман – зур.

[2] Саллы – затлы, иркә.

– Кайда ул үзе?

– Әйре[1] аръягында.

– Аны ничек кичәргә?

– Кичел, суым, дисәң, кичелә ул, – ди көтүче.

– Бабай, маңгаеңа чебен кунган, үтеримме?

– Үтер, балам.

Кузы Көрпеч картның маңгаена бер чиртә, үлә карт. Кузы аның киемнәрен кия, көтү кайтара. Елгага җиткәч, бабайның сүзен оныта, сарыкларын бер-бер артлы су аша ыргыта. Бер бәрәнне куенына тыгып калдыра. Баян Сылу йөгереп килә:

– Малларымны бетердең бит, кичел, суым, дисәң булмыймыни? – ди.

– Ул сүзне оныттым шул, – ди Кузы. Бәрәнен Баян Сылу янына җибәрә.

– Илдә лә калган Кузыкаң, Баян,
Инде лә килеп җитте гуй, Баян, –

ди бәрән.

Баян Сылу аны куып җибәрә. Тагын әйтә, тагын куа.

– Алай да әйттем, белмәдең, Баян,
Болай да әйттем, белмәдең, Баян,
Көн күререңдә көнең күмелсен, –

ди бәрән.

Баян Сылу аңа кайчы белән бәрә, бәрәннең колагы киселеп кала. Бәрән әнисе янына кереп китә. Баян Сылу шул сарыкны суярга куша. Сарыкны суеп, итен пешерәләр, көтүчене ашарга чакырта. Баян Сылуның өч якын кызы була. Шуларның берсен җибәрә көтүчене чакырырга. Кузы Көрпеч бармый, чирлим, ди. Тагын бер кызын җибәрә, аңа да шулай ухылдап, бара алмыйм, дип җавап кайтара. Баян Сылу үзе йөгереп килә.

– Әйдә, бабай, җылы җирдә йокларсың, ит ашарсың, – ди.

---

[1] Әйре – елга.

Китә Кузы Көрпеч. Баян Сылуның үкчәсенә баса-баса бара.

– Бабай, үзең шәп атлыйсың бит, – ди Баян.

– Яшь чаклар искә төшеп китте, – ди Кузы Көрпеч.

Ит ашарга утыралар, ит кисәргә пычак юк. Кузы Көрпеч пәкесен бирә. Баян Сылу кулын кисеп ала.

– Каян алдың мондый үткен пәкене? – ди.

– Гомеремә үзем тоткан пәкем, – ди Кузы Көрпеч.

Баян Сылу пәкедәге язуны укый.

– Юк, син яланда берәр кеше очраткансыңдыр, шуның пәкеседер, – ди.

Бабай, ашап туеп, чыгып китмәкче була.

– Юк, монда кунарсың. Мин йоклый алмыйм, минем табанымны яларсың, – ди Баян.

– Алайса тышка чыгып керим, – дип чыга да җиде яшьлек үгезнең телен өзеп алып керә. Шуның белән Баян Сылуның табанын ышкый.

– Телең бик коры, кәсәңкәдә[1] май бар, шуны ашап кер, – ди Баян.

Кузы чыгып, Лакман дигән этнең телен өзеп керә.

– Менә хәзер телең йомшак, – ди Баян, йоклап китә.

Кузы Көрпеч әкрен генә тора да үз хәленә кайтып ята. Аның матурлыгыннан бүлмә яктырып китә. Баян уянып караса, таң дисә, таң түгел, бүлмә яп-якты, бер чибәр егет ята. Кузы Көрпечне танып ала. Барысын сөйләшәләр, сандыкка кереп яталар. Баянның тәңкәсе сандык тышында калган. Җиңгәләре, таң аткач, моны уятырга киләләр.

– Аранда[2] куйлар мәңридер, Баян,
Таң атуларга охшыйдыр, Баян, – ди.

– Мәңрәшмәк түгел, таң атсын, җиңгәй,
Так куеннардан җан чыксын, җиңгәй.

---

[1] Кәсәңкә – чолан.

[2] Аран – абзар.

– Моның Кузысы килгән, ахыры, – дип китә олы җиңгәсе.

Уртанчы җиңгәсе дә килеп уята. Сандык тышындагы тәңкәсен күрә дә, Кузы килгән икән, дип китә.

Бу вакытта Баян Сылуны кече абыйсының кайнишенә – Әерчәк хан малаена ярәшеп йөргән булалар. Кече килен килеп Баянны уята, тәңкәне кисеп алып китә дә кайнанасына күрсәтә.

– Кузысы килгән, – дип, Баянны сүгә.

Кайнатасына әйттереп, сихерче карчык чакырттыра. Кузы Көрпечне ничек үтерү турында киңәшәләр. Карчык әйтә:

– Зур мәҗлес җыйнагыз, – ди. – Өй түрен казыгыз, анда утын ташлагыз, өстенә ак киез җәегез, утыру белән төшеп китәр, шунда яндырып үтерерсез, – ди.

Болар нәкъ шулай эшлиләр. Кузы Көрпечне ашка чакыралар. Түрдән ак киез өстеннән урын күрсәтәләр.

– Юк, сез олы, сез утырыгыз, мин әле яшь, – дип, анда утырмый.

Әзрәк утыргач, Баян Сылу ефәк яулыгын болгый, чакырып ала. Кузы Көрпеч чыгып, акбүз атына менеп китә. Баян Сылу озатып кала.

Кузы Көрпеч бер күпергә җитсә, бер малай килеп чыга.

– Угым белән аягыңа атыйм әле, җизни диярмен үзеңне, – ди.

Кузы Көрпеч аттырмый. Икенчегә тагын очрый.

– Я, үкчәңә генә аттыр инде, җизни диярмен, – ди.

Тагын аттырмый. Өченчегә очрагач:

– Я, камыш уктан ни булсын! – дип, атарга рөхсәт итә.

Шунда ук аягы шешеп чыга да, чукпәйтәр[1] янына килеп егыла. Шунда ята бу.

Баян Сылуның тургае булган. Ул аны Кузы артыннан очыра. Тургай кайта, сөйләп бирә:

– Кузы чукпәйтәр янында үлеп ята, – ди.

---

[1] Чукпәйтәр – куш тирәк.

– Алайса алып барып дару сөртә тор, мин дә барып җитәрмен, – ди Баян Сылу.

Тургай оча. Шул вакытта сихерче карчык кече киленне өйрәтә:

– Син Баян Сылуның киемен киеп, аның башын багарга утыр, – ди.

Килен шулай эшли дә. Тургай очып кайта, аны Баян дип белеп, куенына керә. Килен кошны тотып ала да чыгып китә. Баян Сылу йоклап кала.

Коштан ничек әйттерергә дип, тагын карчыктан сорыйлар. Төрлечә азаплап та әйтмәгәч, тургайны утка ташларга куша. Ни әйтеп үлсә, шул булыр, ди. Тургайны утка ташлыйлар, «чук» дигән тавышы чыгып кала.

– Алайса чукпәйтәр янында икән, – ди карчык.

Атасы уллары белән Кузыны үтерергә китә.

Баян Сылу кызлар җыеп, кырга күңел ачарга дип китә.

– Йөгерер кызлар, йөгерер кызлар,
энҗе-мәрҗән җыяр кызлар, –

дип, өч урында мәрҗәннәр сибеп калдыра, кызлар аларны җыеп кала.

Баян Сылу чукпәйтәргә таба берүзе китә. Каршысына атасы, агалары очрый, кулларында Кузы Көрпеч башы.

Баян:

– Кырдан ла кырга йөрепсең, атай,
Кырдан киекбаш табыпсың, атай,
Кырдан киекбаш табыпсың, атай,
Аны ла миңа бирсәңче, атай.

Атасы:

– Илдән лә илгә йөрербез, Баян,
Илдә лә матур табарбыз, Баян,
Исемен Кузы куярбыз, Баян.

Баян:

– Илдә лә матур табылса, атай,
Исеме Кузы булса да, атай,
Үзе лә Кузы булмас куй, атай.

Әтисе Кузы башын бирә, кече улының бирдерәсе килми.

Баян Сылу Кузы башын алып чукпәйтәргә таба китә. Юлда өч кияве сугышып яталар. Аерысколан, Киезколан, Әерчәк хан улы Баян өчен талашалар. Аны елга аша уздырмыйлар. Баян Сылу яулыгына таш бәйләп суга ташлый.

– Кем тапса, шуңа булам, – ди. Болар өчесе дә төшеп китәләр. Баян таяк белән өчесен дә батырып үтерә.

Чукпәйтәр янына килеп, Кузысын таба, башын ялгап карый, терелми: үт куыгын суга агызган булганнар. Үте булса, тереләсе икән. Кузыны терелтә алмагач, Баян Сылу аның пәкесен ала да, үзен чәнчеп, Кузы өстенә егыла.

Әтиләре килеп күрәләр дә, үлгәч тә бергә булмасыннар дип, елганың ике ягына күмдерәләр. Икенче килсәләр, каберләр өстеннән алмагачлар үсеп чыгып, ишелеп киткәннәр. Каберләрен ачып карасалар, Кузы Көрпеч белән Баян Сылу үрдәк булып, кыйбла ягына таба очып киткәннәр.

Шунда Карахан, нигә бергә кушмадым икән бу ике яшьне дип, бик үкенгән.

*1967 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Айсылу Сунаровадан (1901 елда туган) фольклорчы Флора Әхмәтова тарафыннан язып алынган. Текст Ф.В. Әхмәтованың 2004 елда чыгарылган «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында дөнья күрде (б. 181–187).*

## **Кузының әнисе белән диалогы**




Әнисе:

> Кырның кырык аюы чыгар, палам,
> Аны ничек чыгарсын, палам?

Кузы:

> Кырның кырык аюы чыкса, әни,
> Угымның бер бүләсе шай пулыр, әни, тите ул…

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Байкова Зөһрәдән (1900 елгы) Илгиз Кадыйров тарафыннан язып алынган һәм нотага төшерелгән.*

## Бүз егет[1]

Заманнан күп заманнар үтте, диде,
Бер ханга ялгыз ул битте[2], диде.
Яхшы зат озак дәүран сөрмәк бармы?
Дөньядан әрман белән үтте, диде.
Бер ул туды – патшага, йортка лаек.
Савын[3] әйтеп, туй кылды илгә җәеп.
Йортына күп яхшылык кылган икән,
Туй кылды һәр җаннан[4] малны суеп.
Заманнан күп заманнар үтте, диде,
Тәңредән аманлыгын көтте, диде.
Җиде яшьтән баласы уку укып,
Ун яшенә бу ул инде җитте, диде.
Йөрептер яманны уена алмай,
Ялганның[5] кызыгына күңел куймай.
Кулына Коръән белән китап тотып
Барадыр мулласына бер көн калмай.
Күрмәгәнне күрәем дип йөрә икән,
Таң калып, йөзен күргән тора икән:
Башында алтын айдар[6] толымы бар,
Айдаен якты булып йөрә икән.
Бер көнне ятып, йоклап төш күрәдер,
Алдында аргымаклы кыз күрәдер.
Ул дагын бер патшаның ялгызы икән,
Бер ялгыз, бер ялгызга туш[7] буладыр.

---

[1] Бу әсәр кыскартылып, эчтәлеге кыскача бирелә. Бүз егет дип яшь егетләрне атаганнар.

[2] Битте – язды, насыйп итте.

[3] Савын – бүләк.

[4] Һәр җаннан – биредә: һәр төрле терлектән мәгънәсендә.

[5] Ялган – дөнья («бу фани дөнья» мәгънәсендә).

[6] Айдар – кырмый калдырылган чәч.

[7] Туш булу – туры килү.

Әлкыйсса. Карачәчсылу бер шаһзадәнең кызы ирде. Сәхиб җамал[1] ирде. Унбиш яшендә Бүз егетне төшендә күрде, гашыйк булды. Көннән көнгә йөзе сулды. Бер ел кайгылы булып йөрде. Һәм табип-дарыгәрләр[2] гыйлаҗ[3] тапмады. Икенче ел дагы Бүз егетне төшендә күрде. Шунда һәм кыз, егетне итәгеннән ушлап[4] җавап сорады:

«Төндә елап, көндез – зар,
Мин йөзеңә интизар.
Ни сәбәптән булдың яр,
Мине мондай кылып зар?
Акылың әйтсәң кирәкте.
Бер ел булды, янармын,
Үткән көнне санармын.
Һич гакылымнан танармын, –
Атың әйтсәң кирәкте».

Әлкыйсса. Бүз егет төшендә, сабыр кыл, дип әйткән сүзе:

«Бән – сәнеңмен, сән – бәнем,
Җанымга төште җаның,
Сатармы зарлап аның?
Сабыр кылсаң кирәкте.
Гашыйклар зарлап үтәр,
Тәңредән рәхмәт көтәр,
Морадка бер көн йитәр, –
Сабыр кылсаң кирәкте.
Сабыр кылмай эш бетмәс,
Мизгелсез арзың[5] йитмәс,

[1] Сәхиб җамал – матур йөзле.
[2] Дарыгәр – даручы.
[3] Гыйлаҗ – чара.
[4] Ушлап – тотып.
[5] Арзы – хыял, теләк.

Зарлау мән[1] кайгың китмәс, –
Сабыр кылсаң кирәкте...»

Әлкыйсса. Кыз сабыр кылды. Ата-анасы, йорты һич гыйлаҗ тапмады. Өченче ел дагы төшендә күрде.

Кыз төшендә егеткә биргән җавабы:

«Мин юлыңда интизар,
Мәйлең[2] булса, эзли бар,
Без бер патша ялгызы,
Сезнең өчен булдык зар.
Өч ел булды – саклаймын,
Киләме дип юклаймын,
Йөзеңне бер күрмичә,
Ничек чыдап туктаймын?
Җаның җанга кушылган,
Син хакыйкать яр булсаң,
Безнең өчен зар булсаң,
Шәһре-бостан-и Румнан[3]
Безне эзләсәң табарсың».

Төшендә кыз үзенең кайда икәнлеген әйткәннән соң, Бүз егет

«Шәһәрдән шәһәр сәел кылды, диде.
Һәр йирдә шәһәре бар ил күренсә,
Атыңның башын аңа борды, диде».

Бик озак йөргәннән соң, Бүз егет юлдашлары белән бер шәһәргә керәләр. Шушы шәһәрдә яшәүче бер өлкән кеше, абыз, егетләрнең максатларына якын булуын белдерә:

---

[1] Мән – белән.
[2] Мәйлең – теләгең, ихтыярың.
[3] Рум – грек, византияле.

«Шәһәрдән ярыңызны эзләп кара,
Кай йирдә әгъриб[1] булса, шуннан сора,
Ярыңыз бу шәһәрдән табылмаса,
Берәвеңез безнең өйгә кайтып ура».

Бүз егетнең дусты белән шәһәрдә йөргәнне кырык кызы күреп, Карачәчсылуга кызга хәбәр бирәләр.

Шәһәргә бичаралар керде, диде.
Алланың ярлыгына күнде, диде.
Бер күчәнең[2] эчендә йөреп иде,
Кырык кыз бар икән, күрде, диде.
Егеттән кызлар борын күргән икән,
Күчәдә ике гариб йөргән икән.
Патшаның кызының күзе төшеп,
Артыннан бераз карап торган икән.
«И кызлар, ул гариб(е) кем буладыр?
Һәр йиргә карап торып әйләнәдер?
Сөенче, ярым булса, бирер идем,
Ул гарибне күрергә кем барадыр?»

Хан кызының кызларга җырлап әйткәне:

«Батыр ирдәй йөреше,
Патша улындай торышы,
Күргән төшнең турысы
Бүген килгән булмасын.
Кылдан пәрдә башында,
Юлдашы бар кашында[3].
Кайгы төшеп башына
Яр эзләүче булмасын.

---

[1] Әгъриб – гарибләр, читтә йөрүчеләр.
[2] Күчә – урам.
[3] Кашында – янында.

Фида кылып малларын,
Корбан кылып җаннарын,
Барып сораң хәлләрен,
Сүз сораучы булмасын.
Төштә күргән ярымыз,
Аңа корбан барымыз,
Көндез-төнлә зарымыз, –
Яр эзләүче булмасын.
Барып йөзен күреңләр,
Әдәп саклап торыңлар,
Бераз карап торыңлар, –
Ил эзләүче булмасын.
Барып хәбәр алыңнар,
Йөзен карап күреңләр,
Кайгы-моңын сораңлар, –
Яр эзләүче булмасын.
Аннан хәбәр алганны,
Сөенеч хәбәр салганны,
Алтын йөзек, гәүһәр таш
Сөенчегә бирермен».

Бүз егет белән кыз очрашалар, аңлашалар.

Хан кызы гашыйк ярын белде, диде,
Кызларга ярын әйтеп көлде, диде.
Җырын җырлап тәрәздән хәбәр салды:
«И ярым! Без чыгармыз[1] гашыйк ярың,
Йиде елдан саклаган интизарың,
Эзләгәнең без булсак, гашыйк ярым,
Сүземә колак салың инде барың.
Дүрт ел булды юлыңда йөргән ярың,
Вәгъдә кылып төшеңдә күргән ярың,

[1] Без чыгармыз – без булырбыз.

Эзләгән гашыйк ярың килеп тормын,
Ишек ач, чын булса интизарың.
Сезне монда яратты,
Безне анда яратты,
Бераз зарлап йөрсен дип,
Арада дәрья яратты.
Күп гариблек күргәнмен,
Юл башлаучы бер тапмай.
Дүрт ел булды, юлында
Хәйран булып йөрепмен,
Дәрья кичеп, тауны үтеп,
Күрмәгәнне күрдем мин.
Табаннарым уелып,
Кул тирем дә суелып,
Дәүләт-багым җуелып,
Зар-сәргәрдан булдым мин.
Атамны мин күрмәдем,
Анамны мин күрмәдем.
Өйдә гомер сөрмәдем,
Бер син өчен йөрдем мин.
Сине эзләп йөргәнмен,
Буең төштә күргәнмен,
Җаным корбан кылганмын,
Рәхим итсәң кирәкте.
Зәгъферандай сулганмын,
Өч ел тоткын булганмын,
Йөзен күрер көн булса,
Ни булса да булганмын.
Миһман[1] булып килепмен,
Хәйран булып йөрепмен,
Нурың төштә күрепмен,
Рәхим итсәң кирәкте.

[1] Миһман – кунак.

Атым минем Бүз егет,
Кашымда бар дус егет,
Бер кайгылы куш егет,
Рәхмәт итсәң кирәкте.
Чын хакыйкать яр булсаң,
Өйгә керсәм кирәкте,
Җаным сөйгән җананым
Йөзен күрсәм кирәкте».

Бүз егет туры айнәккә[1] килде, диде,
Кыз карап, егет йөзен күрде, диде.
Битендәге пәрдәсен ачып иде,
Шунда гашыйк ярын инде белде, диде.
Тунын киеп, хан кызы кадәм басты.
Йөгереп кызлар торып ишек ачты.
Учлап алтын-көмеш кулына алып,
Мәрвәрит мән мәрҗәннән чәчү чәчте.
Кочаклашып күреште гашыйк яры,
Кашында кырык кыз бар хезмәткәре.
Кызлар торып алдында «яр-яр» әйтеп,
Хан кызының табылды интизары.
Кызларның әйткән «яр-яр»ы:
«Әлхәм сүрә Коръәннең башындадыр, яр-яр,
Пәйгамбәрләр алланың кашындадыр, яр-яр.
Берең мәрвәр, берең мәрҗән, тезелепсез, яр-яр,
Берең хандыр, берең – ханча[2], яр булыпсыз, яр-яр.
Берең– тутый, берең– былбыл, яр булыпсыз, яр-яр,
Берең – алтын, берең – көмеш, туш булыпсыз, яр-яр.
Берең гөлдер, берең – йофар[3], хуш булыпсыз, яр-яр,
Берең айдыр, берең көндер, каерылмаңыз, яр-яр,

[1] Айнәк – тәрәзә.
[2] Ханча – хан кызы.
[3] Йофар (җофар) – кыйммәтле, хуш исле су җәнлеге.

Заман ахры булганчы аерылмаңыз, яр-яр.
Берең – гәүһәр, берең – якут, ярашыптыр, яр-яр,
Берең – тутый, берең – былбыл, сайрашыптыр, яр-яр.
Берең – хур кыз, берең– нур егет, бер торыңыз, яр-яр,
Заман ахры булганчы бер булыңыз, яр-яр.
Яр-яр әйтмәк борынгы өлгемез бар, яр-яр,
Терелектә бераз көн күргемез бар, яр-яр».

Кызларның «Яр-яр» әйткәнне ишетеп, ханның бер кол хатыны бу турыда патшага барып әйтә:

«Күп кызлар бер туй кылып ятыр икән,
Ике егет эчендә – аны күрдем.
Кызыңыз мән бер егет муендашып,
Ятыптыр так[1] өстендә куендашып,
Минем әйткән сүземә инанмасаң,
Караңыз, тәкъсир ханым, ишек ачып».

Хан бу турыда ишетеп, гаскәр алып килә, егетләрне үтерергә тели. Әмма Бүз егет дусты белән качып китә алалар. Ишетеп, хан кылычын кулына алды.

Ханның кызына әйткән сүзе:

«Ай, кызым, бу ни дигән шомлык? – диде. –
Атаңны инде кылдың моңлык, – диде. –
Кайдан азып йөргәнгә юлдаш булып,
Шәһәрдә кеше юкмы шунлык? – диде. –
И балам, иркәк тапмай шашканыңмы?
Җир йөзендә ханнарның улы юкмы?
Кайдан азып йөргәнгә юлдаш булып,
Коллар белән, чың[2] белән азганыңмы?

---

[1] Так – тәхет.
[2] Чың – кол.

Бу ни дигән башыма бәла салдың?
Мондый өлкән оятка кайдан калдың?
Йортыңда шундыйк ханлар углы юкмы?
Юлдан азып йөргәнгә кайдан калдың?»

Кызның атасына биргән җавабы:

«Колагым саңгырау булганда
Әйтсәң, сүзең окмамдыр,
Нинди яхшы тапсаң да,
Һич тә миңа якмастыр.
Гакылым баштан киткән соң
Гакылыңны алмасмын.
Барыбер килгән егетнең
Һич юлыннан калмасмын.
Атам, башымны алсаң да,
Зинданыңа салсаң да,
Бу ярымнан китмәсмен,
Йөзен күрми калсам да.
Бездән мәгъкуль кыз табып,
Үз иркеңчә кылырсың,
Йорттан яхшы таңлатып[1],
Сөйгәненә бирерсең.
Бу ярымнан башканың
Үлсәм йөзен күрмәсмен.
Бу егетне күрмәен,
Дәртемә юк дәрманым,
Йөзен күреп үлсәм мин,
Дөньяда юк әрманым».

Хан, кызына ачуланып, хан йортын җыя. Биләре ханга Бүз егетне ничек юк итәргә киңәш бирәләр.

---

[1] Таңлатып – сайлатып.

«Орышып, бу дошманны без ни итик?
Чакырып, кияү кылып, туй туйлатып
Үлтерсәк әмәл кылып, без ни итик?»
Биләрнең бу сүзенә бары күнде,
Күчәдәй савын әйтеп, атка менде:
«Егет-карың бу туйдан калмаң», – диде.
Ханчамызның күңеле инде тынды.
Ханчага сөенчегә берәү килде:
«Ник аерсын хан сездән сөйгән ярны,
Ярыңызга килсен дип хәбәр салың,
Туеңызда туйсын йортның карыны.
Атка менеп, хан үзе йөрмәк булды,
Туеңызның кызыгына кермәк булды,
Ярлык кылып йортына савын әйтеп,
Сөйгәнеңгә ул сезне бирмәк булды».
Кыз фәкыйрь, үтрек сүзгә ишанадыр,
Ярына, сәлам әйтеп, сүз саладыр:
«Туемызга Бүз егет килсен елдам», –
Кияү кылып, туйлатып чакырадыр.

Бүз егет туйга килә, аны эчереп үтерергә телиләр. Әмма вакытында бер дусты кызга ханның уен әйтеп, кыз Бүз егеткә качып китәргә булыша.

Бүз егет юлдашы мән китеп калды,
Артыннан күп гаскәр кумак булды.
Сансыз гаскәр, атына менеп алып,
Артыннан куып җитеп уртага алды.
Кыз, Бүз егетне уйлап, кайгыга кала.
Кыз, фәкыйрь, терелектән өмет өзмәс,
Шулай да көннән-көнгә йөзе сулды.
Дустын юклап, зар кылып иңгерәйдер,
Күрәменме дустымны, дип күп егълайдыр.
Биек тауның башында бер карлыгач

Баласына җим биреп асырайдыр.
«Карлыгач карлыгачка җим бирәдер,
Карендәш карендәшкә дим бирәдер,
Ялгызлыкка төште лә гариб башым,
Минем болай йөргәнне кем беләдер?
Елаганым белмидер атам минем,
Зарлыгымны белмидер анам минем,
Гариблеккә төшептер гариб башым,
Сорарга һичкем юктыр хәлем минем.
Бар икән безгә болай йөрер көннәр!
Зарлансам да, һичкем юк хәлем сорар,
Үз җаныдай асраган ата-анам,
Булырмы тагын бер көн сезне күрер?»
Агачның башын киссәң, төбе калыр,
Икәүнең бере үлсә, бере калыр.
Ялгызның үзе үлсә, нисе калыр?
Менгән аты, кигән туны ятка калыр...
Бу дөньяның эчендә үлмәй калган,
Булырмы уйлаганның барын алган?

Бүз егет дусты белән исән калып, яраларын дәвалап, кызга хәбәр бирәләр.

Дусты, карчык өенә җәяү килеп Карачәчкә:
«Аман ярың килде», – дип хәбәр бирде.
«Сөенчегә телләне алгыл, – диде, –
Кулыңга алтын йөзек салгыл», – диде. –
Карчыкка биш мең алтын бирмәк булдым,
Ярымны, барып, аннан күрмәк булдым.
Карчыкка биш мең алтын бирмәк булдым,
Ярымны, барып, аннан күрмәк булдым.

Хан кызын алам дип йөргән Зәйтүн исемле кеше, карчыкка күп акчалар биреп, Бүз егетне тота, зинданга сала. Үзе хан кызына өйләнергә җыена...

«Хан кызын алам! – дип куанадыр. –
Бу кызны миннән башка кем аладыр?
Бүз егетне зинданга салганнан соң
Күңеле суыр ханчаның», – дип уй кыладыр.
Хан иртән ярлык кылды: «Үлтереӊ! – дип. –
Базарга алып барып үлтереӊ! – дип. –
Дошманымның үлгәнен йортым белсен,
Дошман үлеп, дус күңелен тындырың», – дип.
Солдатлар асыл ирне алып барды,
Базарга ил җыелган уңнан, сулдан.
Бичара мас булып, акылы юк,
Әҗәлгә инде монда дучар булды.

Палачлар Бүз егетне үзенең кылычы белән үтерәләр. Карачәчсылу Бүз егетне эзләп йөри.

«Дөя килеп бузлайдыр,
Бутасы аның юк микән?
Бута күзле Бүз егет
Бу уенда юк микән?
Сыер килеп мөгрәйдер,
Бозавым, дип елайдыр,
Бичараның бозавы
Бу уенда юк микән?
Куйлар килеп мөгрәйдер,
Кузысы өчен иңрәйдер,
Бичараның кузысы
Бу уенда юк микән?
Җылкы килеп кешнәйдер,
Колыным, дип эзләйдер,
Бичараның колыны
Бу уенда юк микән?
Былбыл кошлар сайрайдыр,
Кызыл гөле юк микән?

Кызыл йөзле Бүз егет
Бу уенда юк микән?»
Тәрәзәдән бичара кыз җыр җырлайдыр,
Өй эчендә җәмәгать җыр тыңлайдыр.
Һич адәм хан кызы дип уйламайдыр,
Бичара һәркемгә бер иңрәйдер.
Күп эчендә бер адәм белде, диде,
Бичара хан кызы икәнен күрде, диде,
Бичара яры юктан йөргән икән,
Тәрәзәдән ярын юклап җавап бирде:
«Бу уенда юк чыгар.
Бүз егетнең толгасы
Яраланганга охшайдыр,
Дөньясының дәүләте
Тол калганга охшайдыр.
Ярыңнан хәбәр сорсаң,
Кайтмас җиргә киткән ул».
Ишетеп бу сүзне кыз җылап килде,
Атасыннан кыз, басып, сорап килде:
«Атам минем ау аулай барган икән,
Саугa бир, ата», – дип иңрәп килде:
«Кияү суеп, туй кылдың,
Кызың телең алырмы?
Бүз егетнең сөяген
Мең Зәйтүнгә бирмәсмен!
Акылы юк атамның
Кылган эшен кайтәен?
Үлгән ярым күрмәсәм,
Тере йөреп кайтәен?»

Ханның кызына биргән җавабы:

«Елама, кызым, елама,
Ил эчендә яхшы күп,

Илдән илгә йөрәен,
Сине аңа бирәен.
Телем, балам, каерма,
Сөйгәнеңчә кылырмын.
Алтынлы утау тектереп,
Хезмәтчеләр куермын.
Башымдагы таҗымны,
Астымдагы тагымны,
Кызым, сиңа бирермен.
Аргымакка менгезеп,
Мең кол, балам, бирермен.
Мең дөягә йөк артып,
Мең көң, балам, бирермен.
Дөнья йөзе киң, балам,
Табып алып бер яхшы,
Сөйгәнеңә бирермен».

Карачәчсылуның сүзе:

«Балаң күңеле калгандыр,
Арбасаң да булмас ул,
Нур егетен килтерсәң,
Аны да кабул күрмәстер,
Сөякләрем сынган соң,
Сыласаң да булмас ул,
Йөрәгем янып көл булды,
Су койсаң да сүнмәс ул.
Башым йиргә тигән соң,
Күтәрсәң дә булмас ул,
Күңел коштай очкан соң,
Кайтып кулга кунмас ул.
Сөйгән ярым киткән соң,
Нә кылса да булмас ул,
Эчем бозга тулган соң,

Йөрәгем таш булгандай,
Сүз сөйләсәң эремәс ул.
Күңелем бер калган соң
Ич әм ишетә белмәс ул.
Аргымакка менгезгән
Мең колыңны нитәен?
Кол хезмәте(н) көң иткән соң
Көңеңә хезмәт кылдырмай,
Үзем үк эшем кылырмын.
Алтынлы утау кылганчы,
Җирдән мула кылырмын.
Башыңдагы таҗыңны,
Астыңдагы тагыңны
Кулыма алып нитәен? –
Тагка ултырыр кешем юк.
Мал яхшысын нитәен? –
Алып менәр кешем юк!
Илдән илне аралап,
Тапкан яхшың нитәен?
Үз тапканым киткән соң,
Үзгә ярны нитәен?
Бездән соңгы кызыңны,
Кысыр калган биядәй,
Каемаган дөядәй,
Илдән илне аралап,
Илдән яхшы күренсә,
Алып, шуңа бирерсең».
Бичара кыз елай-иңрәй сүзен әйтте,
Атасының кашыннан зарлап китте,
Үлсәм, ярым юлында үләен, дип
Бер заманда шәһәргә якын йитте.
Бер заман дарга аскан күрде башын,
Бер көрсенеп, исе авып, йиргә төште,

Исен җыеп, канлы башны кулга алып,
Кан аралаш агызды күздән яшен.
«Хәйран башың, хан башың
Киселгәнгә охшайдыр,
Бәһасе юк гәүдәдән
Өзелгәнгә охшайдыр.
Гәүдәң канга болганып,
Аяк-кулың чолганып,
Кәфенең юк, гүрең юк,
Йирдә ятар ирме идең?
Канга башың болганып,
Болай ятар ирме идең?
Комга болгап башыңны,
Күздән аккан яшеңне
Йиргә агызар ирме идең?
Гәүһәр башың – хан башың,
Алтын дөньяң болганып,
Дарга асылыр ирме идең?
Йортыңда син хан идең,
Һәрбер эшең дан идең,
Дошманнарың кулында
Мондый булыр ирме идең?
Карагаттай күзләрең,
Кызыл гөлдәй йөзләрең,
Балдан татлы сүзләрең
Бер күрүгә зар булдым.
Әйтсәм, сүзем йитмәстәй,
Кайгың истән китмәстәй
Алыс юлга китепсең,
Чакырсам да килмәссең,
Зар кылсам да белмәссең!
Сездән дөнья үтептер,
Мин дә артыңнан үтәрмен.

Син алдымда булмасаң,
Бу дөньяны нитәрмен?
Көн дә елап йөргәнче,
Кайгың китмәс үлгәнче,
Бу кайгыны күргәнче,
Бергә булсам кирәкте!»
Бичара кыз дөньясын кулына алды,
Туркага канлы башны урап салды,
Үзеннән алтын-көмеш кулына алып,
Ярына там торгызу уена алды.
Кашына йөз егерме колын алды,
Алтын белән көмештән мула салды.
Бу муласын хан кызының белешкән соң,
Йортына: «Җыелың!» – дип хәбәр салды.
Йортына: «Кыз кашына барың! – диде. –
Ничек йөри кызым минем, белең! – диде. –
Кызымның бераз көндә күңеле суыр,
Кызымның кыл дигәнен кылың», – диде.
Күп гаскәр кыз кашына килде, диде,
Там торгызып куйганын күрде, диде,
Кыз боларның килгәнен яктырмады.
Гаскәрең бары кайтып йөрде, диде.
Кызыгыз там торгызып куйган икән,
Шәһәрдән зәргәр җыеп алган икән.
Бу шәһәрдә андаен өй табылмас,
Алтын белән көмештән салган икән.
Хан кызын күрүгә ояладыр,
Анасы, ялгызым, дип зар кыладыр,
Кашына бер-ике адәм юлдаш алып,
Чыдый алмай анасы бер барадыр...
Кызына, елап, ханым моңын әйтте:
Кылыптыр атаң сиңа «корбан гаете»...
Баласы анасына карамайдыр,

Оялып, анасы өенә кайтты.
Кыз инде там торгызып булды, диде,
Эченнән бигеткәндәй кылды, диде.
Кашында кырык кыз мән аманлашып,
Дала-җир күз яшенә тулды, диде.

Карачәчсылуның кызларга сөйләгәне:

«Яр-яр» әйткән яр-ярым,
Аман булың! Хуш булың!
Безгә үтәр көн булды,
Сездән китәр көн булды.
Аман инде, хуш булың!
Безгә үтәр көн булды,
Яр өчен үләр көн булды,
Сезгә калыр көн булды.
Бездән рәнҗү алганнар,
Бездән күңеле калганнар,
Уеңызга алгайсыз,
Риза булың, дусларым!
Борынгыдай булырсыз,
Сөйгән ярга барырсыз,
Уйнап-көлеп йөрерсез,
Аман булың, дусларым!
Тургайга җим табылыр,
Авыруга им табылыр,
Башыгыз яшь, дусларым,
Сезгә дә көн табылыр.
Минем өчен еламаң,
Миндәй бер кыз табылыр.
Терегә яр табылыр,
Үлгәнгә җир ябылыр.
Минем ярым үтептер,
Бу ялганнан үтептер,

Кил, дисәм дә, килмәс ул,
Зар кылсам да, белмәс ул.
Чын ярымнан калгым юк,
Ялган ярга баргым юк,
Бу дөньяда калгым юк.
Аман булың, дусларым!»
Атама әйтең сүземне,
Канлы яшь алды күземне,
Атама дөнья киң булсын,
Корбан кылдым үземне...»
Бичара кыз елай-елай тамга керде,
Терелектән үлгәнен яхшы күрде,
Там ишеген эченнән бикләгән соң,
Үз эченә үзе ул хәнҗәр орды.
Хан кызы яры белән кушылыптыр,
Газиз җаны гәүдәдән өзелептер,
Атасына йорты хәбәр иткәннән соң,
Кылганы хан(ның) туе бозылыптыр.
Хан, ишетеп, йортыннан елап килде,
Анасы битен ертып, иңрәп килде,
Тәмам йорт бу хәбәрне ишеткән соң
Өлкән-кече – мулага бары килде.
Еласа да, эш үтеп калган икән,
Ике ялгыз – дөньядан барган икән,
Ханым: «Мондый буларын белмәдем!» – дип,
Үз битен үзе тырнап ярган икән.

Бүз егетнең дусты аның ата-анасына кайта. Акын җыр белән Бүз егетнең дөньяда юклыгын аңлата.

«Күпне күргән кәрең мин,
Бераз җырны җырлаен,
Асмандагы тургайдай
Алдыңызда сайраен.

Өй эчендә утырган,
Колак салың, яхшылар,
Бу ялганнан файда юк,
Тәкъва булың, яхшылар!
Кәреңезнең сүзеннән
Гыйбрәт алың, яхшылар!
Кәреләрнең – иске сүз,
Искә алмый йөрмәңез,
Галимнәрнең күзле сүз –
Күңелгә алмый йөрмәңез.
Егетләрнең ялган сүз –
Җен, шайтаннан калган сүз.
Кәреләрнең хәер сүз –
Борынгыдан калган сүз.
Галимнәрнең гадел сүз –
Пәйгамбәрдән калган сүз.
Бер Ходайның дуслары
Күңелене алган сүз...
Җилгән аттан җир калыр,
Тапкан ирдин мал калыр,
Ир башыга көн туса,
Сөйгән ярдан ул калыр.
Патшалардан так калыр,
Мәргәннәрдән якъ калыр,
Ир башына көн туса,
Дөньяның бары юк калыр.
Галимнәрдән хат калыр,
Осталардан яд калыр,
Уйлап торсаң, яхшылар,
Бу ялганнан кем калыр?
Байларыңнан пол калыр,
Хатын булса тол калыр,
Тапкан ирдин мал калыр,

Алтын-көмеш, пол калыр.
Эттәй чаулап, талашып,
Кем күренгән, шул алыр,
Өең булса, буш калыр,
Уйнап йөргән дус калыр.
Туганмын дип куанма,
Туган үләр көн булыр,
Үлгән җанның барыннан
Сорау сорар көн булыр.
Малым күп, дип куанма,
Малны күрмәс көн булыр,
Алтын белән җир тулса,
Күзең салмас көн булыр.
Бер үзеңнән башканы
Күңелгә алмас көн булыр.
Телле мин, дип куанма,
Тел бәйләнер көн булыр.
Кылган эшең якмаса,
Тәмуг әйдәр көн булыр.
Көчем бар, дип уйлама,
Көчең китәр көн булыр,
Янган тәмуг өстеннән
Сыйфат үтәр көн булыр.
Дөньядагы колларыңа
Күзең салмас көн булыр,
Балам бар, дип куанма,
Бала да калыр көн булыр.
Галим мин, дип куанма,
Тиргәү алыр көн булыр.
Кылган эшең якмаса,
Залим син, дир көн булыр.
Кызыл йөзгә куанма,
Суелып калыр көн булыр,

Корт-кырмыска җыелып,
Туенып калыр көн булыр.
Патша идем, дип уйласаң,
Искәндәр[1] мән Сөләйман[2]
Алар да үткән дөньядан.
Балам күп, дип уйласаң,
Йөз кырык бала атасы
Адәм үткән дөньядан.
Малым бар, дип уйласаң,
Малы сездән күп чыгар
Карун үткән дөньядан.
Көчем бар, дип уйласаң,
Каһарман белән Гали[3], –
Алар да үткән дөньядан.
Чичәнмен, дип уйласаң,
Ничә-ничә чичәннәр
Сөйләп үткән дөньядан.
Ничә-ничә түрәләр,
Ничә-ничә яхшылар,
Елап үткән дөньядан!»
Хан алдында кәре чичән җыр җырландыр,
Сүзенең төбен ханга борды инде,
Җырлаучы бу җиргә килгәнендә
Хан, бер торып, урынына бер утырды:
«Чичәнем, яхшы икән җырың синең,
Үлем әйтеп чыгадыр кырың синең.
Җырыңның иңе-буе үлем икән,
Безгә карай тиядер кырың синең».
Җырчының җавабы:
«Тәкъсир, хан, үлемне әйтми, нине әйтәен?

[1] Искәндәр – Александр Македонский (безнең эрага кадәр 368–325 еллар).
[2] Сөләйман – пәйгамбәр.
[3] Гали – дүртенче хәлифә, 661 елда үлгән. Мөхәммәд пәйгамбәрнең кияве.

Бу җирдә әҗәл йитсә, мин нитәен?
Адәмнең ахыр-соңы үлем икән,
Чын әйтсәм, аны әйтми, нине әйтәен?..
Әҗәл дучар булган соң,
Чарамыз юк, нитәрмез,
Әмере килсә Алланың
Муен сонып китәрмез...
Әүвәл килеп юл ачкан,
Тәңре белән сөйләшкән
Адәм иде атамыз, Һавана ирде анамыз,
Бу дөньяда файда юк,
Алар да үткән дөньядан.
Туфан суы ташканда,
Таудан-таштан акканда
Һәр җәнлектән алып ул,
Кимә эченә калып ул,
Аман-исән калып ул,
Нух пәйгамбәр үткән дөньядан...
Унике угыл эчендә
Тоткын итеп яткырып,
Рәхмәт итте алласы,
Мисырның булды патшасы.
Йитмеш елның соңында
Йөзен күрде атасы,
Ахыр гомер хан булып,
Йосыф үткән дөньядан.
Йирнең йөзен алган ул,
Төрле шәһәр салган ул,
Көнчыгышка барган ул,
Көнбатышны күргән ул,
Гадел туган хан ирде,
Иир йөзенә фана иде,
Җаны үлемгә йиткәндә

Йирнең йөзе бозылып,
Көннең күзе тотылып,
Мәңге суын табалмай[1],
Егерме тугыз яшендә
Искәндәр үткән дөньядан...
Күзсезләрне күргезгән,
Аяксызны йөргезгән,
Егылганны торгызган
Әүлиялар үткән дөньядан...
Җир йөзенә килгәннәр,
Мин-мин, дәю йөргәннәр,
Мең яшь гомер сөргәннәр
Бары да үткән дөньядан.
Хан да үткән дөньядан,
Кара да үткән дөньядан,
Бай да үткән дөньядан,
Ярлы да үткән дөньядан.
Күп тә үткән дөньядан,
Аз да үткән дөньядан,
Яман-яхшыны аермай,
Бары да үткән дөньядан...»
Кәре чичән бу йиргә килде, диде,
Хан шомлыкның булганын белде, диде,
Терелекнең соңында бары үлем,
Алла әмеренә хан муен сонды, диде.
Әйтеп җырын, бу чичән тора килде,
Сүзенең төбен ханга бора килде.
Якынлатып җырыны борып иде,
Бер сүз инде әйтүгә туры килде:
«Яраткан хан барында
Хан киткәнгә охшайдыр,
Бүген күргән төшемдә

[1] Искәндәрнең мәңгелек суы эзләве турындагы легендага ишарә.

Сезнең дагы балаңыз,
Ул да үткәнгә охшайдыр.
Аннан соңгы безләргә
Кизәк якынайганга охшайдыр.
Балаңа, хан, елама,
«Бездән борын үтте», дип.
«Бу дөньядин китте», дип.
Алар китте Атага,
Ата белән Анага,
Сез дә бер көн барырсыз
Борын үткән балага.
Әҗәл җитмәй үлмәк юк,
Алла әмереннән калмак юк,
Әҗәл җитеп үлгән соң,
Һичкем кайтып килгән юк.
Тәкъдир җитсә, калмак юк,
Әҗәл куып алмак юк,
Әҗәл җитеп үлгән соң,
Һичкем барып алмак юк».
Хан, факыр, еласа да сабыр кылды,
Ялгызының үлгәнен инде белде,
Ханым угьлы үлгәнен ишеткән соң,
Битен ертып, зарланып, чәчен йолды.

*Бу әсәрне Ленинград Көнчыгышны өйрәнү институты китапханәсенең кульязмалар бүлегендә А-1547 шифры белән саклана торган кульязмадан әдәбият белгече М. Гайнетдинов күчереп алган. Әсәр «Татар халык иҗаты. Дастаннар» җыентыгында басылган.*

**Бүс егет**

Кыз егет каршында җырлый:

Миһырман моштак авылны
Бер күрмәй күңелем тынмай.
Җаным сөйгән ярымны
Бер күрмәй күңлем булмай.
Һай, Бүс егет, Бүс егет
Кашыңда бар тус егет
Чын хакыйкать яр булсаң,
Ишек ачсаң кәрәк, ди.

Кырык кәнизәк кыслар боларга каршы «Яр-яр» әйтәләр.

Берең энжү, берең мәрҗән
Тезелепсез яр-яр.
Берең якыт, берең гәүһәр
Кышылыпсыз яр-яр.
Берең еснә, берең енгә,
Кушылыпсыә яр-яр
Ахирәт көн булгынча
Аерылмагыз, яр-яр.
Яр-яр әйткән тусларым,
Тусымнан күп ишләрем.
Сез дуслардин аерылмасам,
Ялгыс пашым нишләрмен?

Кыз атасына болай дип җырлый:

Яры юкның чаны юк,
Түшәме юк, яр-яр.
Бүс егетем пулмаса,
Кысың да булып йөрмәсмен.

Атасы кызына җырлый:

Илдән илгә йөрермен,
Илдән яхшы табармын.
Илдә яхшы табылса,
Сине шуңа бирермен.

*1968 елда Омск өлкәсенең Тара районы Т. Сәбәләк авылында Таштимерова Фәүзиядән (1908 елгы) Халидә Гатина тарафыннан язып алынган.*

## Бүсьегет

Сәхипҗамал исемле бер кыс Бүсьегетне төшендә күреп гыйшыйк булган. Бүсьегетне эсләргә цыга пу кыс. Эсләргә цыкканда үзенң кәнизәк кысларга әйтә:

– Сезгә энче-мәрчән котлы пулсын, миңа юл котлы пулсын, ти.

Кысларга мәрчән сибә дә, үсе йулга цыгып китәте.

Кыс егетне җырлый-җырлый эсли:

Әй, Бүсьегет, Бүсьегет,
Ил эчендә ас егет.
Пулса пулсын Бүсьегет,
Ил эчендә ас егет, – тип.

Тус кысларын ияртеп, ер ерлап китеп утыраты.

Барып етсә, Бүсьегет үлеп ятаты, ти. Бүсьегетнең чапан астында пыцагы пулган, ти, пыцакны алып кыс үсенең күкрәгенә кадап үлгән, ти.

*1968 елда Омск өлкәсе Тара районы Хуҗавыл авылында Муратова Гайшәдән Халидә Гатина тарафыннан язып алынган.*

## Бүз егет




Ташла, ирегәм, ташла, ирегәм,
Ташла ташылыйсын килсәй.
Мин синий шуныта ташларым,
Тар каберләргә керсәм.

Бу балтамни чабып куйтым,
Талнын тамырларынай.
Ал гөлләр сибеп үстереӊ
Минем каберләремә.

Сандугачым сайрый-сайрый,
Канатын айрып тарый.
Ай, туганым, шунысы кыйын,
Күсен моӊайып карый.

Ташла, ирегәм, ташла, ирегәм,
Ташла ташылыйсын килсәй.
Мин синий шуныта ташларым,
Тар каберләргә керсәм.

*1968 елның июлендә Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Саургач авылында Шәрипова Хәтимә (1905 елгы, 63 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Бүз егет

Ник янасың яшь йөрәгем,
Бу эшләр гади генә;
Чөнки дуслар дус булалар,
Ак бәхет килсә генә.

Оныттыңмы Зарифәңне,
Төштә күргән йарыңны?
Әллә синең сөйгән йарың
Башка берәүне сөйтеме?

Мин сине көттем җиһанда,
Буз егет китә[а]лмадың;
Ничә тапкыр хат язсам да,
Урныңнан кузгалмадың.

*1968 елның 10 июлендә Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Ихсиңер (Эбаргуль) авылында Бакиев Гайнулла (1892 елгы, 76 яшь) җырлаган. И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган.*

## «Бүз егет» дастанының «Йар-йар» җырлары

### *Беренче җыр*




Сыктама, балам, сыктама,
Туйың булыр, йар-йар!
Сыйыр б...ктан сылаган
Өйең булыр, йар-йар!

Атинәңнең өйендә –
Агач бикләү, йар-йар!
Йат кешенең өйендә –
Тимер бикләү, йар-йар!

Ике йастык, бер түшәк –
Аз булмасын, йар-йар!
Чыгып карагыз кийәүне, –
Таз булмасын, йар-йар!

*1979 елда Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сабитова Сәрби (1895 елгы, 76 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

### *Икенче җыр*




Кысыл-кысыл краслар
Комта булыр, йар-йар!
Кыс алмаган йегетләр
Туйта булыр, йар-йар!

Кара сыйыр мөгесен
Каермагыз, йар-йар!
Әткәсендин баласын
Айырмагыз, йар-йар!

Чылтыр-чылтыр камышка
Сыргам төште, йар-йар!
Кыс алмаган йегеткә
Күңлем төште, йар-йар!

Түрт почмаклы өйемтә
Урным калты, йар-йар!
Түрт колаклый касанта
Өлешем калты, йар-йар!

Кызыл-кызыл этәчләр
Комда булыр, яр-яр!
Кызалмаган егетләр
Туйда булыр, яр-яр!

*1970 елда Төмән өлкәсе Ялутор районы Сәел авылында Булатова Гайниҗамал (1895 елгы, 75 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## *Өченче җыр*




Кара сыйыр мейгесен
Кайырмагыс, йар-йар!
Анасыннан баласын
Аермагыс, йар-йар!

Килер-китәр йулыңа
Киндер чәчтем, йар-йар!
Киндер китән[1] булганчы
Килмән, атам, йар-йар!

Ак төенгә төйгәнем
Алтынмите, йар-йар!
Айлык йиргә саткалы
Атаңмите, йар-йар!

Пәйгамбәрнен бер кысын
Али алты, йар-йар!
Тастармаллык[2] туй кылмак,
Шуннан калты, йар-йар!

---

[1] Китән – киндер, тукыма.

[2] Тастар – тастымал, сөлге; тастармаллык туй – бирнә күрсәтү мәҗлесе (?).

Бер чиләк бузаңыс –
Ас булмасын, йар-йар!
Кийәү башын ачып багың,
Тас булмасын, йар-йар!

Кара сыер мөгезен
Каермагыз, яр-яр!
Анасыннан баласын
Аермагыз, яр-яр!

*1968 ел Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Хәкимова Бәдигыйльҗамал (1900 елгы, 68 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## *Дүртенче җыр*




Кара сыйыр мөгесен
Кайырмаңыс, йар-йар!
Замана ахры җиткәнче
Айрылмаңыс, йар-йар!

Үнә күсе сынганта
Улыктырган[1] әнекәм;
Үнә сынлы мин киттем,
Инте тыңгыл, әнекәм!

Киер-китер йулыңга
Кинтер чәчтем, яр-яр!
Инте кинтер пешкәнче
Килеп китең, йар-йар!

---

[1] Улыктыру – ачулану.

Чыбылтыгым эченә
Чебен инәр, йар-йар.
Чыбычык буйлы йәш йегет
Йылып инәр, йар-йар!

Кара сыер мөгезен
Каермагыз, яр-яр!
Замана ахры җиткәнче
Айрылмагыз, яр-яр!

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Хәкимова Бәдигыйльҗамал (1900 елгы, 68 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

### *Бишенче җыр*




Вый! Җемеҗем җан[1], җилвандин[2],  
Сәнең дәртең – гамендин.  
Диванамын, йар-йар!  
Йар хәләтен белмәгән,  
Калыр йарсыз, йар-йар!

*1969 елда Омск өлкәсе Большеречье районы Үләнкүл авылында Рәшитова Рәбигадан (1903 елгы, 66 яшь) магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

---

[1] Җемеҗем – яраткан кешегә яки әйбергә карата кулланыла торган, яратып әйтә торган сүз.

[2] Җилвандин – сүзнең мәгънәсен таба алмадык.

## ***Алтынчы җыр***




Шутыр-шутыр камышта
Сыргам төште, йар-йар!
Сынамаган йат йергә
Сеңлем төште, йар-йар.

Түрт кулаклы касанта
Өлешем калты, йар-йар!
Түрт почмаклы өйемтә
Урыным калты, йар-йар!

Шытыр-шытыр камышта
Алкам төште, яр-яр!
Сынамаган ят җиргә
Сеңлем төште, яр-яр.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Мөхәммәтшин Аллаяр (1894 елгы, 74 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## ***Җиденче җыр***




Чыбындыгым эчендә
Чыбын уйный, йар-йар!
Бесгә төшкән кийәүләр
Мулла мигән, йар-йар!

Кара сыйыр мөйесен
Кайырмагыс, йар-йар!
Ахрысаман йеткәнче
Айрылмагыс, йар-йар!

Чыбылдыгым эчендә
Чебен уйный, яр-яр!
Безгә төшкән кияүләр
Мулла микән, яр-яр!

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Шагыр авылында Сабитова Салиха (1905 елгы, 67 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Сабитова Салиха – оста җырчы. Мәҗлесләрнең түрендә, бар җырларны да белә. Аннан җырлар самавыр борыныннан аккан су кебек бертуктаусыз агып тора.*

## Тайыр менән Сәүрә

Ике хан булды, Ал хан белән Көл[1] хан. Икәү сәелгә[2] цыкты бер сәхрәгә. Бер тауга бер көмәнле куян кацып инеп барадыр. Ике ханның өлкәне Көл хан игән. Ал хан әйтте:

– Ә, Көл хан, бу көмәнле куянны атаек! – диде.

Көл хан әйтте:

– Юк, минең хатыным өйдә көмәнле калды, мин атмаймын.

Ал хан әйтте:

– Минем хатыным да көмәнле калды, мин дә атмаймын.

Атмай куйдылар. Икәү хан сүз кыла:

– Икәү хатынымыз тап углан килтерсә, я, кыс килтерсә, икәвен дә дус кылаек. Бере кыз, бере ир булса, хәләл цебетлеккә[3] кушаек.

Берницә вакыттан соң өендән сөенце киләдер. Ал ханнан – ир бала, Көл ханнан кыс бала туды.

Ике хан әйтте:

– Инде кайтаек.

Ал хан әйтте:

– Әй, Көл хан, яшең өлкән, син алдан цап!

Көл хан цапты, үз өенә исән йитеп килде. Инде Ал хан өенә цапты, үз шәһәренә килеп, үз түбәсе астыннан аты өркеп егылды. Ал хан аттан төшеп үлде.

Ницә вакыттан соң, кыз ман егет үскәндәй соң, аларны укуга, мәктәпкә бирделәр. Ал ханның улының аты Тайыр булды, Көл ханның кызының аты Сәүрә булды. Сабак укыганда Тайыр Сәүрәнең кулын китапка кысты. Сәүрә инәсенә килеп әйтте:

– Ә, инә, Тайыр китапка кулым кысты.

---

[1] Көл дигәндә Гөл сүзе күздә тотыла.

[2] Сәел – хозурлык, матур көн.

[3] Хәләл цебетлек – хәләл җефетлек.

Инәсе әйтте:

– Ә, балам, син аталы бала. Ул Тайыр ятим, аңа сине бирмәбез. Син атаңа әйтмә, атаңа әйтсәң, атаң сине башка шәһәргә алып китәр.

Берницә вакыт соң Көл хан кызын алып, бер башка шәһәргә китте.

– Монда торсам, – диде, – кызымны ятим балага бирергә кәрәк. Мин кызымны ятим балага бирмәймен, – диде. Күцеп китте.

Бер көндә балалар уен кылып ятыр икән алтын ашык[1] белән. Ул алтын ашык ятим баланыкы игән. Тайыр (аның) янында торып, алтын ашыкны тартып алды. Бала елады. Өеннән баланың инәсе – бер корткаяк[2] елап цыкты:

– Минең баламның алтын ашыгын нигә тартып алдың? Моңдай көцле (булып) туган икәнсен, атаң саңа ярашкан кызны ник бушаттың?

Тайыр әйтте:

– Инәм маңа шулай әйтмәде.

Корткаяк әйтте:

– Синең инәң әйтмәс, кырык якалы тун тегеп ултырыр.

Тайыр сурады:

– Аны ни дип әйтәен?

Корткаяк әйтте:

– Кырык кыркын[3] узып бара, дип әйт! Ярмадан куырмац[4] куырып бир, дип әйт. Куырганда туз аягын[5] яшереп куй, андан соң инәң казандай суын алгандай соң, син эссе казанга инәңнең кулын бас, анда сурап тор: «Сәүрәне маңа ярашканмы? Тиз әйт, бушатырмын», – дип әйт!

---

[1] Ашык – кузна, куй аягының бер буын сөягеннән ясала.

[2] Корткаяк – карчык.

[3] Кыркын – кыз.

[4] Куырмац – куырылган җим.

[5] Туз аяк – туздан ясалган савыт, аяк.

Тайыр инде өенә кайтып барды, өенә килде.

– Я, инә, – диде, – кырык кыркын узып бара.

Инәсе ярма салып куырды, Тайыр туз аягын яшерде, эссе казанга инәсенең кулын басты:

– Тиз әйт! Сәүрәне атам миңа ярашканмы иде? Тиз әйтсәң, сине бушатам!

Инәсе түзәлми, әйтте:

– Бәәле[1], дөрес, ярашкан.

Инәсенең кулын бушатты. Тайыр әйтте:

– Ә, инә, инде мин китәмен Сәүрәне эстәп.

Инәсе әйтте:

– Юк, балам, китмә! Бер йома көт, шай[2], азык, тун кылаен.

Бер йомадан соң инәсе кырык якалы тунын кигезде, алтын әйкәрен[3] иңенә салды.

Инәсе өйдән торып цыгып, тышкары килеп кыцкырды:

– Өер башы айгырны апкилең!
Айгырны алып килделәр,
Иярне алып салдылар,
Йөгәнне башына суктылар,
Аелын, коешканын[4] тарттылар.
Бала менде айгырга,
Барып китте сәхрәгә.
Бала аннан киткән соң
Инәсе ултырып елады,
Елап-елап сыктады:
Баламны инде күрмәмен,
Баламны куып барып китәен,
Өйгә алып кайтараен!
Өер бияне апкилең!

---

[1] Бәәле – мәйле; билгеле.

[2] Шай – юл кирәк-ярагы.

[3] Әйкәр – панцырь.

[4] Коешкан – койрык астыннан иярне тарттыра торган бау, каеш.

Өер бияне килтерде.
Инәсе биягә менеп,
Үз шәһәрендән цыгып,
Баланы инде куып китте.
Үз шәһәрдән цыкканда,
Киң сәхрәгә йиткәндә,
Өер биясе кешнәде.
Айгыр мондан китмәде,
Айгыр кайры[1] карады.
Инәсе балага әйтте:
Кайт, балам! Кайт балам!
Бу юлдан син кайтмасаң,
Мин сине тагы күрмәсәм,
Бу өемдә тормаен!
Кыйгудан[2] цыкса кырык бүре,
Аннан ницек цыгарсын?
Айгайдан[3] цыккан алтмыш бүре,
Аннан ницек цыгарсын?
Цыцкан үтмәс цытырман,
Цытырманнан ницек цыгарсын?
Агынып[4] йитмәс ала тау,
Аннан ницек цыгарсын?
Кыелып яткан тиңесне[5]
Аннан ницек цыгарсын?
Тайыр цавап бирәде:
Бу барган ман барармын,
Кайтмасам да кайтмаен,
Юлда үлсәм – үләен,

[1] Кайры – артка.
[2] Кыйгу – су чите, ярындагы тар җир.
[3] Айгай – үсемлек.
[4] Агынып – менеп.
[5] Тиңес – диңгез.

Кыйгудан цыккан кырык бүрене
Кыйгу[1] салып цыгармын.
Айгайдан цыккан алтмыш бүрене
Айгай салып[2] цыгармын.
Цыцкан үтмәс цытырман
Алмас[3] салып үтәрмен.
Агынып йитмәс ала таудан
Киртмә[4] салып цыгармын,
Кыелып яткан тиңесне
Агацтан сал ясап цыгармын.

Инәсе әйтте:

– Ә, балам, син минең сүсемне тыңламадың, кил, балам, үбәен!

Баласы килде, инәсе үпте. Баягы инәсе үпкәннән соң бала әйтте:

– Кил, инәм, кецкенәмдә әллә туймадым, имцәк сөтеңне имәем! – диде.

Инәсе баланы түшенә какланды[5], бала имде. Инәсе әйтте:

– Риза булың, балам! – дип кайра[6] кайтты.

Бала менде атына,
Цыгып китте юлына,
Ницә таулар ашып китте,
Ницә сулар кицеп китте.
Кыйгудан цыкты кырык бүре,
Кыйгу салып цыкты бала,

---

[1] Кыйгу салу – кычкыру.
[2] Айгай салу – ай-һайлау, тавыш чыгару.
[3] Алмас салу – алмаз (кылыч) белән кисү.
[4] Киртмә – казып ясалган баскыч.
[5] Каклану – ябышу.
[6] Кайра – кире.

Айгайдан цыкты алтмыш бүре,
Айгай салып цыкты бала.
Цыцкан үтмәс цытырманнан
Алмас салып цыкты бала.
Агынып йитмәс ала таудан
Киртмә салып цыкты бала.
Кыелып яткан тиңестән
Агацтан сал ясап цыкты бала.

Мондан цыгып бер шәһәргә килде. Бу шәһәр баягы тиңескә якын икән. Иңендәге алтын әйкәре[1] менән шәһәрнең цитенә килде. Алтын әйкәрен иңендән алды, түңгәккә куйды. Шәһәргә керде, бер өйгә керде. Керсә, корткаяк ултырыр.

Корткаяк сурады баладан:

– Кайдан килгән кешесен?

Тайыр:

– Йетем-кареб[2] баламын,
Кешедән хәер сураймын.

Корткаяк:

– Юк, балам, син йетем түгел,
Бай бала булсаң, байга бар!
Син тик кеше түгел,
Би угылы булсаң, бигә бар!

Бала тагы әйтәде:

Бай угылы түгелмен,
Би угылы түгелмен,
Хан угылы түгелмен,
Йетем-каребмен, корткаяк,

---

[1] Алтын әйкәр – алтын божралардан ясалган яу киеме.
[2] Йетем-кареб – ятим, юлаучы, гариб.

Улсызга ул булаен,
Кызсызга кыз булаен!
Йетем-каребмен, корткаяк!

Корткаяк әйтте балага:

Угылсызга ул булсаң,
Кызсызга кыз булсаң,
Угылым юк, кызым юк,
Угылым бул, кызым бул!

Егет «ярайды» диде, корткаякка угыл булды. Көйләрдә бер көн егет цыгып караса, мәктәп (тә) укыган тавыш колагына инә. Корткаякның өенә кереп елый егет. Корткаяк әйтте:

– Ник елыйсын, балам?

Бала әйтте:

– Еламай ницек итәен? Монда мәктәп укыйлар игән. Ә, инәм, ниндәй мәктәп укыйлар?

Корткаяк әйтте:

– Кырык кыз укый.

Егет корткаяктан сурады:

– Мөңкөнлөк[1] булмасмы мин дә кереп угыгалы, моны ни кеше укыта?

– Монда бер хан килгән иде, аның кызы укыта.

Егет әйтте:

– Бар, инәм, ханга! Мөңкөнлөк булса, мине укырга сора!

Мондан соң корткаяк китте, ханга барды.

– Ханым, дат[2], – диде.

Хан әйтте:

– Датың булса әйт!

[1] Мөңкөнлөк – мөмкинлек.

[2] Дат (фарс.) – зар, кайгы, үтенү.

Карчык әйтте:

– Датым шулдыр, бер угылым бар иде, мөңкөнлөк булса, шул угылым сорый укырга.

Хан әйтте:

– Мөңкөн.

Мондан кайтты корткаяк өйгә куанып:

– Я, балам, – диде, – әзерлән! Хан боерды укырга.

Корткаяк баланы мәктәпкә кергезде. Анда кырык кыз бар икән, кырык беренце – ханның кызы булды. Егетнең көненә укымышы зур икән, көнендә бер кызны уза, кырык көндә кырык кызны узды. Кырык беренце көнендә Сәүрә кашына барды, сабак алды. Кырык икенце көнендә егет сабак бирә Сәүрәгә, кырык өценце көнендә Сәүрәгә ашыйк булды.

Аннан соң Сәүрә әйтте аталарына:

– Минем укымышым йитте, кырык кызны алсын!

Мондан соң Сәүрәнең атасы бер кешене йибәрде:

– Ницек кызым өенә кайтмаган? Башка кызлар өйләренә кайтты. Кызым ницек йөри?

Йибәргән егет караса, Сәүрәнең егет менән икәнен күрде. Ханга килеп, күргәнен әйтте. Хан ацу тотты:

– Ул ниндәй егет икән минең кызым янында? Мин аны астырырмын, я башын цаптырырмын.

Ханша әйтте:

– Астырма, башын цаптырма, ул да тик егет түгел.

Хан әйтте:

– Моны ни кылабыз?

Ханша әйтте:

– Арыкцылар арык казысын, тиңеснең суын кызның өенә килтерсен! Осталарыңа боер, сандык кылсын, ултырса – башы тимәсен, сонса[1] – аягы тимәсен, эце көмеш булсын, тышы алтын булсын, эценнән ацкыцы булсын, су кермәсен!

---

[1] Сонса – сузса.

Хан ханша әйткән сүзне тыңлады:

– Ярый, – диде.

Арыкцылар килде, арык казып, суны китерделәр тиңестән кызның өенә. Осталар сандыкны алып килделәр кызның өенә. Хан кеше йибәрде Тайырга, баягылар әйтте:

– Хан сине каргады, бу сандыккаултырсын, дип боерды.

Тайыр әйтте:

– Бу сандык белән кайда барамын?

Кешеләр әйтте:

– Сине тиңескә йибәрәмес.

Егет сандыкка ултырды, сандыкны япкалы иттеләр.

Егет әйтте:

– Туктаң! Япмаң! Әйтәтеген цавап бар хатыныма, – диде.

Кызга егет әйтәде:

Сарыслан[1] туным, туным йиңсез,
Сагышым күптер синсез.
Тар шарбакның[2] эцендә
Ницек ятарсын минсез?

Кыз цавап бирәде:

Сарыслан туным йиңсез,
Сагышым күптер синсез.
Тар сандыкның эцендә
Ницеккә ятарсын минсез?

Инде егетне сандыкка бикләде, ыктырып[3] йибәрде тиңескә бетмәс азык белән. Кыз кияүсез өйдә калды.

Егет сандык эцендә барып ултыра. Бер шәһәр бар икән. Шул шәһәрдә бер хан бар икән, шул ханның өц кызы бар икән.

[1] Сарыслан – сары ас, сасы көзән.

[2] Шарбак – кала; читән; беседка.

[3] Ыктырып – агызып.

Көйләрдә бер көн шул өц кыз шул тиңескә суга төшеп яты[1] икән. Суга төшеп, тиңеснең уртасы белән киләдер бер сандык.

Иң олы кызы торып әйтте:

– Күрдеңесме шул сандыкны? Атабызның хәзинәсенә төшеп алам.

Йөзде, йитә алмады. Уртанцы кыз йөзде дә йитә алмады. Иң кецесе йөзде, йитте. Сандыкны тиңес якасына апкилде. Үзенең хезмәткәр кызын атасына йибәрде.

– Кызыңыс хәзинә тапты, – диде.

Атасы боерды:

– Өц кыз яши торган өенә бу сандыкны аппарыңыз!

Шул төн шул сандыкның эценнән бер егет цыкты. Өц шамның[2] ярыклыгын[3] йөз ярыгы басты. Моннан соң кыз атасына әйтте:

– Ушы сандыкның эценнән бер егет цыга, өц шамның ярыклыгын йөз ярыгы баса. Моны бу сандыктан алып миңа бирсәң иде.

Атасы килде останы алып.

– Бу сандыкны капъяра[4] кис! – диде.

Бу сандыкны капъяра кисте. Ушы сандыкның эцендән бер егет цыкты, шулай сылу. Мондан соң кыз сурады атасыннан:

– Я, ата, бу егетне миңа хәләл цеп[5] кылгын!

Атасы моны хәләл цеплеккә кушты кызга. Егет моны хуш күрмәде. Алты төн, алты көн үтте, егет бер айланып карамады. Кыз ацу тотты, атасына әйтте:

– Адәмгә бирдеңме, хәйванга бирдеңме? Алты көн, алты төн үтте, бер айланып карамады.

Мондан соң атасы кызыннан ишетеп ацу тотты.

---

[1] Суга төшеп яты – су коена.

[2] Шам – шәм.

[3] Ярык – яктылык.

[4] Капъяра – урталай.

[5] Хәләл цеп – хәләл җефет (гар.).

– Я астырам, я цаптырам! – диде.

Ханша әйтте:

– Астырма, башын цаптырма! Сынданга ташла!

Мондан соң сынданга ташлады егетне. Ханша ханга әйтте:

– Сынданга ташладың егетне, инде иртәге намазга шул егетнең өстенә тәһарәт ал, ул саңа бер цавап бирер.

Хан барды тәһарәт алгалы. Егет тәһарәт алырын белде. Егет әйтте ханга:

Һауа ауама иде? – диде.
Кар-яңгыр яуамы иде? – диде.
Хан бабай шәһәрендә
Кыз өцен үлмәк вафама[1]? – диде.

Хан иртәнге намазга тәһарәт алуын куйды, йөгерде ханшага. Ханша әйтте:

– Ник тәһарәт алмай килдең?

Хан әйтте:

– Тәһарәт алмай килгәнемнең сәбәбе шулдыр: егет сындан эцендә шулай-шулай сүз әйтте.

Ханша торып әйтте:

– Тик[2] атаның баласы түгел, дип әйттем куй. Тиз алдыра куй, кызыңа (алып) кайтып куш!

Хан егетне алдырды, кайтып кызына кушты.

Сәүрә ханша өендә калган иде. Ул кырык пәрине йомышка кушты. Кырык пәрине йыйдырды. Сәүрә боерды ике пәридән шәһәрмә-шәһәр йөргәле.

– Тайыр патшаны табып, маңа килтереңез, – диде.

Кырык пәри шәһәрмә-шәһәр китте. Тунны ак цикмәннән кигезде, такъяларын[3] кызыл төлкедән ясады. Инде киттеләр пәриләр эстәп.

[1] Вафа (гар.) – тугрылык, сүздә тору.

[2] Тик – гади.

[3] Такъяларын – бүрекләрен.

– Тайыр патша торган шәһәрдә патша булды, кайнатасы кырык хәзинәсенең ацкыцын бирде, үзе ултырган урынын бирде.

Көнләрдә бер көн Тайыр патшасы кырык хәзинәнең ацкыцын тота цыкты. Кырык хәзинәсенә килсә, халык күптер. Бу халык Тайыр патшаны күргәц, ярылып[1] тордылар. Шуның эцендә ике кеше ак цикмән кигән киләдер. Йырлап килделәр. Тайыр патша моны тыңлады. Ике кеше турыга йиткән соң, тукталды. Тайыр патша әйтте:

– Нигә тукталдыгыс, егетләр, йырлай торган йырыгыз булса, йырлаңыз!

Болар йырладылар:

Без килдек кәрван булып,
Йөрибез хәйран булып,
Эстәйбес, Тайыр патша юк,
Йөрибез хәйран булып.

Патша бу пәриләрне тыңлады.

– Килеңез, егетләр! – диде.

Кырык хәзинәнең ацкыцы менән кырык хәзинәне ацып керде, һәр төрле йимеш алды һәм боларга ашатты, һәм яулык тулы алды, кырык хәзинәдән цыкты.

– Я, егетләр, мине кем дип беләсез? – диде. – Тайыр патша миндер, – дип белдерде.

Ике кеше әйтте:

– Хәзер без сине алып китәбез.

Тайыр әйтте:

– Туктаң, егетләр, мин монда өйләнгәнмен, мин бараен өемә, мин керәен өемә, кинәшим хатыным белән. Андан соң цыгармын. Уң аягымны бисмилла дип бассам, мине алып китеңез! – диде.

[1] Ярылып – юл ярып.

Тайыр яулык тулы йимеш менән хатынына керде. Цавап бирде хатынына:

Мин килдем инештән,
Яулык тулы йимештән,
Сәүрәдән хат-хәбәр килде,
Рөхсәт бирген бер эштән.

Яулык тулы йимешне хатынына бирде. Хатын һичбер цавап әйтә алмады.

– Я, хатын, син миңа риза бул, һичбер цавап бирә алмадың, риза-бәхил бул!

Ишекне тотты, кыял[1] булып китте. Мондан соң хатыны сыктады.

– Ирем каип булып[2] китте, – дип, атасына барды.

Атасы һәрбер якка цаптырды, эстәде, табалмады.

Иртәге көн Тайыр Сәүрәгә килде намаз вакытта. Сәүрә ятыр йоклап.

Тайыр әйтте:

Мин килдем зуһүр[3] вакытта,
Сәүрә ятыр тактада.
Цәр[4] корып уяталмаймын,
Ни күп ятыш бу вакытта?

Тайыр тиңес белән киткән вакытта (патша) Сәүрәне бер Кара Батыр дигән ханның угылына ярашкан игән. Бу Кара Батыр кайныннан сурады:

– Ә, кайным, кызыгызны мин күргәнем юк, барып күрсәм иде, – диде.

---

[1] Кыял булып – «югалып»мәгънәсендә.

[2] Каип булу – гаип булу, югалу.

[3] Зүһүр – икенде, кичкырын.

[4] Цәр – сәра, чатыр; пәрдә; павильон.

Кайны әйтте:

– Яхшы бар, бар! – дип боерды.

Кара Батыр барды Сәүрә кызны күргәле. Килсә, кызның кашында бер егет ятыр. Кара Батыр әйтте:

– Бу ни эш булды? Берәү рузасын тотып, берәү гаетен кылар? Тукта, мин моңа цавап бирәен.

Кара Батыр әйтте:

Кыргый цөйдем һавага,
Алды төште бакцага.
Шул кыргыем югалды дип,
Сураулар салдым барцага.

Тайыр уянды, Сәүрәгә әйтте:

– Бу ни? – диде.

Сәүрә әйтте:

– Син киткәннән соң Кара Батыр дигән ханның угылына мине ярашты. Шул Кара Батыр килде.

Тайыр патшасы әйтте:

– Тукта, мин аңа цавап бирәен!

Тайыр патша Кара Батырга цавап бирде:

Кыргыең цүсә (чөйсә) булмасма?
Талдан (о) цып цыгармасма?
Борынгы сәүгән Сәүрә ханышны
Инде сәүсә булмасма?

Кара Батыр аңа ачуланды, китте. Барды инде кайнына:

– Рузасын берәүгә тоттырып, гаетен берәүгә кылдырасыз икән, – диде.

Хан моңа ацу тотты, ат йиктерде, кайтамын дип. Кайтты өенә. Кайтканда әйтте:

– Моның башын инде мин чаптырамын.

Ханша елады, әйтте:

– Башын цаптырма!

Хан боерды йәлләтләргә[1]:

– Тайыр патшаны баш цабатыгын[2] йиренә апкитең!

Баш цабатыгын йиренә апкиттеләр. Андан соң хатын Сәүрә сыктады.

Кәтәр-кәтәр[3] биләр килде, кәтәр-кәтәр вәзирләр килде Тайыр патшаны үлтерүгә. Менә цыкты Сәүрә ханыш каршына. Ханыш әйтте:

– Баягы Тайыр тик кеше түгел, хан атамнан үтенеп алың!

Кәтәр-кәтәр вәзирләр
Кәтәрләшеп үтәрләр.
Тайырым тик кеше түгел.
Хан атамнан үтенеп алың!
Ай татарлар, татарлар!
Тайырның башын сатарлар.
Тайырым тик кеше түгел,
Хан атамнан үтенеп алың!

Ханыш елаганын ишетеп, биләр барды, вәзирләр барды, татарлар барды, ханнан үтенеп алырга. Хан аларның һицбер сүзен алмады. Кыз инде үзе китте атасының өенә. Чәчен өзде, йөзен ертты. Күпме сураса да, атасы һицбер сүзен алмады.

Атасына әйтте:

Ә, атам, сүзем алмайсын,
Бу Тайырны салмайсын,
Өстеңә кигән туның
Кибенеңә[4] ярамасын!

---

[1] Йәлләт – җәллад-палач.

[2] Цабатыгын – чаба торган.

[3] Кәтәр-кәтәр – бергә-бергә, төркем-төркем.

[4] Кибенеңә – кәфенеңә.

Анасына әйтте:

Ә, инәм, сүзем алмайсын,
Бу Тайырны салмайсын,
Башыңа кигән яулыгың
Кибенеңә ярамасын!

Хан кызына мойрылды[1], бер кешене йибәрде:

– Бар вәзиргә, Тайырның башын цапмасын, дип әйт! Мин кицтем.

Баягы кеше йитмәде. Тайырның башын цаап[2] ташладылар. Тайыр патша үлгән соң бицә[3] кайгырды. Атасына ацуланды, ацуланса да, белдермәйде. Андан соң Сәүрә ханыш атасына әйтте:

– Кырык кызымны йыеп бир, күңлемне ацаен! Кырык хәзинәң ацылсын, хәзинәңне күреп, күңлемне ацаен!

Атасы кызының сүзенә шатланды, кырык кызын йыйдырды, кырык хәзинәсенең ацкыцын бирде. Кыз хәзинәгә барды. Куеныңа-куныцына йенце-мәрвәр[4] куйды. Кырык кызын алып китте. Андан соң сыктап, Тайыр баш(ы) цапкан йиренә йитеп килде. Моннан кырык кыз курыкты. Ханыш елап-сыктап кызларга әйтте:

Килең, кызлар йөрешәек!
Йенце-мәрвәр цацышаек[5]!
Йенце-мәрвәр цацышкан соң
Бер Тайырга йитешәек!
Килең, кызлар йөрешәек!
Йенце-мәрвәр цацышаек!

---

[1] Мойрылды – йомшарды, миһербанлыланды.
[2] Цаап – чабып.
[3] Бицә – хатын.
[4] Йенце-мәрвәр – энҗе-мәрҗән.
[5] Цацышаек – чәчешик.

Йенце-мәрвәр цацышкан соң,
Без-быцак[1] цәнцешәек!

Кызлар ятып калды, курыкты. Сәүрә йенце-мәрвәр алып цацаты. Кызларны цагырды[2], кызларның бисләрен[3] сөйде.

– Ә, кызлар, – диде, – кайтыңыз өегезгә! Өегезгә кайтып сүз кылмаң!

Мин Тайырга барам.

Кызлар сыктап кайтты.

Сәүрә Тайырга барды. Башын ипләде[4]. Үсе быцагын кулына алды, быцагын күкрәгенә салды, коцаклады Тайырны, быцак үс күкрәгенә керде, Сәүрә үлде.

Баягы Кара Батыр килде. Кара Батыр аны күреп әйтте:

– Бу ялган дөньяда күрмәдем сине, цын дөньяда күрерменмә?

Тайырдан тартып алды Сәүрәне, Сәүрәнең күкрәгеңдәй быцак алды, үс күкрәгенә салды, Сәүрәне коцаклап үлде.

Кара Батырның атасы улының үлгәнен белде. Сәүрәнең атасына әйтте:

– Сәүрә менән Кара Батырны бер гүргә сал!

Сәүрә менән Кара Батырны бер гүргә салдылар. Тайырны үзен башка күмделәр. Берницә көйләрдән соң гүргә килсәләр, Тайырның гүре ябык, Сәүрәнең гүре ацык. Тайырның гүрен ацып карасалар, Тайыр менән Сәүрә коцаклашып ятыр. Кара Батыр менән Сәүрәнең гүре тагы ацык, Тайырның гүре ябык. Мондан соң Кара Батырның атасы ацу тотты:

– Сөймәс кызыңны минең улыма бирелсен, бу Тайырны тиңеснең ул ягына апцыгып куй, Кара Батыр мән Сәүрәне бер гүргә сал!

---

[1] Бес-быцак – без-пычак.

[2] Цагырды – чакырды.

[3] Бисләрен – барысын (рус. – весьләрен).

[4] Ипләде – көйләде, китереп куйды.

Кара Батыр мән Сәүрәне бу йирдә күмделәр, Тайырны тиңеснең ул ягына алып цыктылар.

Кырык көннән соң цыксалар, Алланың пәрманы менән, Тайырның баш ягындан бер тирәк үсепте, Сәүрәнең баш ягыннан бер тирәк үсепте. Сәүрәнең баш ягындан үскән тирәк, Тайыр баш ягындан үскән тирәк, Алланың пәрманы менән, ялгашып торыптыр тиңес аша. Бу тирәкнең башында ләкләк менән былбыл уйнап ятыр. Карасалар, Тайыр патша менән Сәүрә ханыш, Тайырның иңендә алтын әйкәр, Сәүрәнең башында ал киләбәц[1], ал яулыгы кулында, ләкләк белән былбыл арасында йөрделәр. Кара Батыр аннан ерак, карга менән козгынның арасында кыркылдашып бергә йөрде.

*1860 елларда академик В.В. Радлов тарафыннан Тобольск янындагы Саусхан авылында (хәзер ул авыл юк) язып алынган.*

*Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен,живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. С. 274–286.*

[1] Киләбәц – кызлар баш киеме.

## «Таһир-Зөһрә» дастаны көйләре

### *Беренче көй*




Кысыл алма айагың,
Сафы көмештәй сөйәгең;
Гәүһәре йакут беләгең,
Күрәр күңлем буларма?

Күп сар булган күргәли,
Риса булган үлгәли;
Таһир жаның килгәнтур
Гөлйөзеңне күргәли.

*1971 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Лаймтамак авылында Бәхтиева Сәрвәр (1900 елгы, 71 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## ***Икенче көй***




*Хан кызы:*

Таһире затыңы пәримә,
Фирештәме, хурийма?
Бу йаралган җисемегес
Йәшел җәүһәр нурыйма?

*Таһир:*

Мин Зөһрәнең йарыйман,
Кара зөлфи[1] дариман;
Синең гүзәл хөснеңә[2]
Хәйран булып карыйман.

---

[1] Зөлфи – зөлф, биткә төшкән чәч бөтеркәсе.
[2] Хөсне – хөсен, матурлык, гүзәллек.

*Хан кызы:*

Синең өчен зар микән,
Сине сөйәр йар микән?
Бер хуп назар[1] кыйл сана,
Зөһрә миндәй бар микән?

*Таһир:*

Сәрви назым минем йук,
Хөснеңә һич сүзем йук;
Гакылым Зөһрә алгандар,
Сине күрер күзем юк.

*Хан кызы:*

Мәгъсүманә[2] һәр җирем,
Нәзек, зифа бу билем;
Ирнем шифа хәстәңә,
Дәрткә дәрман һәр җирем.

*Таһир:*

Матур булсаң мең һазар,
Берен кыйлмам ихтияр;
Зөһрә белән вәгъдәм бар,
Һич сөймәс мән бүтән йар!

*1969 елда Таминдаров Сәгыйрь (1889–1975) җырлаган. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Халык музыкасы кабинетында магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган һәм нотага төшерелгән.*

*С. Таминдаров һәм аның дуслары әле революциягә кадәр үк Кемерово өлкәсе Юрга районы Эскәтем авылында «Таһир-Зөһрә» пьесасын куйганнар. Таһир ролен С. Таминдаров үзе*

---

[1] Хуп назар – матур караш, җылы караш.
[2] Мәгъсүманә – гонаһсыз, керсез, кимчелексез.

*уйнаган һәм җырлаган. Зөһрә ролен аның тормыш иптәше Гөлсем ханым уйнаган. Спектакльне карарга авыл муллалары да килгән. Спектакль кем әсәре буенча куелгандыр, анысын хәзер әйтү кыен. С. Таминдаров ул турыда мәгълүмат калдырмады, һәрхәлдә, төп сюжет линиясе итеп Әхмәт Мөхәммәтзариф улы Уразаев-Курмашиның «Таһир илә Зөһрә кыйссасы» яки Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе алынгандыр. Беренчесе 1876, 1911 елларда Казанда басылса, икенчесе 1916–1917 елларда язылган.*

*Җыр тексты, аз гына үзгәрешләр белән, Курмаши әсәрендәге текст белән тәңгәл килә. Тик анда 5 (нче?)куплет кына юк.*

*С. Таминдаров – Ленин орденлы укытучы. Гомеренең соңгы елларын Казанда үткәрде. Тумышы белән Кемерово өлкәсе Юрга районы Эскәтем авылыныкы. Әтисе чыгышы белән Чистай ягыныкы. Себергә килеп өйләнә. С. Таминдаровның әйтүенчә, әнисе Алтай ягыныкы. Чөнки ул курчакка табына торган булган.*

*С. Таминдаров – искиткеч моңлы, катлаулы мелизм бормасырмаларын гаҗәеп төгәл көйләүче түбән тавышлы (бас) җырчы.*

*Кемерово өлкәсе Юрга районы Эскәтем һәм Кышлау авылларында үзләрен калмак-калмыгышлар дип йөртүче себер татарлары яши. Картлар әйтүенчә, аларның бабалары монголлардан аерылып китеп, шушы җиргә килеп утырган. Боларның арасыннан Тарантасов фамилияле кеше Ак патша Михаил Федоровичка буй сынырга дип барган һәм шуның бәрабәренә ул Мәскәүдән тирә-як җирләргә кәгазъ-грамота да алып кайткан икән.*

*1969 елның көзендә Тел, әдәбият һәм тарих (ТӘһТИ) институты фәнни экспедициясе вакытында мин Эскәтем авылында язмалар эшләдем һәм шактый үзенчәлекле җыр хәзинәсенә тап булдым. Бигрәк тә туй йоласына караган «Кыз елату» һәм «Ишек бавы» җырлары безнең өчен зур табыш булды.*

*«Казачий бәете» һәм «Җир бәете»ндә 1905 еллардан соң Столыпин чорында бу якларга күчеп килгән «килмешәкләр» – «ак чабаталар»ның ничек итеп калмакларны алдалап һәм куркытып җирләренә хуҗа булулары сөйләнә.*

*Боларның барысын да миңа Сәгыйрь абый Таминдаров сөйләде. Сәгыйрь абый күренекле нәфис сүз остасы Айрат Арсланов һәм аның хатыны диктор Мәрьям Арсланова белән дустанә иде. Мәрьям апа – Сәгыйрь абый белән якташлар, ул Кемерово өлкәсенең Саз авылы кызы иде.*

*1969 елда, Казанга кайткач ук, мин Сәгыйрь абыйның Фрунзе урамындагы агач йортын эзләп таптым. Искитмәле таза, нык гәүдәле бу кешенең бик тә мөлаем һәм сыгылмалы бас тавышы минем күңелемдә илле елга якын яңгырап тора. Шунысын да искәртеп үтим: татар халкында бас тавышлы җырчылар бармак белән санарлык та юк. Казакъ халкында алар тулып ята. Хикмәт нидә икән? Дала? Тау? Башкорт халкында гел тенор һәм сопрано.*

*1969 елда мин үземнең тәҗрибәсезлегем аркасында бу табылдыкка әллә ни әһәмият биреп тә бетермәгәнмен. Бу менә нәрсә турында сөйли: ерак Себердәге гап-гади бер татар авылында революциягә кадәр мәдәният учагы дөрләп торганын күрсәтә.*

*Сәгыйрь абый Таминдаровтан «Тау башында таш тегермән» дигән тагын бер җыр язып алу бәхетенә ирештем мин. Заманында бу җырны «Татарстан» радиосыннан Таһир Якупов җырлады, хәзер Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылыннан Казанга килеп, күренекле җырчы булып өлгергән Закир Шаһбан җырлый.*

*Менә шулай...*

*И. Кадыйров*

## ***Өченче көй***




Әйтә, гыслар, үтәлек, тите,
Шат суына төшәйек.
Тәртле Таһир, инә тор,
Мәкертенә ишәйек, тите.

*Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур тибенде авылында Мәди Әбүсәгыйтов (1895 елгы) сөйләгән дастан назымы. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Сәйфелмөлек

Борын-борын заманда, ханнар яшәгән заманда, яшәгән бер бабай. Ул бабайның бик матур, күркәм йөзле, нечкә билле, зифа буйлы тал кебек Сәйфелмөлек исемле улы булган. Сәйфелмөлекнең әтисе яуларда күп йөреп, дан алган, төрле илләрдән, төрле җирләрдән фотопортретлар китергән. Көннәрдән бер көнне Сәйфелмөлек әтисе бүлмәсенә кергәч, бер фоторәсемне күрә. Анда бик матур бер кыз була. Сәйфелмөлеккә уй төшә: бу кызны эзләп тапсам иде, ди. Сәйфелмөлек бу кызга гашыйк була.

Көннәр үтә, Сәйфелмөлек әнисе-әтисенә хәбәр итә:

– Әти-әни, мин сәфәр чыгып, дөнья күреп килер идем, – ди. Әти-әнисе дә каршы килмичә рөхсәт бирәләр. Егетне юлга хәзерлиләр. Әтисе юлына алтын балдак бирә:

– Улым, төрле куркыныч хәлләргә туры килгәндә менә бу алтын балдак сиңа файда итәр, – ди.

Егет алтын балдакны кулына кия. Әти-әнисе фатиха кылып, озатып калалар. Егет чыгып китә. И китә, и китә, бик күп җирләр үтә. Менә бер заман бер шәһәр күренә. Бу шәһәрдә шундый зур таш йортлар салынган, зәңгәр болытларга терәлгән зәңгәр таш йортлар, ак болытларга терәлгән ак таш йортлар. Ләкин шәһәрдә бер тавыш юк, тып-тын. Тик елганың шаулап аккан тавышы гына ишетелә.

Зур йортка килеп җитә егет, биек баскычлардан күтәрелә, ләкин ишек йозаклы була. Ничек ачарга ишекне? Исенә төшә:

– Тукта, минем әти биргән алтын балдак бар бит.

Алтын балдакны зур йозакка тидерә. Ишек шылтырап ачылып китә. Өйгә керә. Керү белән бүлмәнең нәкъ уртасында, ефәк пәрдәләр эчендә бик матур бер кыз йоклап ятуын күрә. Кызны уятып карый, кыз һич уяныргa теләми. Нишләргә?

Карый егет, кызның баш астында яшел такта ята. Яшел тактада сүзләр дә язылган була. Тактаны тартып алу белән кыз уянып китә. Кыз уяна да, куллары белән күзләрен угалап:

– Сез адәм егетеме, җен егетеме? Монда кошлар да очып килеп җитә алмый торган җирләргә сез ничек килдегез? – дип сорый.

Егет:

– Адәм егетемен, – ди.

Кыз тора, киемнәрен кия, юына. Сөйләшә башлыйлар. Егет кызның ничек монда килүе турында сораша башлый. Кыз сөйли:

– Мин фәлән ханның иң кечкенә, өченче кызы идем. Нәкъ унсигез яшемдә мине бирегә дию пәрие урлап килде. Мин хәзер биредә яшим. Ә дию үзе Каф тавы артына еракка-еракка сәфәргә чыгып китте, – ди.

Кыз егеткә ашлар хәзерли, егет юлдан арып-талып килгән. Егет ашый. Кыз егеттән сорый башлый:

– Әгәр мөмкин булса, мине дә үзең белән алып китсәң иде, – ди.

Ә егетнең түш кесәсендә этисе бүлмәсеннән алган фоторәсеме була. Бу рәсемне кызга тиңләштереп карый егет, ләкин охшамый. Рәсемдәге кыз бу кыз булмый. Егет кызның исемен сорый. Аның исеме Мәликә була. Ә егет үзенең Сәйфелмөлек икәнлеген әйтә. Кыз аңлата:

– Менә тиздән дию үзе дә кайта торган көннәр җитә.

Болар диюне үтерү турында план кора башлыйлар. Егет кызга менә нәрсә ди:

– Мин дию кайтканда идән астына төшеп утырырмын, син сорарсың: «Сезнең җаннарыгыз кайда?» – дип. Менә безнең, адәмнәрнең, җаннарыбыз үзебездә. Ә безнең ишеткәнебез бар: пәриләрнең, җеннәрнең җаннары чүплек башларында, себерке асларында була, имеш, диярсең. Ул ачуланыр, ачуланса да сөйләр, – дип, кызны өйрәтеп куя.

Икенче көн дә килеп җитә. Өйләрне селкетеп, җилләр чыгарып, тузаннар туздырып, дию пәрие кайтып төшә. Дию пәрие кайту белән һавадан баскычка төшә. Билендә ачкычлары була. Аларның берсе белән ишегенең зур йозагын ача да керә. Ә егет, элек килгәндәге кебек, Мәликәне йоклатып куйган була. Яшел язулы тактаны баш астына куя. Дию пәрие килә дә, язулы тактаны алып ташлый, Мәликә уяна. Дию пәрие:

– Уф, уф, адәм исе килә, – дия башлый.

Мәликә:

– Һи, үзең адәм арасында йөрисең, адәмнәрне ашыйсың да, үзеңнән чыга торгандыр әле, – дип әйтә.

Я, Мәликә диюне ашата. Кич җитә. Сөйләшеп йокларга яталар. Мәликә иркәләнеп кенә:

– Пәриләрнең, җеннәрнең җаннары кай төштә була? Менә безнең, адәмнәрнең, җаннары үзебездә, – ди.

Дию пәрие тыңлый-тыңлый да:

– Минем җаным сиңа нәрсәгә кирәк?! – дип, бик ачуланып, Мәликәне ятактан сугып төшерә.

Елый Мәликә. Берничә сәгатьләр үтә. Дию пәрие бераз йомшара төшә:

– Я, Мәликә, кил, әйтсәм әйтим, – ди. – Дәрья уртасында бер сандык булыр, ул сандык эчендә кечкенә генә яшел сандык булыр. Ләкин ул сандыклар бикле булыр. Ул яшел сандык эчендә ике күк күгәрчен утыра. Әгәр дә ул күгәрченнәрнең башын борып дәрьяга ташласаң, мин үләчәкмен, – ди.

Я, болар йоклап китәләр. Алсуланып, кызарып таң ата. Дию пәрие юлга әзерләнә башлый. Мәликәне йоклатып, ишекне бикләп, чыгып китә. Һавага күтәрелеп, пырылдап-зырылдап очып китә.

Хәзер килик Сәйфелмөлеккә. Сәйфелмөлек идән астында дию пәриенең сөйләгән сүзләрен тыңлап яткан икән. Тиз генә идән тактасын күтәрә дә чыга, Мәликәне уята. Мәликә белән ерак юлга әзерләнә башлыйлар.

Дию пәриенең байлыгы гаҗәеп була. Мәликә дию пәриенең байлыгын күрсәтү өчен Сәйфелмөлекне амбарлар буенча йөртә. Беренче амбарны ачып карасалар, анда шундый зиннәтле киемнәр – җаныңа нәрсә кирәк. Бер сандыкка андагы зиннәтле киемнәрне тутыралар.

Сәйфелмөлек үзенең нинди сәбәп белән юлга чыкканлыгын сөйләп бирә. Үзен гашыйк иткән кызның рәсемен Мәликәгә күрсәтә.

– Мәликә, менә нәрсә, мин сине дию пәрие кулыннан коткарам, син дә миңа шушы кызны табуда булышсаң иде, – ди.

Мәликә рәсемне текәлеп карый. Озак карап торганнан соң:

– Сәйфелмөлек, бу адәм кызы түгел бит, бу пәри кызы, – ди.

Сәйфелмөлек бер сүз әйтмичә, тын алып торганнан соң:

– Юк, мин аны барыбер яратам, барыбер мин аны эзләп табарга тиешмен, – ди.

Мәликә вәгъдә бирә:

– Табышырмын, ул пәри кызы бездән ерак түгел, пәриләр авылында яши. Мине дию пәрие урлап китергәч, аны күргәнем бар. Ул кызның исемен дә беләм. Ул кызның исеме – Фәтхелҗамал.

Сәйфелмөлек, юл киемнәрен киенеп, урманда каен тузлары әзерләп, дәрья уртасына керү өчен каек[1] ясарга керешә. Каекка ике ишкәк хәзерли. Амбардан алган сандыкны да каекка куялар.

Баралар, баралар. Дәрья бүген, бәхеткә каршы, тып-тын икән. Мәликә көймәнең түрендә, Сәйфелмөлек ишәргә керешә. Дәрьяның уртасына килеп җитәләр. Дәрьяның нәкъ уртасы бераз дулкынланып китә. Йөзекле кулын дәрьяның уртасында болгата егет, шул вакытны зур сандык килеп чыга. Сандык бикле була. Егет сандыкка әтисе бүләк итеп биргән алтын балдакны

[1] Каек – туздан я агачтан казып ясалган көймә.

тидерә. Сандык ачылып китә. Сандык эченнән бәләкәй яшел сандык килеп чыга. Ул да бикле була. Аңа шул ук балдакны тигезү белән ул да ачылып китә. Аның эчендә ике күгәрчен утыра. Тиз генә Сәйфелмөлек күк күгәрченнәрнең муеннарыннан борып, дәрьяга ата. Дәрья өсте кызыл канлана. Бу вакытны бик көчле күк күкрәгән тавыш килә. Дәрья өсте дулкынлана. Чак кына боларның көймәсе өстенә дию пәрие килеп төшми. Ул калын тавыш белән: «Ах, Мәликә, ашадың башымны», – дигәнче, дәрья төбенә төшеп тә китә. Тиз генә Сәйфелмөлек көймәне ишә-ишә дәрьяның икенче ягына чыгалар. Көймәдән чыгып, сандыкны алып юлга китәләр.

Киләләр, киләләр болар. Бер сукмак очрый. Сукмак буйлап китәләр. Боларга Фәтхелҗамалны эзләп табарга кирәк. Юлның уңында да, сулында да кеше очрамый.

Баралар, баралар болар, бер авыл читенә килеп чыгалар. Авылга керәләр. Мәликә Сәйфелмөлекне авыл читендә калдырып, Фәтхелҗамалларның өен эзләп китә. Авылның нәкъ уртасында бәләкәй генә бер өй була. Мәликә шунда керә. Өстәл янында бик матур кыз утыра. Ул Фәтхелҗамал була. Алар үзара сөйләшә башлыйлар. Мәликә башыннан үткәннәрне сөйләп бирә. Аннан соң Фәтхелҗамал янына ник килүен әйтә:

– Мине дию кулыннан коткарган егет синең рәсемеңне күреп гашыйк булган, сине эзләп килгән.

Егетне күреп сөйләшкәч, егет тә Фәтхелҗамалга ошый. Ләкин Фәтхелҗамал егеткә өч шарт куя, әгәр шуларга риза булса, кияүгә чыгачагын белдерә. Егет риза була.

Болар туган якларына карап юлга чыгалар. Кайталар, кайталар, иң элек Мәликәнең туган авылына килеп җитәләр. Мәликәнең əти-әнисе кызлары кайту шатлыгыннан зур бәйрәм ясый. Халык җыя, егеткә рәхмәт белдерә, бүләкләр бирә. Егет, саубуллашып, Фәтхелҗамал белән өйләренә кайтып китә.

Сәйфелмөлекнең әтисе-әнисе улларын ай көтәләр, ел көтәләр, тагын бер-бер артлы көннәр-айлар үтеп тора. Нәкъ бер ел дигәндә, Сәйфелмөлек, Фәтхелҗамалны җитәкләп, өйгә кайтып килә. Әти-әнисе шатланып каршы алалар. Уллары исән-сау кайтканга барча авыл халкын җыялар. Тиздән туй булачагын белдерәләр. Әти-әнисенең туган-тумачалары, таныш-белешләре, атлар җигеп, шаулатып-гөрләтеп килеп тә җитәләр. Туй бик күңелле, кызык үтә. Фәтхелҗамал белән Сәйфелмөлек бер-берсен яратып бик тату яшиләр.

Шулай итеп, берничә еллар үтә. Боларның уллары дөньяга килә. Бу баланың матурлыгын әйтеп тә килештерә алмассың, язуга да язып бетерә алмассың: чулпан күзле, чия иренле, ак йөзле бик мәһабәт егет була. Бер яшь тулганда йөгереп йөри башлый, «әти», «әни» сүзләрен әйтә. Ә Сәйфелмөлекнең әтисе картая, тормыш итүне улына тапшыра.

Көз үтә, яз да килеп җитә. Бервакыт болар аш ашап утыралар. Шул вакытта ишектән зур гына эт килеп керә. Фәтхелҗамал улын эт авызына куеп, ишектән чыгарып җибәрә. Бу хәлне күреп, Сәйфелмөлек Фәтхелҗамалны чиксез ачулана. Шунда ишек ачыла да бала кайтып керә.

– Менә бит, – ди Фәтхелҗамал, – улыңа бернәрсә булмаган. Ә син өч шартыңның берсен боздың, – ди.

Сәйфелмөлек Фәтхелҗамалдан гафу үтенә. Болар яңадан тату гына тора башлыйлар.

Боларның икенче балалары дөньяга килә. Бу юлы кыз бала була.

Кыз да үсә башлый. Бик матур була. Көннәр үтә, айлар үтә. Тагын уен-көлке белән өйдә утыралар. Бу вакытны Фәтхелҗамал зур мич ягып куйган була. Аның ипи саласы бар икән. Мичтә утыннар күмерләнә. Шул вакыт Фәтхелҗамал зур көрәкне ала да, кызны шуңа утыртып, мичкә ыргыта. Сәйфелмөлекнең бик ачуы килә. Ачуыннан хатынына кычкырып

җибәрә. Мичкә барып караса, кечкенә кыз мич эчендә кызу күмерләр белән уйнап утыра.

– Менә, – ди Фәтхелҗамал, – син өч шартның икесен боздың инде, – ди.

Болар шулкадәр ачуланышалар. Фәтхелҗамал бәләкәй кызны үзенә ияртеп, улын әтисендә калдырып, өйдән чыгып китә. Фәтхелҗамал өйдән чыгуга җил чыга. Бәләкәй кызы белән ул һавага очып китә. Һаваларда бер ләгән туры килеп, шуңа утырып, алар дөнья әйләнә башлыйлар. Ул ел саен бер мәртәбә үзе беренче тапкыр килен булып төшкән йортны, анда калган улын эзләп, әле дә булса әйләнеп йөри икән. Өермәләр уйнау, сафура бураннары күтәрелү шуннан калган, диләр.

*1969 елда Омск өлкәсе Тара районы Шыклар авылында Гыйззәтуллина Сарадан (1926 елгы) Н. Ибраһимов тарафыннан язып алынган. «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында басылып чыккан (б. 118–123).*

## Сәйпелмөлек

Бер шәһәрдә торган бер патша. Аның улы Сәйпелмөлек исемле була. Вәзирнең улы Якуп була. Алар икесе бик дус булалар. Икесе кич көннәрдә (хәзер без клуб дип әйтәбез, ул чакта мәдрәсә дип йөрткәннәр), шунда йөреп, таң алдыннан йокларга килеп яталар.

Таңның тәмле йокысында Сәйпелмөлек Сәлимә дигән кызга гашыйк була. Болар икесе бик дус булып, инде кушылып дөнья көтәбез дигән йирдә егет уянып китә. Иртә белән бик уйлана. Бернәрсә ашамый, бер тамчы су эчми. Әтиләре сорый:

– Син, улым, чирләдеңме әллә? Нигә берни дә ашамыйсың? – диләр.

Бу әти-әнисенә: «Төшемдә шундый Сәлимә дигән кызны күрдем», – дип әйтергә оялды. Сәйпелмөлек тышка чыгып утыра да, табармынмы шул кызны, дип уйлана.

Шулвакыт Якуп килеп:

– Син нәрсә, чирләдеңме, дус? – ди.

– Юк, шулай-шулай төшемдә Сәлимә дигән кызны күрдем, шуңа гашыйк булдым. Хәзер инде ни эшләргә белмим, – ди.

Әлеге Якуп әйтә:

– Әйдә, дус, әти-әниеңә әйтәбез дә китеп эзлибез, табарбыз, – ди.

Якуп, кереп, Сәйпелмөлекнең әти-әнисенә сөйли. Әтиәнисенә, патшага әйтәләр. Патша риза була:

– Эзләсен, җибәрәбез аларны, – ди. Патша хатыны вәзир хатынына да әйтә:

Юлга әйберләр әзерләгез, – дип. Патша сал эшләтә.

Бөтен җирдән эзләгез, кызны табыгыз, – ди патша. Зур дәрьяларны йөзеп китәләр болар судан, салга утырып.

– Сулардан карыйк, – ди Якуп. – Судан тапмасак, авыл араларыннан эзләрбез, – ди.

Болар китәләр, бик тирән дәрьялардан, матур сулардан эзлиләр. Бер ашап-эчеп утырганда кыйбла яктан давыл чыгып,

боларның салы ватыла. Егетләр икесе ике агачка ябышып калалар. Ашамак ризыклары су төбенә китә. Сәйпелмөлек бер агачка атланып китә кояш чыгышына, Якуп китә кояш батышына.

Сәйпелмөлек, бер балыкка җитеп, кулын суза. Кулын югары сузганда бер аякка юлыга. Ул Сәмруг кош аягына тотынган икән. Сәмруг кош аны алып китеп, оясына куя.

– Инде син миңа бала бул. Мин сиңа ашарыңа алып киләм, – ди Сәмруг кош кешечә. – Минем балаларым аякланганда, телләнгәндә аждаһа-елан ашап китә балаларымны. Син аларны ашатма аннан, – ди.

Сәйпелмөлек аждаһа-елан килгәндә аны чабып үтерә, балаларын исән-аман алып кала. Сәмруг кош төрле йийем-эчем[1] алып килә. Бик куана.

– Минем балаларымны һәрвакыт шулай ашап китә иде. Каян син минем аягыма эләктең? Мин инде сине гомергә онытмам, – ди.

– Мин риза, – ди Сәйпелмөлек. – Мине җир өстенә төшер. Мин Сәлимә дигән кызга гашыйк булдым. Аны сулардан эзләдем, инде җирдән, шәһәрдән, авыллардан эзлим, – ди.

Сәмруг кош Сәйпелмөлекне җиргә төшерә.

– Инде ризамы?

– Риза. Тик синдә алтын балдак бармы? Бир миңа аны. Балаларың белән гомергә бергә яшәрсең, – ди.

Сәмруг кош балдакны Сәйпелмөлеккә бирә. Ул әлеге балдакны алып, кәгазьгә төрә дә кесәсенә сала. Китә, китә бу. Авыллар, шәһәрләр буйлап йөри. Күрә: күктә бер өй әйләнеп тора. Элгән элмәге юк, таянган таягы юк.

– Бисмилляһи-р-рахман-иррәхим! – дигән иде Сәйпелмөлек, ишек ачылып китә.

Бер бик матур кыз ята монда.

---

[1] Йийем-эчем – ашау-эчү.

Сәйпелмөлек әти-әнисе юк, дип, янына бармый. Кыз үзе бик матур күренә. Ул бер авылда бер байның кызы булган. Җиләк җыеп йөргәндә аны пәриләр алып киткән. Мәликә исемле була ул кыз. Сәйпелмөлек шуңа барып чыга.

Ул кыз янына килә дә:

Яныңа килсәм, йоклыйсың,
Ишеккә барсам, көләсең, –

дип әйтүе була, кыз сикереп тора.

– Син кем кызы?

– Мин шундый-шундый байның кызы, җиләк җыеп йөргәндә мине шул пәриләр алып киткән иде. Син үзең ничек килеп кердең монда, абый? – ди.

Сәйпелмөлек әйтә:

– Синең исемең кем?

– Мәликә.

– Мин Сәлимә атлы кызны эзләп чыктым.

– Мин ул кызны беләм, – ди Мәликә. – Ул пәри кызы. Мин аны сиңа алып килермен, – ди. – Тизрәк качыйк бу су астыннан. Син мине пәриләр кулыннан алып кит. Мин әти-әниемне тапсам, сиңа Сәлимәне табып бирермен. Тик моның өчен Сөләйман атлы балдак кирәк, – ди.

– Бар миндә ул балдак, – ди Сәйпелмөлек.

– Син кулыңны суга тык, без шул балдак аркылы гына кача алырбыз, – ди кыз.

Болар баралар. Пәри килсә – кыз юк. Пәри сугыш ача. Мәликәләр өен белгән була.

– Сәйпелмөлек абый! Пәриләр сугыша, мине эзлиләр. Су өстендә ике илле кан булды, – ди.

Болар исән-аман кырга чыгалар, дәрья бетә. Юлдан туп-туры әлеге кызның авылына китәләр.

– Син минем туган абыем булдың. Пәриләр кулыннан исән-аман коткарып алдың, – ди.

Куанышып кайталар. Боларга ат белән тауар алып кайтучы кешеләр очрый. Бер карт Мәликәне таный. Ул элек аның әтисендә, байда эшләгән хезмәтче икән. Сәйпелмөлек белән Мәликәнең каршысына килә.

– Мәликә, синме, балам? – ди.

– Мин.

– Әти-әниең бик картайды бит синең өчен кайгырып.

– Мине пәри алып киткән иде. Менә, бәхетемә, Сәйпелмөлек абый очрап, алып килә мине, – ди Мәликә.

Сөенче алырга дип, Сәйпелмөлек белән Мәликәне әти-әнисенә утыртып алып китә.

– Кызың исән-аман. Бер егет тә бар! – ди.

Әти-әнисе бик шатлана. Утыз көн уен була. Кәрваннар юлдагы тауарларыннан бераз төяп китерәләр. Аннан соң Сәйпелмөлек Мәликәгә әйтә:

– Минем күңелем утырсын, Сәлимәне китер, – ди.

– Китерәм, китерәм. Хәзер кырык кызны җибәрәм дә китертәм, – ди Мәликә.

Чыкканда җилләргә сөйләгән сүзен Мәликә. Кырык кызга ишетелгән. Кырык кызны ияртеп, Сәлимә килеп тә җиткән. Мәликә Сәлимәгә әйтә:

– Сиңа бер Сәйпелмөлек дигән кеше гашыйк булган, – ди, шул вакыт Мәликәнең һушы китә.

Сәлимә әйтә:

– И дус, син серләреңне әйтергә чакырдың. Ник сөйләмисең? – ди.

– Сиңа, – ди, – бер егет гашыйк булган, әйдә карыйк.

– Яле, күрсәт, – ди Сәлимә. Барып караса, үзенең һушы китә.

Сәйпелмөлек тәрәзәдән караса, төшендә күргән кыз һушсыз өй артында ята. Сәйпелмөлек йөгереп чыга да аны Мәликәнең өенә алып бара.

– Мин сине җирдән дә, судан да эзләп, бик күп газаплар чиктем, – ди.

Сәлимә әйтә:

– Мин дә бит сиңа күптән гашыйк. Бергә булыйк. Мәликә, син безгә туй яса, – ди.

Утыз көн уен, кырык көн туен итеп, Сәйпелмөлек Сәлимәне, пәри кызын алды.

Сәйпелмөлекне патша итеп утырталар. Әти-әнисенә алып кайтмадылар. Бу алтын тәхеткә утыра. Пәри кызы белән көн итә инде.

Бер-ике елдан соң, көннәрдән бер көнне яннарына Сәйпелмөлекнең дусты Якуп килеп чыга. Сәйпелмөлек патшаның дәрьясында йөзгән икән. Ите юк, сөяк кенә калган, бик ябык. Якупның яр башында ятканын бер вәзир күргән. Килеп патшага әйткән:

– Шундый-шундый бер кеше яр башында ятып тора, – дип.

– Китерегез, мин күрим, нинди кеше икәнен, – ди Сәйпелмөлек.

Вәзир китерә.

– И дустым Якуп, син нигә болай беттең? – ди.

Якуп җавап та бирә алмый. Аны ял иттерәләр, ашатып эчертәләр. Шуннан соң Якуп үзенең ни күргәннәрен сөйли.

Сәйпелмөлек үзенең патша булуын әйтә. Хезмәтчеләренә әйтә:

– Бер атна эчендә кеше итегез үзен, – ди.

Бик тәрбияләп, бер атнадан Якупны алманың сабындай егет итәләр.

– И дус! – ди Сәйпелмөлек. – Мине пәриләр кулыннан бер кыз коткарган иде. Туйлыйк әле сиңа шул Мәликәне. Ул минем сүземнән чыкмас, – ди.

– Ярый, – ди Якуп.

Күп уйлап тормый, Мәликәне чакырта Сәйпелмөлек:

– Бу, – ди, – минем дустым. Без икәү бергә эзләдек Сәлимәне. Күп михнәтләр күрдек. Аллаһы Тәгалә безне аермады. Мин сине Якупка димләдем, – ди.

– Мине ат койрыгына бәйләсәң дә каршы түгелмен, – ди Мәликә. – Синең сүзеңнән чыгасы түгелмен, риза, – ди. – Син минем әти-әниемә дә әйт, мин ризамын. Минем кебек үк кешенең газиз баласы, – ди.

Сәйпелмөлек әти-әнисенә әйтә. Халыкны җыеп, утыз көн уен, кырык көн туен ясыйлар. Эт тә, мешәк[1] тә калмый туйларыннан. Бик кызык була. Якуп белән Мәликә дә инде көн итәләр.

Сәйпелмөлек белән Якуп үз әти-әниләрен бик сагыналар.

– Биш ел ят җирләрдә йөрдек, әти-әниләр дә безне сагынгандыр инде, – диләр.

Халыкны җыенга салып, Сәйпелмөлек патшалыктан төшә. Болар үз җирләренә кайталар. Кайтып җиткәч, әти-әниләре елап, бик шатланышалар.

– Икәү китеп, дүртәү булып кайттыгыз, – диләр.

Тугыз дөя, тугыз кысыр сыер, тугыз ат суеп, утыз көн уен, кырык көн туен ясыйлар. Үз җирләрендә әтисе урынына Сәйпелмөлек – падиша, Якуп вәзир булып көн күрәләр. Әле дә яшәп яталар.

*Новосибирск өлкәсе Чаны районы Чүплекүл авылында Шиханова Зәйнәптән (1898 елгы) Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Язма мирас үзәге, колл. 79, п. 2. «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында басылып чыккан (б. 123–127).*

[1] Мешәк – мәче.

## «Сәйфелмөлек» дастаны көйләре

### *Беренче көй*




Кашың карай күсеңнең күклегенәй,
Пуйың сифай пилеңнең нәслегенәй.

*Төмән өлкәсе Тобол районы Лаймтамак авылында Бәхтиева Сәрвәр (1900 елгы, 71 яшь) һәм Хисаметдинова Хөсни (1915 елгы, 56 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Хөсни мамай – Кыскыркүл авылы кызы. Шул авылда җырланган көй. Күпме тырышсак та, җырчыларыбыз икенче куплетны искә төшерә алмады.*

### *Икенче көй*




Яшел чарбан[1] эчендә гөл йарадды,
Мәне сайрап аны былбыл йаратты. } 2

Мәнең сайрамагыл гөл йар эчендә,
Сәнең сайрамагың дидар эчендә.

Кара сачең төшәр микән йөзеңә,
Сәлам әйтсәм, йитәр мигән үзеңә. }2

Каш астында кара күзең сөзеләү,
Сәне күрсәм, азиз җаным өзелә. } 2

Азиз җаным, җәмалыңни[2], гүзәлем,
Сәне күрмәй нихәл итеп түзәрмен. } 2

Сәне сөйдем, кибеп калдым бәладән,
Рәхим әйләгән икәнсең мөдәтәләгә[3].

---

[1] Чарбан – сүзнең мәгънәсен таба алмадык.
[2] Җәмал – матурлык, гүзәллек.
3 Мөдәтәлә – мөбтәля сүзеннән бозылган, бәхетсезлеккә дучар булучы.

Бу сүзләрне китапта күргәнем бар,
Хыял бәндәнең арыскы[1] булды.

Сәне янда яраддың, мәне анда яраддың.
Арабызга мөхит дәрья[2] яраддың.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Ихсиңер авылында Бакиев Гайнулла (1892 елгы, 76 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

[1] Арыскы – ырыс сүзеннән, бәхет, шатлык.
[2] Мөхит дәрья – дөнья океаны.

**Өченче көй**

Йәшел сантык эцләрентә алтын кашык,
Күсең берлән кашыңга булдым гашыйк. } 2

Күс өстентә кашың кара сөселмәс,
Синең өчен газиз җаным өселмәс. } 2

Синең дәртең миңар дәрмәндан артык,
Сиңар кол булганым солтантин артык. } 2

Бер илә кеше лайык булырмы,
Очар кошкай адәм гашыйк булырмы? } 2

Очар кошлар очар китәр авадан,
Канатың юк, калырсың мөтәәссиф[1]. } 2

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абитов Биктимер җырлаган (1918 елгы, 50 яшь). Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган.*

[1] Мөтәәссиф – кайгыру, кызгану, үкенүне белдерү.

## «ӘЙТҮКӘ»:
## ҖЫРДАН ДАСТАНГА

Татар халкында бәхетсез мәхәббәтне бәян иткән дастан-кыйссалар, легендалар, тарихи җырлар гаять популяр. Аларның дистәләгән вариантлары булып, бәхетсез гашыйклар тарихын белмәгән кеше юктыр. Таһир белән Зөһрә, Ләйлә белән Мәҗнүн, Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу мәхәббәтләре турындагы дастаннарны халык яттан белгән. Сезгә тәкъдим ителә торган Әйтүкә җырлары да – мәхәббәт җырлары. Бу җыр – эчтәлеге белән романик дастанга якын әсәр. Дөресрәге, реаль вакыйгаларга нигезләнгән Әйтүкә җырлары җыр белән дастан арасында тора.

Хәзергә кадәр Себергә оештырылган комплекслы экспедицияләр вакытында «Әйтүкә җыры» турында ишетергә туры килә. Информантлар бу җырның Әйтүкә исемле егет белән Батыш исемле кызның бәхетсез мәхәббәтен бәян иткән җыр булуын хәтерләсәләр дә, соңгы елларда ул онытыла бара, аерым строфаларын гына искә төшерәләр. Җыр Новосибирск өлкәсендә яшәгән татарларда бик популяр булган. Җырда тасвирланган вакыйгалар, җыр чыгуга сәбәп булган мәхәббәт тарихы күпсанлы, еш кына бер-берсенә каршы килгән риваятьләрдә, истәлекләрдә дә саклана.

Бу мәкаләдә, җырларның барлык юлларын, төрле елларда һәм төрле галимнәр тарафыннан язып алынган вариантларны да кертеп, эзлекле бер текст буларак туплап, мөмкин булганда риваятьләр ярдәмендә тулыландырып барып, Әйтүкә мәхәббәте белән сезне дә таныштырырга телибез.

«Әйтүкә җыры» Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Себер татарларының фольклорын өйрәнү максаты белән оештырылган экспедицияләр вакытында күп тапкырлар язып алына. Җырны иң беренче язып алучы кеше Хафиз Рәхмәтуллин була. Ул 1894 елда Омск өлкәсенең Усть-Ишим районы Тау авылында туган. Хафиз Рәхмәтуллин 1928 елдан 1936 елга кадәр Новосибирск өлкәсендә төрле вазифалар башкара. 1932–1936 елларда «Азат Себер» газетасында редактор урынбасары һәм баш редактор булып эшли. Ул киң эрудицияле, күпкырлы талантлы шәхес булып, Себер татарларының рухи байлыгын туплау һәм киләчәк өчен саклап калу өчен зур хезмәт куя. Себер татарларының күпсанлы җырлары әлеге шәхес язмага теркәү сәбәпле сакланып калган. Х. Рәхмәтуллин Новосибирск өлкәсендә эшләгән дәверендә «Әйтүкә җыры»н да язып ала.

1940 елгы В.В. Радлов эзләре буенча оештырылган экспедиция вакытында бу җырларны һәм Әйтүкә тарихын Хәмит Ярми һәм Мөхәммәт Садри (В. Хаҗиев) язып алалар. М. Садри бу елларда язып алган «Әйтүкә» җыры турындагы риваятьләрне 1964 елда «Совет әдәбияты» журналында искә ала[1], җыр текстын «Казан утлары» журналында бастырып чыгара[2], бу җыр әдипнең «Иртешкә сәяхәт» дигән җыентыгында да урын ала[3].

1967 елда Х. Ярми җитәкчелегендәге экспедиция яңадан Новосибирск өлкәсендә эшли. «Әйтүкә җыры»н, Әйтүкә белән Батышның мәхәббәт тарихын, тормышларын яктырткан риваятьләрне Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев язып алалар. Ике тапкыр оештырылган экспедиция нәтиҗәсендә Әйтүкә белән Батыш турында кызыклы риваятьләр, шактый гына җыр текстлары туплана.

---

[1] Совет әдәбияты. 1964. № 8, Б. 135–136.

[2] Казан утлары. 1978. № 9, Б. 118–120.

[3] *Садри М.* Иртешкә сәяхәт: Себердәге халкыбыз арасыннан җыйган әкиятләр, җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 115–119.

«Әйтүкә җыры» диалектологлар игътибарыннан да читтә калмаган. Диалектолог Л.В. Дмитриева 1967–1968 елларда Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылында җырның унҗиде строфасын язып алып, аларны үзенең «Язык барабинских татар» дигән китабында бастыра[1]. «Әйтүкә җыры»н һәм риваятьләрен Новосибирск өлкәсендә узган экспедицияләр вакытында диалектолог Ф. Йосыпов туплый. «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» дигән коллектив монографиядә галим үзе язып алган вариантлар белән диалектологлар Л.В. Дмитриева, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова һәм әдип М. Садри бастырган текстларны да биреп, бу җырның билгеле вариантларын бергә туплый[2].

Диалектологлар Ф.С. Баязитова белән Д.Б. Рамазанова «Әйтүкә җыры»ның сүзләрен Себер татарларының этнокультура лексикасына багышланган җыентыкларында бастырганнар[3].

Риваятьләр һәм истәлекләр буенча, Әйтүкә белән Батыш Себердә Үңәр дигән авылда (хәзерге Новосибирск өлкәсенең Чаны районында Тармакүл авылы) туып үскән кешеләр. Әйтүкәнең тулы исеме – Әйтмөхәммәт, Батыш – Фатыймадан кыскартылган. Озын исемнәрне кыскарту күренеше элегрәк татарларда таралган күренеш була. Геройларның биографиясе берничә варианттагы риваятьләрдә бәян ителә.

Беренче риваять буенча, *Батыш Үңәр авылының Балыйк (Халыйк, Халик) исемле байның кызы була. Әйтүкә бик ярлы гаиләдән була. Атасы аны ун яшендә Балыйк байга сата. Үсеп җиткәч, ул шул байның хезмәтчесе булырга тиеш була. Әйтүкә Батыш белән бергә уйнап үсә.*

---

[1] *Дмитриева Л.В.* Язык барабинских татар. Л.: Наука, 1981. С. 73–77.

[2] Барабинские татары. Страницы духовной культуры. Казань: Казанский университет, 2013, С. 25–274.

[3] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2009. Б. 546–547; *Рамазанова Д.Б.* Себер диалектларыннан материаллар. Казан: Фикер, 1998. Б. 98–100.

*Әйтүкә йөзгә чибәр, күркәм холыклы егет булып үсеп җитә. Шул ук вакытта егетнең тавышы шулкадәр матур була, аны ишетеп-күреп, бер кеше дә битараф кала алмый. Әйтүкә үзе җырлар да чыгара, дөресрәге егет чичән-җырау сәләтенә ия була, ул һәр вакыйганы җыр белән шәрехләп бара. Батыш белән Әйтүкә бер-берсен ярата башлыйлар. Бай Әйтүкәне кызына тиң күрми, бу мәхәббәткә чик куярга теләп, Батышны бер байга кияүгә бирә. Тәбсәү (туй) көнне Әйтүкә белән Батыш ат менеп качып китәләр. Алар урманда качып яшиләр. Бер-ике елдан, сагынуларына түзә алмыйча, кире әйләнеп кайталар.*

*Ләкин бай Әйтүкәне кияве итеп танырга теләми. Байлар, муллалар җыелып Әйтүкәне шәригать буенча хөкем итәләр. Кыйнап кулын сындыралар. Шул вакыйгаларның шаһиты булган халык, Әйтүкәне яклап, байлар кулыннан тартып ала. Шуннан соң Әйтүкә белән Батыш җыр белән үзләренең мәхәббәтләрен сөйлиләр.*

Икенче риваять буенча, *Батыш ярлы кызы була. Аны Үңәр бае көчләп үзенә кияүгә ала. Соңыннан Әйтүкә Батышны байдан тартып алып кача.*

Бу риваятьләрне 1940 елда Хәмит Ярми Новосибирск өлкәсе Чаны районы Аялу авылында Нур Ибраһимовтан язып алган.

1967 елда Ф.И. Урманчеев Чаны районы Тармакүл авылында Гази Шәмсетдиновтан язып алган риваятьләр алдагысында бирелгән мәгълүматларны тулыландыра.

*Әйтүкә Тармакүлдә туып-үскән. Уналты яшендә үзе яраткан Фатыйманы алып, авылдан качкан. Өч ел буена бу авылдан 100 чакрым җирдә, Казах илендә яшәгән. Аның яшәгән җирен күргән кешеләр дә булган. Фатыйма бу яктагы иң матур кыз булган. Үзе биюче дә булган. Маңгаена ...* (сүз танылмый. – *И.З.) белән су куеп биегән. Әйтүкә бәхер* (ярлы) *булганга күрә, Фатыйманың әтисе аны Әйтүкәгә бирәсе килмәгән. Шуннан соң Әйтүкә өйләнмәгән булса да, Фатыйманы алып качкан.*

*Фатыйманың биш агасы булган. Фатыйманы Балык дигән бай кешегә биреп куйган булганнар. Кодалатып куйган булганнар. Әйтүкә белән Фатыйма әүвәл, сөйләшеп, аннан качып киткәннәр. Кайбер кешеләрнең Әйтүкәне күргәннәре дә булган. Әйтүкәне тотып, алып килгәннәр. Аннан соң Әйтүкә үзенең җырларын җырлаган. Җырларны русчага тәрҗемә иткәннәр. Шуннан соң пристав Әйтүкәне җибәргән. Фатыйманың атасы кызына аңа кияүгә чыгарга рөхсәт итмәгән. Шулай итеп, Әйтүкә белән Фатыйма, бер-берсен яратсалар да, кушылып бергә яши алмаганнар. Фатыйма ялгызлыкта гомер уздыра, Әйтүкә соңра өйләнгән булса кирәк. Ләкин анысын тәгаен белүче юк. Бу вакыйгалар моннан бер йөз ел элек булган.*

Ф. Әхмәтова 1961 елда Новосибирск өлкәсе Бараба районы Бакчакүл авылында 1891 елгы Ажбаков Мөслим бабайдан, 1967 елда Новосибирск өлкәсендә Куйбышев районы Шагыр авылында 1897 елда туган Баязитова Оркыя әбидән, 1878 елгы Сәлимҗанов Хәмидулла бабайдан «Әйтүкә җыры»ның аерым строфаларын да, геройлар турында сөйләк-риваятьләр дә язып ала. Бу язмаларда кайбер геройларның исеме башка булса да, Әйтүкә белән Батыш турында алдагы язмалардан аерма күп түгел.

*Тармакүл авылында (Үңәр элеккечә) Ибраһим хәзрәт була. Аның Әйтүкә исемле батрагы була. Әйтүкә хәзрәтнең Батыш исемле кызын ярата. Калым түләр хәле юк, хәзрәт бирми дә аңа кызын. Яшьләр бер-берсен яратышып, казах далаларына качып китәләр. Шулай шактый йөргәннән соң, туган якларына кайтырга булалар. Кайбер легендалар буенча, тотып алып кайталар. Үңәрдә халыкны җыеп, Әйтүкәне камчы белән суктырмакчы булалар. Хөкем алдыннан Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен җыр аша әйтеп бирә. Бу җырларны тыңлаган авыл картлары, мондый саф көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр, дип, хәзрәттән яшьләрне кичерүне үтенәләр.*

*Әйтүкәне төрмәгә утыртканнар. Аның төрмәдә җырлаган җырлары да бар, диләр.*

*Әйтүкә Батышны ташлап, башка хатын янына, үзенең кызы белән калган элекке хатыны янына кайткан, дип тә сөйлиләр.*

«Әйтүкә җыры» халыкта бик популяр булып, аны туйларда кара-каршы җырлаганнар. Җырның көйләре бик күп булган, ул борынгы бик озын көйгә дә, кыска көйләргә дә башкарылган. Бараба районы Тандау авылында яшәгән информант Сәбидә әби Бигушевадан Ф. Урманчеев язып алган мәгълүмат буенча, аның яшьлегендә туйда ике кеше «Әйтүкә җыры»н башкарганнар. Аларның берсе Әйтүкә булып, икенчесе Батыш булып җырлаган.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төрле елларда язып алынган материаллар хәзерге вакытта Институтның Язма мирас үзәгенең фольклор фондында саклана. Бу мәкаләдә әлеге архив материалларын бер цикл буларак туплап, аерым строфаларны, эчтәлекләреннән чыгып, эзлекле бер хәлгә китереп, укучыларны таныштыруны максат иттек.

Фольклорчы галимнәр җырның берничә көйгә җырланганын искәртәләр.

Әйтүкә җырларын башкарылу сәбәбенә, вакытына, кемгә аталуына карап берничә төркемгә аерырга мөмкин. Бу җырлар арасында кыска гына аңлатма биреп барабыз. Җырларның эчтәлеге һәр ситуацияне аңлаткан риваятьләр белән ярашып бара.

*И. Закирова*

## Әйтүкә

«Әйтүкә белән Батыш» җыры геройларның бер-берсенә мәхәббәтен аңлаткан җырлар белән башлана. Алар бу җыр аша бер-берсенә соклана, бер-берсен мактый, бергә булырга да сүз бирешә.

*Әйтүкә:*

Йөгерәләй куян, йогерәләй,
Мамык тикләй йонын туздыралай,
Бер яхшы берлән ай бер яман,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Шатлык белән гомер уздыралай.

Варианты:

*Йөгерә лә куян баласы,*
*Мамыктай ла йонын туздыра.*
*Ике лә яхшы бер кушылса,*
*Әй җаныкай гынам, сылуым,*
*Шатлык берлән гомерен уздыра.*

Ике лә генә кырның уртасында,
Ятадыр ла куян баласы.
Дөнья-ахирәт, мәхшәр сәхрасында,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Корыладыр мизан тарасы.

*Батыш:*

Тәрәзәләрдән ник бактың?
Кар йомарлап, җаныем, ник аттың?
Берләр лә атмай, җаныем, ике аттың,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Яшь йөрәккәемә ут яктың.

Сикереп ләй төштем бакчага,
Бакчадагы пешкән алмага.
Бер матур белән уйнаймын дип,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Гөнаһкяр ла булдым Аллага.

*Әйтүкә:*

Әй җанкәм лә җанкәм, түзә алмыйм мин,
Тәрәзәдән күрсәм, күз алмыйм мин.
Үңәр урамнарын әй үткәндә
Синеләй күрмәй үтәлмим мин.

Урамыгыздан узганымда
Ике генә күзем, тулды яшем.
Кара ла кашым, асыл ташым,
Исән булсын газиз башың.

Әй урамыгыздан әй узамын,
Яшел лә ефәк мин сузаем.
Яшел лә ефәкләр җитмәсә,
Тәхлил-бәет әйтеп мин узаем.

Ай тулган ла җанкәм, әй ай тулган,
Ай туган чакта ла син туган.
Тулган айдай якты ла йөзең,
Бу җиһанда синдәен кем булган.

Әй кыйгач ла кашым, карлыгачым,
Сине лә кайда күрәем мин?
Кызыл алмадай ай йөзеңне,
Кай җирләрдән суырып үбәем мин.

Җырларда өч тапкыр Түкә кәмшек телгә алына. Язып алынган материаллар бу кешенең кем булуы турында информация

сакламый. Түкә Төхфәт дигән исемнең бозылган варианты булырга мөмкин. Кәмшек сүзе кыегайган, ямьшәйгән дигән мәгънәдә. Бу очракта ул Төхфәтнең исеме белән янәшә кулланыла торган кушаматы булырга тиеш. Төрки халыклар эпосында, яшьләрнең мәхәббәтенә комачаулап йөргән хезмәтче традицион образ булуын да истә тотсак, Түкә Батышның атасында хезмәттә булган, кызны саклау да аңа йөкләтелгән хезмәтчесе булырга мөмкин.

*Батыш:*

Әй җанкәм лә, җанкәм, күзем туймас,
Бу җиһанда синдәен егет булмас.
Йөгереп чыгып үбәр идем,
Түкә лә кәмшек капка ачмас.

Таллардин ла очар талга кунар,
Кара бакчай кошының баласы
(кара бакчай – сыерчык).
Билдинләй кысып, авыздан сөйсәң,
Яхшы ла эткәйләрнең баласы.

Әй Уралдай биек тау бармы икән,
Барып ла күргән ир бармы икән.
Авырлыклар күрмәй әй ярын алган,
Бу җиһанда андаен яр бармы икән.

Чобырлай чобыр тамчы тамар,
Тамчылары сары май кебек.
Кешеләр күзләренә әллә ничек,
Үз күземә тулган ай кебек.

*Әйтүкә:*

Әй иртә лә торып юлга чыксам,
Олы ла юлда урыс ямщик.

Урыс ямщигенә әй, охшаган
Үңәр урамында Түкә лә кәмшек.

Әй йөгерепләр лә йөгереп җитәлмим мин,
Тал, читәннәрдән үтәлмим мин.
Билгеләре шулдыр сөюемнең,
Катындыйн (яныннан) ташлап китә алмыйм мин.

*Батыш:*

Әй иртә лә торып тәрәзә ачып,
Таң атуларын көтәмен мин.
Йөрәгемә тулган гыйшык уты,
Сине лә уйлап уңамын мин (уңу – саргаю, сулу).

Батышны икенче кешегә ярәшкәннән соң, яшьләр өйләнешүдән өмет өзә, алар үзләре өчен качып китү генә калганын аңлыйлар. Җыр буенча фикер йөртсәк, Батыш качып китүне үзе тәкъдим итә.

*Батыш:*
Әй китәек җанкәм, әй китәек,
Кара урманнардан әй үтәек.
Аяк аска басып дошман сүзен,
Үз теләгебезгә без җитәек.

Үңәр лә күле әй киң икән лә,
Сулары ястыкка тиң икән.
Ике лә күңел әй бер булганда,
Аеручы ла дошман әй кем икән.

Әй баш имәм, җанкәм, баш имәм мин,
Үз теләкләремне итәрмен мин.
Аягыма богау салсалар да,
Аны да ла тибеп өзәрмен мин.

*Әйтүкә:*

Әй китәрбез, җанкәм, әй китәрбез,
Үз теләкләребезне әй итәрбез.
Безгә каршы килгән әй дошманның,
Битләренә төкереп без үтәрбез.

*Батыш:*

Әй күктә лә йөзгән бер йолдызга,
Әйтәләр лә икән Чулпан дип.
Дошман ла сүзен читкә каккан
Егетләрне әйтәләр солтан дип.

*Әйтүкә:*

Каен төпләренә балта чапсаң,
Гөрләп оча аның әй тургае.
Үз сүзләреңдә әй тугры булган,
Син, җанкәем, кызның әй солтаны.

*Батыш:*

Ашасаң ла шикәр, әй бән куямын,
Ашаганыңны ла әй күрәем.
Ашаганыңны ла әй бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

Әй кырларда үскән куш каенның,
Төпләренә билге кем юнган.
Сөйгәндә лә ярына туры булган
Бу җиһанда синдәен кем булган.

Яшьләр үзләренең мәхәббәтен дә, киләчәктәге бәхетсезлекләрен дә язмыш дип кабул итә. Җырда язмыш мотивы төрле яктан ачыла.

*Әйтүкә:*

Майдалай кәккүк әй кычкырадыр,
Язынлай көзен һич белмидер.
Халаек безне күп сөйлидер,
Хак язганын һич белмидер.

Туй көнне Әйтүкә Батышны алып качып китә. Качып барганда, аларның бияләре колынлый. Ат, колыны белән мавыгып бармый башлый. Бу вакыйга ике төрле бәян ителә. Беренчесендә колынлы бия тиз бара алмаганга, Әйтүкә колынны суярга тели. Әмма Батыш, колынны кызганып, бу эшкә юл куймый. Әйтүкә дә, Батыш каршы килгәч, колынга тими. Риваятьнең икенче вариантында, киресенчә, Әйтүкә колынны кызганып, аны суярга кулы күтәрелми. Батыш, атның туктап калуы аркасында, бөтен планнарының җимерелү куркынычын аңлап, колынны үзе суя. Җырда да шушы хәлләр тасвирлана:

*Әйтүкә:*

Кара ла колын кешнәгәндә,
Туры ла биям әй тулады.
Батыш җанкәм аны суй дигәндә
Ике лә кулым әй бармады.

Минем лә кулым әй бармады,
Батыш җанкәм пычак ошлады (ошлау – тоту).
Кешнәп лә торган әй колынны
Бугазыннан суеп әй ташлады.

Шуннан соң Әйтүкә үзенең халыкта иң таралган җыр юлларының берсен җырлый:

Кызылгат дигән әй җиләкнең,
Тышлары ла татлы, эче ташлы.

Минем лә сөйгән әй Батышның
Телләре лә татлы, күңеле каты.

Бу строфа галимнәр тарафыннан кат-кат язып алынган. Риваяте онытыла барып, җырның яңа варианты барлыкка килгән. Әйтүкәнең кызның кискенлеген, холкын күреп, гаҗәпләнеп җырлаган җыры мактауга, соклануга әйләнә:

*Кызылгат дигән әй җиләкнең,*
*Тышлары ла татлы, эче ташлы.*
*Минем лә сөйгән Фатыйманың*
*Авызы ла татлы, теле баллы.*

Качып киткән яшьләр җыр юлларына Ябышкан дип кергән урманда, икенче вариантта болында, яши башлыйлар. Бу җирләр аларның туган авылларыннан шактый ерак, кеше аягы басмаган аулак урын була.

Әйтүкә качып китеп урнашканнан соңгы җырларында, аның сөйгәне белән кавышудан сөенеп, күпмедер вакыт эйфория халәтендә булуы аңлашыла:

Суда ла йөзгән ак балыкның
Баласын әйтерләр култан диеп.
Акча ла бирми ярлар сөйсәң,
Әйтүкәне әйтерләр солтан диеп.

*Яр буйлары әй, Ябышкан,*
*Ябышканда яткан бармы икән?*
*Яр буенда яткан Әйтүкәне,*
*Әйтерләр аны солтан дип.*

Шул ук вакытта кире кайту турында уйлау, киләчәкнең билгесез булуы яшьләргә бәхетле булырга да ирек бирми. Алар, йолаларга каршы килүләре, илдә булмаган гамәл кылулары өчен

үзләрен гаепле тоялар. Алдагы строфаларда бер-берсен гаепләү, чарасызлык чагыла:

*Әйтүкә:*

Ябышканның буе ярлар микән,
Барып кына күргән барлар микән.
Газиз генә башын хурлар кылган
Яр сөйгән матур ярлар микән.

*Ябышканның буе ярлар микән,*
*Барып кына күргән барлар микән.*
*Сөйгәнен алып мәерләй канган*
*(мәерләй канган – күңеле рәхәтләнгән)*
*Бу дөньяда барлар микән.*

*Ябышканның буе ярлар икән,*
*Барып та лай күргән барлар микән.*
*Уйны да йөрдем, буйны да йөрдем*
*Җан сөйгәннән артык барлар микән.*

Кешеләрдән читтә яшәү аларга кыен бирелә. Икесе дә туган иленә кайту турында уйлый башлый.

*Әйтүкә:*

Карагат (карагат – карлыган) бәнем икеләй күзем,
Саргайды ла бәнем ике йөзем.
Исән генә булып илгә барсам,
Әйтергәләй күптер бәнем сүзем.

Сикереп лә төштем әй инешкә,
Ат бәйләдем сары камышка.
Үлмәсә дә адәм үлми икән,
Эчекәе тулган сагышка.

Ябышкан буе, әй, ком такыр,
Алтын акчалар булмас бакыр.
Сагындым, җаный, әй, саргайдым,
Кайтмаенча булмас, ахыр.

Әй әдернә лә тартып, уклар аттым,
(әдернә – җәя)
Кырларда ла йөргән киекләргә.
Газиз генә башым туган икән
Дөньясынамы көекләргә
(көек – кайгы, борчу).

Муены ла озын әй пүз (бүз) торна,
Әллә ничә төрләй бузнайдыр.
(бузнау – көйләү, сайрау)
Әй, уйны да йөреп, пуйны ла йөреп,
Мөхәндәрдин адәм узмайдыр
(мөхәндәр – язмыш).

Күпмедер сугылып йөргәннән соң, Әйтүкә белән Батыш туган илләренә кайтырга булалар. Икенче версия буенча, аларны эзләп табып кайтаралар. Авылга кайткач, җырның эчтәлегенә караганда, авыл халкы җыела.

Хөкем иткәнче, Әйтүкә үзе чыгарган җырларны җырлап күрсәтергә тәкъдим итә. Бу җырларда ул Батышның матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен тасвирлый. Картлар, бу җырларны тыңлагач, мондый көчле мәхәббәт өчен җәза бирү гөнаһ булыр иде, дип, хәзрәттән яшьләрне кичерүен үтенәләр. Әйтүкә җырларында мондый юллар бар:

Ул да яхшы, бу да яхшы,
Чәй эчкәндә бал да яхшы,
Баш коткарган тел дә яхшы.

*Ашаган чакта бал да яхшы,*
*Сөешкән чакта яр да яхшы.*
*Газиз генә башка эшләр төшсә,*
*Сөйләшкән чакта тел дә яхшы.*

Әйтүкә белән Батыш җырларында үзләренең гаепсез булуларын, бигрәк тә бер-берсенең гаебе юклыгын исбатларга тырышалар, берсе икенчесен коткарып калырга тели.

*Әйтүкә:*

Шаулап ла аккан әй елгада,
Чуртан йөзә суларның үзенә.
Кимсетмәгез безне, әй дусларым,
Кеше кермәс кеше ләй гүренә.

Таң алдыннан яуган әй карларга,
Ак куяннар йөгереп лә юллар салган.
Сөйгәндә дә сөйгән ярын алу
Йосыф белән Зөләйхадан калган.

Суларда ла йөзгән әй балыкның,
Баласына әйтегез култан диеп.
Маллары ла булмас ярлар сөйгән
Әйтүкәне әйтегез солтан диеп.

*Батыш:*

Күлләрдә лә ялгыз аккош,
Баласыннан аерып атмагыз.
Минемдә лә сөйгән Әйтүкәне
Малы юк дип читкә какмагыз.

Әй какмагыз безне, әй какмагыз,
Түкә кәмшек сүзенә бакмагыз.

Гомерлек лә итеп сөйгән ярым,
Аерып ла мине утка ла якмагыз.

Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Бугазыма баулар әй салмыйча.
Аера алмассыз мине Әйтүкәмнән,
Газраилләр җаным әй алмыйча.

*Батыш:*

Әй беләгемә кигән куш беләзек,
Ай яктысы төшсә ялтырый.
Минем лә сөйгәнем әй Әйтүкә –
Ир-егетләрнең лә иң батыры.

Үңәр байларының соравы буенча, Әйтүкәне хөкем итү өчен, шәһәрдән кыңгыраулы унсигез пар атта 18 түрә килгән. Алар Әйтүкәне гомерлек каторгага хөкем итәләр. Ахырда баш түрә: «Сезне җырчы диләр, ахыргы минутыгызда бер җырлап күрсәтегез», – ди. Баштагы җырдан түрә, бу безне бик мактады, дип аңлый, «бик күп маллар түгәр идем алтын штуф укалы якагызга» дигән юлларны бу безгә ришвәт бирәчәк икән дип аңлап, хөкем җәзасын йөз чыбык суктырырга калдыра.

Әйтүкәнең суд приставы килгәч җырлаган җыры:

Ат бәйләгән кубагызга (куба – күчмә өй,
чыбыктан үрелгән),
Чәң (чәң – кыңгырау) бәйләгән дугагызга.
Гакылым бетте, исем китте
Алтын штуф бәйләгән якагызга.

Ат бәйләрмен курагызга,
Чәң бәйләрмен дугагызга,

Бик күп маллар түгәр идем
Алтын штуф укалы якагызга.

Риваятьләр Әйтүкәне төрмәгә утыртканнар, аның төрмәдән җырлаган җырлары да булган, дип бәян итә.

Икенче версия буенча, Әйтүкәне утыртмаганнар, ләкин аңа Батыш белән калырга да рөхсәт булмаган. Ул үзенең беренче хатыны, баласы янына кайткан.

Әйтүкә белән Батышның хөкем карарыннан соңгы җырларында мәхәббәткә, гашыйкларның тугрылыгына дан җырлана:

*Әйтүкә:*

Батыш җанкәм суга ингән,
Көянтәсен талга элгән.
Буе зифа тал чыбыктай
Яр буласын әй кем белгән.

Батыш җанкәм урак ура,
Уң беләген әй талдырып.
Батыш җанкәй мине сөйде
Байлар күңелен әй калдырып.

Батыш җанкәй әй кия лә
Кара сатин көйләген (көйләк – күлмәк).
Батыш җанкәм ташламайды
Маллар өчен әй сөйгәнен.

Ашасаң да шикәр, бән куямын,
Ашаганыңны ла, әй күрәем.
Ашаганыңны ла әй бән күрәем,
Сәнеңләй өчен бән үләем.

*Батыш:*

Онытмам ла, җанкәм, онытмам мин,
Синнән лә башканы яр итмәм мин.
Синең лә кайгыңнан, әй солтаным,
Камыштаен саргаеп үләрмен мин.

Өченче риваять Әйтүкәнең хөкем ителүен бәян итә. Әйтүкә өстеннән җәза башкарылган. Баш түрә Әйтүкәдән, яңадан Батышны алмам, дигән сүз ала. Шуннан соң Әйтүкәне атып үтерәләр. Бу вариант җыр юллары белән дә туры килә. Батышның соңгы җырларында хөкем карарының нинди булганы да, палач турында да мәгълүмат саклана:

Сине генә сагынган чакларымда,
Астанаңа башымны куярмын мин.
Әй моңланып кошлар сайраганда,
Сине генә уйлап җырлармын мин.

Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Эт урядник кылыч әй алганда,
Әйтер сүзен әйтә алмый торды,
Түкә кәмшек мылтык әй атканда.

Әй куе ла кауданлы каен төбе,
Яныкаем, яткан җирең булды.
Кара ла туфрак әй астында
Алмадаен кызыл ла йөзең сулды.

Батыш, Әйтүкә үлгәннән соң, башка кияүгә чыкмаган. Гомере буе Әйтүкәне эзләп, 60 яшендә Үңәргә кайтып вафат булган.

*Текст Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгенең фольклор архивында сакланган материаллардан Илсөяр Закирова тарафыннан төзелде.*

*Аларны фольклорчы галимнәр Х. Рәхмәтуллин, Х. Ярми, Һ. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, В. Хаҗиев Новосибирск өлкәсенең төрле районнарында фольклор экспедицияләре вакытында туплаган.*

*Информантлар исемлеге*

*Бараба районы Бакчакүл авылы: Аәнбанов Габбас (1884 елгы), Ажбаков Мөслим (1891 елгы).*

*Венгерово районы Арынсас авылы: Вахитов Мәгърүф (1905 елгы).*

*Венгерово районы Венгерово авылы: Назирова Мөршидә (1910 елгы).*

*Куйбышев районы Шагыр авылы: Рафикова Мөхлисә (1882 елгы), Баязитова Оркыя (1897 елгы), Хәйдәрова Мәргу (1898 елгы), Сәлимҗанов Хәмидулла (1878 елгы).*

*Чаны районы Кошкүл авылы: Мөхәммәтшин Аллаяр.*

*Чаны районы Тармакүл авылы: Ишмакова Нәкыя (1923 елгы), Нургалиева Вәйдә, Шәмсетдинов Гази (1903 елгы), Ташпулатов Кәрим, Юнанов Сәфәргали, Сиражетдинов Давыт, Хәбибуллина Хәтирә (1890 елгы), Вәлиуллина Нурҗамал (1899 елгы).*

## Дастаннарга тиң мәхәббәт

«Әйтүкә – дөрестән дә, Тармакүл авылында туган кеше. Ләкин ул вакытта әле Тармакүл исеме бирелмәгән булган. Аның әнисе Карлыгаңсылу исемле була. Бу ялгыз бер карчык улы Әйтүкә белән генә Тармакүл авылының Зур күле тирәсендә яши торган була. 1803 елларда туган булырга тиеш. Ятим калган Әйтүкә көтүче булып йөри. Бик матур йырлый торган була, курайда уйный торган була. Үсә, зур була. Үсеп җиткәч тә, шул ук көтүчелек хезмәтен күрә. Бер вакытларны кыш көне, бу вакытта инде мәчет салынып Тармакүл авылына, яшьләр шул тирәгә уйнарга цыга торган булалар. Айлы бер төнне мәчет янында ураза вакытында очрашалар болар Батыш белән. Беренче мәртәбә алар бер-берсенә кар бәрешеп уйныйлар. Менә шул вакытларда беренче аның яратуы. Болар бер-берсен яратышалар. Ләкин Батышның бай абзыйлары, эти-әнисе ярлы карчыкның улына кызларын бирергә риза булмыйлар. Алар аны Тамтау авылының Бауычат исемле баена ярәшәләр. Туй әйтелә, туй салалар. Килешәләр. Туй көтелә. Менә бу көннәрнең берсендә сөйгән кызы Батышны Әйтүкә урлап китә. Риза булалар. Биясе була. Менә болар Иртышка таба китәләр, казакъ якка китәләр. Юлда Иртышка җиткән вакытта боларның бияләре колынлый. Әйтүкә сизә торган була. Арттан куып килүләрен. Шуңа күрә аңа тизрәк китәргә кирәк. Ул колынны нишләтергә белми аптырый. Менә бу вакытта Батыш әйтә: «Без аны бугазлап калдырыйк», – ди. Әйтүкә бик нечкә күңелле кеше була. Ул бик жәлли хәзер генә менә дөньяга килгән колынны бугазлап калдырырга. «Арбага алып кына алып китик», – ди. Батыш: «Авырлыгы бар, куган-килгән вакытта безгә тизрәк китәргә кирәк», – дип, риза булмый. Менә шул вакытта Әйтүкә җырлый.

Аннан соң болар Иртышның аръягына чыкмыйча, Иртыш буйлап китәләр казакъ далаларына. Павлодарга җитмичә туктыйлар. Нindidер бер ярсыман урын була. Күле дә юк, суы да юк, үзе ярга охшаган була. Менә шул тирәдә туктыйлар болар. Агачлар була бик матур тезелеп үскән. Боларга инде халык

арасына барырга ярамый, чөнки болар – яшеренеп йөри торган кешеләр. Бу Батышны биредә калдыра, үзе якын-тирәдән казакъ авылларын эзләп китә. Барып бер казакъ баен таба. Шул казакъ баенең малын көтәргә ала. Ул шунда тагын көтүчелек хезмәтенә керешә. Биредә ул өч ел яши. Батыш бик уңган хозяйка булып чыга. Бакча да утырталар, карбыз да үстерәләр. Әйтүкә бирегә кое казый. Ул кое һаман да бар. Хәзер дә булырга тиеш. 1933 елларда әле аннан су алып эчә торган булганнар. Урыслар ул коены «Айтикин колодец» дип атыйлар. Билгеле, теге коры казакъ даласында бу коеның булуы юлаучыларга бик уңайлы булып китә. Соңыннан әнә шул Павлодарга үтә торган юлаучылар туктый торган булалар. Биредә болар өч ел гомер итәләр. Әйтүкә сагына. «Илгә кайтырга», – ди. Батыш кайтмаска итә. Әйтүкә: «Кайтыйк», – ди. Шулай иттереп болар бу якка таба килеп чыгалар. Ләкин ул Тармакүлгә дип килми. Бу тирәне күреп үтеп, әнисенең исәнлеген генә белеп, соңыннан икенче бер якка китәргә уйлаган. Ул шулай туры килми. Белекте авылында Кечек исемле кенәз була. Шул кенәзнең улы Раймбака көтмәгәндә генә боларны Белекте тирәсендә очырата. Атының башыннан тотып ала да биредә Тармакүлгә алып килә инде. Аны бик күп эзләгән булалар, таба алмаган булганнар. Бласларга хәбәр ителгән була. Чөнки Әйтүкә – ул халык өчен бик хезмәт иткән кеше. Бу вакытларда әле, Әйтүкә биредә вакытта, барабалар түләүне бирә торган булганнар тоткан сунарлаучының тиресе беләп. Натурадан түләтә торган була. Ә менә бу натурадан түләүне акчага күчерергә килә бер вакытны. Биредә инде халык үзенә җиңелрәк булган, өйрәнгән натурадан түләүне яклыйлар. Ә бласлар решать итәләр, обязательно шуңа күчәргә, дип. Шул шаукым чыккан вакытта Әйтүкә беренче булып сүз кузгата. Әйтүкә артыннан бөтенесе дә оешкан хәлдә моңа каршы чыгалар. Бу билгеле була бласларга. Бласлар моны халыкны оештыручы, котуртучы кеше иттереп күрсәтәләр, һәм аны төрмәгә дә алган булалар. Качып киткәнгә кадәрле. Ул Каинаский төр-

мәсендә утырган була. Суд та булмый, сорау да булмый. Озак вакытлар утыра. Менә шул утырган вакытында җир астыннан гына чыккан тәрәзәсе була, кичке вакыт шулай ул моңланып кына Әйтүкә җырлап утыра торган була. Менә аның җыр тавышын тагын да төрмә тирәсеннән үтеп бара торган, губернатор булгандыр, ишетә. Ул хатыны белән прогулкага чыккан була. Шул кешеләр аптырап туктыйлар бу тирәгә, «Бу нинди матур тавыш», дип. Аннан соң төрмә сакчысыннан: «Теге кешене күрсәтегез миңа, шул кешене», – ди. Шул кешенең янына әллә алып чыгалар моны. Шул вакытта бу әйтә. Хатыны сорый: «Без үтеп барганда җырлаган җырыгызны бер мәртәбә җырлап күрсәтегез әле», – ди. Бу инде хәзер аларга үзенең җырлаган җырын җырламый, ә тегеләргә карата чыгарып җырлый. Аннан теге кеше сорый: «Русчага әйләндереп хәзер миңа җырлап күрсәтә алмассызмы бу җырны», – ди. Русчага әйләндереп җырлый. Аннан соң: «Чыгарыгыз бу кешене биредән», – ди. Шунда ук чыгартып калдыра. Менә шулай иттереп ул авылга кайтып килгән булган.

Хәзер бласлар белән дә әзрәк каршылыклары булган кеше икәнлеген белгәннән соң, байның алар ярәшелгән кызын алып киткәненннән соң, билгеле, материаллар күп кенә җыелган була. Менә хәзер моны инде законлаштырып шул судить итәргә әзерләнеп торалар.

Алып киләләр бирегә. Батышны абзыйларына бирәләр. Әйтүкәне шул явып куялар.

Берничә көн көтәләр. Мулла казакъ арасына киткән була. Мулланың килүен көтәләр. Мулла килми. Биредә байларның моннан тизрәк үч аласылары килә. Җыелалар барлык байлар. Җыялар халыкны. Килеп җитә әнә шул Тандау авылыннан Бауычак бай. Биредә, мәчет алдында, суд ясарга үзләренчә җыеналар. Менә шунда решать итә байлар, аларның кыска була инде судлары: «Йөз камчы сугарга!»

Әйтүкә: «Мин элек шуннан алда сезгә әйтәсе сүзләремне әйтеп калыйм», – ди. Менә хәзерге бу мәчетне төзергә дип

бүрәнәләре, агачлары хәзерләнеп өелеп куелган була. Шул бүрәнәләрнең өстенә утырып ул үзенең җырларын җырлый. Халыкларның әйтүе буенча, ул вакыттагы аның җыры йөз утыз җыр була. Бирәдә аның мин кечкенә вакытта ишетә идем сиксәнен белә дип. Ә хәзер инде алар бик азайган.

Җырларын җырлап бетерә ул. Кояш байый. Иртәдән башланган әйбер. Халык бирми аны суктырырга. Ә Батышны алып китәләр. Бауычак бай Тандау авылына. Менә ул анда сөргендә йөргән кебек йөри инде. Алып бара, сарыклар көтәргә куя. Сарыклар белән бергә яши торган була. Хәзер анда Батыш дигән бик матур түгәрәк күл бар. Шул күл тирәсендә көтә торган була ул сарыкларын. Ул бик матур була, бик оста биюче, бик оста җырчы була.

Күп еллар үтә. Әйтүкә Тармакүлдән китеп кала. Әйтүкә Тармакүлгә килгәндә шул 50 яшьләр тирәсенә җиткән кеше була инде. 1848 елларны Әйтүкә үлә. Әйтүкә үлеп өч ел булганнан соң, Батыш Тармакүлгә кайта. 1851 еллар була.

Бер вакытны минем әбиемә 12 яшьләр тирәсе була. «Дөрестән дә син Әйтүкәгә гашыйк булган идеңме?», – дип сорый. «Яткан йөрәкне нишләп кузгаттың», – диеп җавап бирә Батыш, һич бернинди сүз әйтми. Кич яткан кеше төне буена күзенә йокы алмыйча иртәнге таңны шулай аттыра.

Әйтүкә үлә. Әйтүкәне күмгәнне Хөснетдин карт күрмәгән. Батыш озак еллар яши Әйтүкәдән соң. Картаеп үлә. Батыш үлгәннән соң кабер казыган вакытта бер кабер килеп ачыла. Шул. «Хәзер инде күмәргә ярамый бирәдә, кабер ачылды». Бу кемнең кабере булырга тиеш?» – дип киләләр муллага. Мулла барып күргәч, Әйтүкә кабере. «Чын гашыйк булганнар икән, ярар, бергә үк күмәргә кирәк», – дип икесен алар бергә күмәләр.

Теге сораган вакытта Батыш болай әйтә: «Безне аерган Бауычак әллә кая китмәгән, кабере белән купкан. Каберенең өстенә бер үлән дә үсмәгән», – ди».

*Хикәят Нәкыя апа Ишмакова сөйләвендә И. Кадыйров тарафыннан язып алынган.*

## Әйтүкәнең беренче җыры




И... Кызылгат дигәне ай җимешнең
Этче генә ташылы, тышы татылы.
Минем дә генә сөйгән шулы Батышның
Күңеле каты, теле татлы.

И... Йөгерә-йөгерә җитә алмыйм,
Тал-читәннәрдән үтә алымыйм.
Тал-читәннәрдән үтәр идем,
Сине лә ташлап китә алмыйм.

И... Суда ла йөзгән ай балыкның
Баласын әйтегез култан диеп.
Акча ла бирмәй ярны сөйгән
Әйтүкәне әйтегез солтан диеп.

И... Ябышкан буе ярлар микән,
Барып ла күргән барлар микән.
Ярны лай сөеп мәхрүм калган
Бу дөньялыккайларда барлар микән?

И... Ябышкан буе әй ком такыр,
Алтын ла акча булмас бакыр.
Сагындым лай, дуслар, бик сагындым,
Кайтып ла булмас илгә ахыры.

И... Утыр ла ялган, бутыр ла ялган,
Бу ялганлардин кемнәр үк калган.
Бу ялганнарда барлар микән
Сөйгәнен алып ла мәйре лә калган.

И... Ат бәйләгән кубаныкка,
Шәм бәйләгән туганыкка.
Карап кына торып исем китте
Алтын ыштоп укалы якалыкка.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылында Нургалиева Вәйдә (1898 елгы) һәм ИшмаковаНәкыядән (1928 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Әйтүкә*

*Көнбатыш Себер территориясендә яшәүче бараба татарларында атаклы «Кузы Көрпәч һәм Баянсылу» дастаны, шулай ук «Асыл кошлар», «Агавын», «Кара да гына елан», «Кияү типсәү» кебек искитмәле җырлар белән беррәттән, Әйтүкә атлы җырчы егет исеме белән аталган тарихи җыр да бик кадерләп һәм*

*сөеп саклана. Тырыш һәм курку белмәс Әйтүкәнең (тулы исеме Әйтмөхәммәт) Фатыйма атлы сөйгән кызы була. Әйтүкә аны иркәләп Батыш дип йөртә. Фатыйма – бай кызы. Әйтүкә исә – ярлы карчык улы. Фатыйманың әтисе үз кызын бай егетенә бирергә тели. Әмма мәхәббәткә киртәләр юк...*

*Мин бу тарихи җырны 1968 елның сентябрь аенда Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылында Вәйдә Нургалиева, Нәкыя Ишмакова, Белектә авылында Зәйтүнә Хәсәновадан язып алдым.*

*Зәйтүнә Хәсәновадан (1928 елгы) язып алынган өлеше:*

*... Буйны ла озын әй бус торына*
*Әллә нигә төрле бузнайтор ла.*
*Уйны ла йөрдем, кырны ла йөрдем,*
*Мөкәтдәр дә язмыштин узмайтор ла.*

*И... Әтерне лә тарытып укылар атытым*
*Кырда гына йөргән кийекләргә.*
*Газиз генә башны хурлар кыйлып,*
*Дуып калыпсың кийекләргә.*

*И... Ябышкан буе ярлар мигән,*
*Борынчылар күргән барлар мигән.*
*Газиз генә башны хурлар кыйлган*
*Җан сөйгән матур ярлар микән.*

*И... Иртә тә буран, кич тә буран,*
*Тармаклы буен алган ла сырау.*
*Шул җаныемны уйлай-уйлай*
*Сау гына башым булды ла сырхау.*

## Әйтүкәнең икенче җыры




Йөгерәләй куян баласы,
Мамык тикләй йонын туздыралай,
Ике лә гашыйк бер кушылса,
Әй җаныкай гынам, сылуым,
Шатлык белән гомер уздыралай.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылында Нургалиева Вәйдәдән (1898 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Мөлтәл

Борын-борын заманда булган, ди, бер ир белән хатын. Аларның булган җиде улы. Сигезенчесе туар алдыннан гына аталары үлеп киткән, ди.

Җиде егет үсеп җитеп, үзләренә кыз эзләргә китмәкче булганнар. «Их, әни, синең бер кызың да юк, без кыз эзләп кайтыйк. Әгәр син без югында кыз тапсаң, капка башына каба белән орчык куярсың, малай туса – ук белән җәя», – диләр һәм юлга чыгалар. Болар киткәндә әниләре бик елап кала. Ә бер атнадан аның кыз баласы туа. Кыз бала тугач, ул шунда ук капка башына каба белән орчык чыгарып куйган, ди.

Аларның күршесендә генә җиде-сигез яшьлек бер кыз яшәгән икән. Шул кызчык, каба белән орчык урынына, ук белән җәя китереп куйган.

Бер заманны җиде туган өйләнеп кайтканнар, кайтсалар, капка башындагы ук-җәяне күреп, әниебез тагын малай тапкан икән дип белеп, кире киткәннәр, ди.

Әниләре яңа туган кызга Мөлтәл исеме кушкан. Кыз, ай үсәсен көн үсеп, уйнарга әлеге күрше кызы белән чыккан.

Көннәрдән беркөнне күрше кызы әйтә моңа:

– Их, Мөлтәл, йөрисең бер ялгыз, синең бит җиде агаең бар, – ди.

– Каян килсен миңа җиде агай, – ди Мөлтәл, – юк минем бер кемем дә, – ди.

– Ышанмасаң, кайтып әниеңнән сора, – ди күрше кызы.

Мөлтәл әнисенә әйтә:

– Әни, бармыни минем җиде агаем? Кайда йөри алар? – ди. Әнисе әйтми. Шуннан Мөлтәл тагын күрше кызы янына керә.

– Юк минем бер кемем дә, мин ялгыз, – ди.

– Алайса, син әниеңнән бодай куырт, шуны кызган килеш күкрәгенә бассаң, әйтер, – ди теге кыз.

Мөлтәл өенә йөгереп кайта да: «Әни, ашыйсым килә, бодай куырып бир әле!» – ди. Әнисенә нәрсә, куыра да бирә. «Юк,

ашамыйм, – дип киреләнә Мөлтәл, – имәсем килә!» – ди. Әнисе аны, кочагына алып, имезә башлый. Мөлтәл шулвакыт аның күкрәгенә кызган бодай белән баса. «Бармы минем җиде агаем?» – дип аптырата. Әнисе бусында: «Бар», – дип әйтә. Мөлтәл яңадан күрше кызы янына кереп китә.

– Бар икән минем җиде агаем, – ди.

– Алай булгач, – ди дусты, – сип әниеңнән җил арба ясат. Эт, песи, әтәч алдыр... Җиде агаеңны эзләргә китәрбез, – ди.

Бик сорагач, әнисе җил арба ясап бирә. Эт, песи, әтәч сатып ала. Мөлтәл белән күрше кызы, җил арбага утырып, җырлый-җырлый китәләр:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Шулай баралар болар. Арба йөгерә, эт өрә, песи мыраулый, әтәч кычкыра. Бара торгач, бер күл янына җитәләр.

– Әйдә, су керәбез, – ди күрше кызы.

– Юк, мин кермим, ди Мөлтәл, – мин болай да таза, – ди.

Тагын торып китәләр. Тагын җырлыйлар:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,

Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Шулай тагын бер күлгә җитәләр. Иптәш кызы тагын су керергә димли. Мөлтәл бу юлы риза була. Аннан күрше кызы әйтә: «Әйдә чумабыз, кайсыбыз су астында озаграк торыр икән», – ди. Мөлтәл ничек тә озаграк торырга тырыша. Ул арада күрше кызы тиз генә судан чыга да, Мөлтәл киемнәрен киенеп, арбага утырып китеп бармакчы була. Җырлый:

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Тик җил арба урыныннан кузгалмый, эт өрми, песи мыраулямый, әтәч кычкырмый.

Мөлтәл елый-елый күрше кызы киемнәрен киенә дә арбага менеп утыра.

Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

Арба йөгерә, эт өрә, песи мыраулый, этәч кычкыра. Баралар болар, баралар, бара торгач, жиде агай янына килеп җитәләр.

Бу вакытта аларның кайсы токмач басып, кайсы бәрәңге әрчеп маташа икән. Күрше кызын сеңелләре дип белеп, алар аны күтәреп алалар, үз яннарына утыртып бик каты сынлыйлар. Ә Мөлтәлне ишек катына утырталар.

Кич булгач, йокларга яталар болар. Күрше кызын түргә, Мөлтәлне ишек катына гына яткыралар. Төн урталары узгач, аны ат эчертергә җибәрәләр. Әле таң атмаган. Айның якты чагы. Мөлтәл җырлый-җырлый ат эчерә:

Олы агайның атына
Тонык сулар эчерәм,
Уртанчы агай атына
Көмеш сулар эчерәм,
Кече агай атына
Алтын сулар эчерәм.
Аннары Айга карап:
И Айкаем, Айкаем,
Күрдеңме бәнем энкәем? –
дип җырлый. Ай аңа әйтә:
Күрдем сәнең энкәңне
Аяклы келәт алдында,
Ачкычлары кулында,
Эчәдер дә кичәдер,
Мөлтәл диеп елыйдыр, – ди.

Бер агасы моны чыгып тыңлап торган була. Ул, кереп, туганнарын уята да: «Әйдәгез әле, чыгыгыз, күл буенда кемдер бик моңаеп җырлый», – ди. Шуннан чыгып тыңлап торалар:

Олы агайның атына
Тонык сулар эчерәм.
Уртанчы агай атына

Көмеш сулар эчерәм,
Кече агай атына
Алтын сулар эчерәм...
И Айкаем, Айкаем,
Күрдеңме бәнем әнкәем?
Ай бу юлы да:
Күрдем сәнең әнкәйне
Аяклы келәт алдында,
Ачкычлары кулында,
Эчәдер дә кичәдер,
Мөлтәл диеп елыйдыр, – ди.

Җиде агайның җидесе дә Мөлтәлдән:

– Нигә болай моңланасың?– дип сорыйлар.

Мөлтәл үкси-үкси барысын да сөйләп бирә.

– Мине күрше кызы алдады, минем киемнәрне киенеп, хәзер сезнең сеңлегез булып утыра, – ди.

Абыйлары сеңелләрен күтәреп кайталар да күрше кызына, сынар өчен, эт савытына аш салып бирәләр. Ул аны шунда ук ашап куйган, ди. Төн урталары узгач, күрше кызын ат эчертергә җибәрәләр. Су буена барса, атлар эчми, тибешәләр генә, ди. Ай да күренми, ди. Көйләп карый, көе дә килми, ди.

Шуннан соң җиде агай киләләр дә, моның Мөлтәл түгел икәненә ышанып: «Сиңа ат койрыгы кирәкме, орлык тубалы кирәкме?» – диләр. «Ничек тә ярый, орлык тубалыннан орлык ашармын, ат койрыгына атланып чабармын», – ди хәзер теге. Алдакчы кызны орлык тубалына салалар да, ат койрыгына тагып, куып җибәрәләр.

Җиде агай, сеңелләре Мөлтәлне ияртеп, әниләре янына кайтып төшәләр, ди. Җидесе дә өйләнеп, сеңелләрен кадерләп, әниләрен сөендереп, баеп-бакшып әле дә шулай яшәп яталар, ди.

*Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Тимганова Талигадан (1912 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган.*

**«Мөлтәл» әкиятеннән назым**




Җил-җил арбам, җил арбам,
Җиде агайга җитәек.
Җидесен дә күрәек.
Өр-өр, этем, өр, этем,
Бүре килгән – сизәек.
Мыраула, песи, мыраула,
Тычкан килгән – сизәек,
Кычкыр, әтәчем, кычкыр,
Таң-таң аткан – сизәек.

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Тимганова Талигадан (1900 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## «Колган байның кызы» йомагыннан назым




Колган байның кыситем,
Колмашикәр атлитем,
Пусанак байның килнитем,
Бүскүс йегет йаритем. А инәй.
Аң.

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Мусина Фатыймадан (1900 елгы) һәм Рәфикова Хәбибҗамалдан (1899 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

«Колган байның кызы» әкиятенең тексты әлегә табылмады.

## БӘЕТЛӘР ҺӘМ ТАРИХИ ҖЫРЛАР

Татар фольклорында үзләренең язма әдәбиятка якын булулары белән башка жанрлардан аерылып тора торган әсәрләр бар. Бу – татар халык иҗатының лиро-эпик төренә кергән бәет жанры. Трагик вакыйгалар артыннан иҗат ителгән бәетләрнең нигезендә фаҗига, кайгы ята. Көлкеле вакыйгалар уңаеннан туган сатирик һәм юмористик бәетләр сан ягыннан бик аз. Бәетләрне – мәдрәсә шәкертләре, тарихи вакыйгаларның шаһитлары, сугыш бәетләрен шул сугышларда катнашучылар иҗат итә. Элегрәк авылларда трагик вакыйгалар уңаеннан бәетләр иҗат итүче талантлы кешеләр дә булган. Бәетләрнең традицион башлам өлешләре, уртак урыннары бар, яңа бәетләрне дә жанр кануннарына таянып иҗат итәләр. Бәетләргә карата язу түгел, чыгару сүзе куллану да аларның халык иҗатына каравын раслап тора.

Бәетләр, күпчелек очракта, язма хәлдә, дәфтәрдән дәфтәргә күчерелеп сакланган. Борынгы бәетләр, халыкта популярлашып киткән бәетләр телдән телгә күчеп йөргән, аларның үзләренең көйләре булган. Әлбәттә, популярлыгы ягыннан «Сак-Сок» бәете белән бер башка бәет тә тиңләшә алмый. «Сугыш бәетләре» дә бер аерым җирлек иҗаты булудан туктап, бөтен халыкта таралган. Халыкны тетрәткән вакыйгаларны яктырткан шәхси фаҗига бәетләре дә бөтен татарлар яшәгән җирләрдә таралып, андагы вакыйгаларның кайда баруын ачыклау мөмкин булмаган очраклар да аз түгел. Мәсәлән, исправник яки поп белән карта уйнап кызын попка оттырган «Мостафа мулла бәете» әлбәттә,

күз алдына да китермәслек вакыйга булып, татарлар яшәгән барлык төбәкләргә таралган. Бәет шулай ук «Зөлхәбирә бәете» исеме белән дә билгеле. Икенче иң еш очрый торган бәет дип «Суга баткан Гайшә бәетен» атарга мөмкин. Иртәгә туе буласы көнне елгага кер чайкарга барып батып үлгән бу кызның фаҗигасы да күпләрне тетрәндергән. Кызның батканын күреп, аны коткарырга ташланган кияү буласы егет тә батып үлә.

Бәетләр арасында сатирик эчтәлекле бәетләр булып, алар халык өнәмәгән, кабул итмәгән күренешләрне бәян итәләр. Мәсәлән, «Пракуб мәкүб», «Камали» бәетләре шундый бәетләрдән.

Бәетләр үзләренең эчтәлекләре, көйле булулары, рифмалары һәм төзелешләре, ике яки дүрт юллы строфадан торулары белән тарихи җырларга якын, бу жанрларның аерылып бетмәгән очраклары да бар. Мәсәлән, бер үк строфалар сугыш бәетләрендә дә, сугыш турындагы халык җырларында да очрарга мөмкин, ягъни алар җиңел генә бер жанрдан икенчесенә күчә ала.

Тарихи җырларда да тарихи шәхесләр, аларның эш-гамәлләре, мәхәббәтләре, тарихи вакыйгалар тасвирлана.

Тарихи җырлар белән дастаннар арасында да бәйләнеш зур. Кайбер татар дастаннары онытылуга дучар булып, аларның аерым строфалары җыр булып сакланып калган. Бу бүлектә бирелә торган «Мәрәтнең җыры», «Мәхмүт мәргән» җырларын онытылган дастаннарның кыйпылчыгы дип фаразларга мөмкин. Әлбәттә, «Хан кызы» җыры турында да шул ук сүзләрне әйтеп була.

*И. Закирова*

## БАИТЫ И МУНАЖАТЫ

Одним из самых популярных жанров традиционного наследия западно-сибирских татар являются баиты, люди старшего и среднего поколения с большим удовольствием и со всей серьезностью слушают «Сак-Сок», «Көйдем-яндым бәете», «Гыйбадулла бәете», «Баструк бәете» («Баит о тюрьме»), «Рус-япон сугышы бәете» и многие другие, в любом татарском ауле можно найти одного-двух «бәет әйтүче», знающих почти весь репертуар данной местности. Весьма одаренные исполнители знают баиты наизусть, другие же записывают их в специальные тетрадки, где можно прочесть и тексты лирических песен, мунажатов, любовно-стихотворных песен.

Тематика баитов «широкоформатна». Она охватывает многие стороны социально-экономической и семейно-бытовой жизни сибирских татар. Баиты – неписанная народная летопись устной традиции, где наибольшей полнотой высокохудожественным мастерством фиксируются важнейшие узловые события в жизни народа.

Самым популярным среди большинства этнических групп является «Сак-Сок бәете». Он стал почти обязательным репертуарным «минимумом» у многих «бәет әйтүче», певцов и музыкантов. Такое явление вызывает весьма разнообразное толкование не только поэтического текста, но и самого напева баита, например, в Усть-Илимском, Знаменском и Большереченьском районах Омской области преимущественное распространение получил следующий напев (см. стр. 267):

Әнкәй каргаты, әтекәй, күрдеңме,
Турандин оцытык, әтекәй, белдеңемә?
Әнкәй каргаты, Сак-Сок бултык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без[1].

Такой же напев бытует в Тобольском районе Тюменской области. Все они являются вариантами мелодии широкоизвестной песни «Хасбулат удалой»[2], оказывается, такое наблюдается не только в Западной Сибири. Например, куплеты «Сак-Сок» в Свердловской области имеют такую же аналогию[3]. На исключительную популярность данного напева указывает и композитор Дж. Файзи. В своей книге «Халык җәүһәрләре», о взаимовлиянии двух музыкальных культур он пишет следующее: «Характерно то: в трех помещенных в книге баитах чувствуется влияние русских народных песен. Древний баит «Сак-Сок» на Оренбургской стороне пелся на русскую народную мелодию «Хазбулат удалой». Приходилось услышать пение «Баита о двух братьях» («Ике туган бәете») на несколько отатариванную мелодию «Яблочки», в то же время о происхождении упомянутых двух русских народных песен может возникнуть вопрос «Не от татарского ли народа?»[4] Весьма любопытное заключение. Тем более оно принадлежит к композитору, (который родился в г. Оренбурге), вносившему заметный вклад в дело собирания, изучения и обработки татарской народной песни.

Мелодия «Хасбулат удалой» обслуживает не только баит «Сак-Сок». Например, в Усть-Ишимском районе Омской

[1] Запись автора и Ф. Урманчеева от Кучатовой Малики (1900) в деревне Б. Тебендя Усть-Ишимского района Омской области. Материалы 1968 г.

[2] Слова А.Н. Аммосова, музыка О.Х. Агреневой-Славянской.

[3] Об этом узнали у кандидата филологических наук М. Мухамадиева и И. Муфазалова, уроженцев дер. Васькино Нижнесергинского района Свердловской области.

[4] . *Фәйзи Җәүдәт* Халык җәүһәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. Б. 12.

области на эту мелодию поются куплеты свадебной песни «Яр-яр». Как правило, исполнение обрядовых куплетов на чужую, взятую извне, мелодию – чрезвычайно редкое явление. Возможно, что это вольная интерпретация самого исполнителя. И в этом случае мы можем обнаружить популярность данного напева. Так или иначе, в народном творчестве татар разных этнических территорий он пользуется сравнительно большой популярностью. Например, известная татарская революционная песня «Икенче садә», созданная под влиянием событий первой русской революции 1905 года, «исполнялась на несколько измененный мотив популярной русской городской песни «Хазбулат удалой»[1]. Такого же мнения придерживается З. Сайдашева[2]. В статье, посвященной татарским революционным песням, мы читаем: «Во вторую группу входят те революционные песни, которые были приняты путем изменения в некоторой степени старые, готовые мелодии. При использовании старых песен не только их слова, но и даже мелодии претерпели изменений. Эти изменения у разных песен происходит в разной степени. В песне «Вторая сада», например, чуждые татарской мелодии интонации, особенно интонации вводного тона, изменены».

Поистине удивительно сложная биография у этой мелодии. Выяснение национальной принадлежности ее – дело будущего, для этого нужны полевые записи не только среди татарского, но и русского народа. Это повествовательная песня типа баллады, как указывает Т. Попова, пользовалась значительным распространением в бытовом песенном репертуаре XIX века (и городском, и крестьянском). Для нас важно то, что песня поется на слова даровитого русского поэта А. Аммосова, оставшегося в

[1] *Музафаров М., Виноградов Ю., Хайруллина З.* Татарские народные песни. М., 1964. С. 64, 195.

[2] *Сәйдәшева З.Н.* Татар халкының революцион җырлары // Казан утлары. 1970. № 4.

свое время безвестным[1]. Сюжет песни взят из жизни горцев. Молодой князь за золотую казну, за коня, кинжала и винтовку хочет купить у старого, седого Хаз-Булата ее юную жену.

Опубликованный до этого в различных трудах баит «Сак-Сок» имеет лишь один напев с некоторыми изменениями[2]. Такой же вариант записан в новосибирской области (деревня Кошкулы Чановского района) от Каримуллы Хабибуллина, который исполнил на собственно изготовленном курае.

Он очень близок по своему мелодическому строению тому варианту, который бытует в Заказанье[3].

В некоторых баитах дореволюционного периода повествуются драматические события в жизни западно-сибирских татар. Тюменские татары и сегодня с большой любовью исполняют «Ибәтулла бәете» (или «Гыйбадулла бәете» – «Баит об Ибатулле»), где описывается произвол и беззаконие царских властей и их ставленников в Сибири. По преданию информатора Гани Бакиева (1912), Ибатулла с его братом Шигабутдином без суда и следствия были расстреляны урядником. Другие же информаторы сообщают об убийстве Ибатуллой самого урядника[4], и баит повествует о подлинных событиях в деревне Тарсук (или Учкун) Шадринского района курганской

---

[1] *Попова Т.* Русское народное музыкальное творчество. Т. II. М.: Музыка, 1964. С. 28, 62. Текст песни см.: Песни и частушки города и деревни / сост. А.С. Арнольдов. Тверь, 1927. С. 10–11.

[2] См.: Вопросы татарской музыки. Сборник научных работ КГК. Казань, 1967. С. 24; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967. С. 466; *Нигмедзянов М.* Татарские народные песни. Казань, 1976. С. 57.

[3] Запись автором собственного исполнения баита, усвоенного в детстве Б. Берези Арского района от Шамсикамары Лотфуллиной (1885–1956).

[4] Возможно, что эти данные соответствуют истине. Во всяком случае, в 4-ой книге «Ведомости справок о судимости», издаваемая министерством юстиции за 1914 год, в списке лиц, приговоренных к наказаниям под номером 61868 назван некий «Абдулвалиев Ибатулла Гиляш, 22 лет, К. Тюменск. у., Тугулымск в., юртъ Калачинских».

области. А сам баит с напевом как-будто принадлежит матери Ибатуллы.

*Гыйбадулла урак урып ятар иде,*
*Урагы ятып калды курасында.*
*Шуны әйтеп Гыйбадулла күп егълады*
*Ыстанавай периставның курасында.*

*Атарыңда сыер ята бозау белән,*
*Кызлар сачен үстерәләр сыйпау белән.*
*Әнекәсе карт кияүгә бирәм дисә,*
*Күс майларын сысдыралар йылау белән.*

Большое распространение получил баит так же в Курганской области[1], поэтическое содержание его почти совпадает с тюменским вариантом[2]:

*Ат аранда, сыер ята бозау белән,*
*Әнекәсе чәчен тарый майлау белән.*
*Габидулла чыгып китте олау белән*
*Әнекәсе күз бетерде егълау белән.*

Весьма интересное предисловие, которое раскрывает содержание и историю возникновения баита. «Среди исторических протяженных песен встречаются песни о беглецах, которые перенесли притеснения царских властей и о джигитах, участвовавших в войне 1812 года. Есть песни о казанских джигитах, которые убегая от преследований царских чиновников, оказались в Зауралье. Из таких... самым популярным во всем Шадринском и Шатровском районах является "Баит о Габидулле". Судьба этого баита очень интересна. Некоторые строфы баита в последние время обнаружены среди документов Пугачевского

[1] Устное сообщение языковеда Ф. Юсупова.
[2] Курган татарлары авыз иҗаты // Казан утлары. 1967. № 9.

восстания. По нашему мнению, Габидулла – выходец из казанских земель, участвовавший в восстании Пугачева, а затем отправленный царским правительством на ссылку. Во всяком случае, содержание баита намекает на это. Среди всех своих песен татары Курганской области особенно любят эту песню, среди людей старшего поколения почти нет человека, который бы не знал ее».

Установить подлинную личность Ибатуллы – Габидуллы – дело будущего и вероятно предмет других дисциплин. Если даже герой повествования является выходцем из Поволжья или другой местности, сам факт использования его трагедию в сюжете западно-сибирского баита весьма примечателен. В любом случае песня – баит имеет историческую ценность и является ярким звучащим реликтом неписанной летописи борьбы народа и его отважных сыновей против царских поработителей и угнетателей.

Среди барабинских татар был записан баит «Елашмагыз, туганнарым!» («Не плачьте, родные мои!») от Салимжанова Гильмана (1889) в деревне Кошкуль Чановского района Новосибирской области. Исполнитель не помнит историю создания баита. По его словам, баит бытует давно. (До этого он был записан на магнитофонную пленку в 1987 г. в деревне Шагир Куйбышевского района Новосибирской области от Маулютовой Хаернисы «Баструк бәете»).

*Кояш кебек ялтырап чыга*
*Падишамызның метале.*
*Ходай безгә язган икән*
*Җысыф пәйгәмбәр зинданы.*

*Аягымдагы читегем*
*Былчыратмадым герәзгә.*
*Брошения язып бирдем*
*Благородный зур кенәзгә,*

*Артымдагы карый урман,*
*Юкә суймадым имәндин.*
*Бадишага допрос бирдем*
*Төтен чыкканчы түбәмдин.*

*Алдымдагы агым суга*
*Кармак салдым ак балыкка.*
*Кафер патша малы өчен*
*Терләй салдылар тәмугка.*

*Мулла ясин укыганда*
*Кәфенем бәнем буенда.*
*Ун барабан сугыладыр*
*Бәнем актыккый туемда.*

*Столопка бәйләделәр*
*Кәфенемнең иңе берлән.*
*Утыз талга буядылар*
*Себер халкы мие берлән.*

Поэтический текст с незначительными изменениями совпадает с текстом баита «Сабир галькәй»[1], который выслала из деревни Тармакул Новосибирской области учительница Накия Ишмакова. В комментариях сообщается: «Нам пока неизвестны: по какому событию и когда сочинен баит, его появление и сказывание («әйтелүе») в сибирских деревнях. По своему содержанию и языку он походит на баит «Сабирулла ристан», записанного (записал Э.Касимов)... в Мордовской АССР»[2].

Как выяснилось позже, баит действительно принадлежит творчеству волжских татар-мишарей. Вот что сообщила нам Накия Ишмакова (Шамсутдинова): «Три мишара по

[1] Бәетләр. С. 145–146.
[2] Там же. С. 355.

имени Алтынбай, Муса и Хайбулла после окончания 25 летней царской службы в Енисейской тайге, останавливаются в г. Иркутске. Алтынбай исчезает, захватив вместе вымытое золото. Они встречаются с парнем из деревни Тармакуль, который приглашает их в свою деревню. Те остаются здесь жить и вызывают из деревни Петряксы Симбирской губернии свои семьи. Это случилось где-то в 1856 годах. Хайбулла 1806 г. рождения. Год призыва в солдаты – 1831».

Подтверждением вышеизложенного мог бы служить «Сабир бәете», записанный М. Нигмедзяновым у татар-мишарей с К. Пожарки Сергачского района Горьковской области. Текст его тот же.

Хотя имеется еле заметное интонационное родство, оба же музыкальных текста совершенно самостоятельны по всем своим музыкальным параметрам. Сравнение с напевами других баитов этого сборника, записанных у татар-мишарей, подтверждает самостоятельность сибирского напева.

Наиболее драматическое содержание имеет исторический баит – песня «Керәшен җыры» («Кряшенская песня»). Для ее исполнения используется известная мелодия песни «Асыл кошлар» («Прелестные птицы»). Мы полагаем, что поэтический текст привнесен в барабинские степи переселенцами. Встречается только в этой этнической группе. Основное содержание баита – насильственное крещение казанских татар, отлучение от веками исповеданного ислама. Безусловно, такая беспрецедентная в истории народов варварская политика царского самодержавия, направленная на идеологическое раздробление и лишение целостности татарского народа, встречала естественное сопротивление. Не имея возможности активно бороться за духовное единство, татарский народ в эту борьбу включил свое народное искусство. Оно через столетия рассказывает о бесчеловечных пытках тех, которые не хотели перейти в христианскую веру. «Ислам динебезне бозмам дисәк, тимер баса,

утка кыздырып». («Если скажем, что не изменим своей вере ислама, то обжигает каленым железом»). В баите воспевается стойкость простых людей, которые не хотели мириться с этим и уходили из своих родных мест. «Өч тройка җигеп чыгып киттек Мәдинә илинең үрендин» («На трех тройках выехали из деревни Медина»). Они проклинают тех, кто добровольно принял новую веру. «Гаптелҗәлил улы Гаптелвәли туңгыз булып купсын гүрендин» («Сын Габделжалиля Габделвали – пусть превратится в свинью в своей могиле»). Безусловно, основная масса мусульман покоряется судьбе, считая, что это послано им самим Всевышним. «Бар да бер Алланың язуы» («Все это от самого Бога»).

Сделаем маленький экскурс к баитам советского периода. В деревне Яргуль Куйбышевского района Новосибирской области тотчас же после трагической гибели дочери Загидуллиных Сонафраз Тимганова Талига сочинила следующий баит:

*Сара апа иртән торгачтын да*
*Килеп күреп китте кыз чагын;*
*– Кай җирләрдә әрәм булып ята микән*
*Ялтыратып муен мунчагын?*

*Бәгеркәем, сине эзләп йөрим,*
*Күтәреп карачы муйныңны;*
*Ничек жәлләмичә әрәм иттең*
*Бу хәдәрле зифа буеңны?*

*– Печәннәргә алып китте*
*Печәннәрне җыярга.*
*Төн буена уйлап йөргән*
*Минем башны җуярга.*

Этот факт говорит о том, что баиты были и есть самый оперативный вид традиционного народного музицирования,

в художественной форме отражающие любые наиболее критические моменты повседневной жизни. Для нас чрезвычайно важно то, что кроме традиционных, общенациональных образцов (например, «Сак-Соте», «Бает об утопленнице Гайше» и т.д.) бытуют те баиты, отражающие события непосредственно этой деревни. За основу сюжета берется местное событие, и главными героями являются люди опять этой деревни. Баиты мгновенно распространяются и получают широкую общественную огласку. Таким образом, при помощи баитов выражаются коллективное сочувствие семье и близким, которые потеряли дорогого им человека, осуждается или осмеиваются антиобщественные, аморальные действия. Любые отклонения от веками установленных привычных норм патриархально-родовой морали порождали баиты. Об этом очень образно писал Г. Тукай: «Иске; күчмә заманнардан калган гадәтме, ниндендер, безнең халык – шигырь вә җыр – бәетләр чыгарырга бик маил (һәвәсле, яратучан. – *И.К.*) халык. Чү, аз гына бернәрсә “шылт” иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәетләр чыга».

Баиты являются жанром общетатарского порядка. У других тюркоязычных народов, кроме башкирского, они не встречаются. Однако башкирские баиты, по мнению самих же башкирских исследователей (А. Харисов, С. Шлин), возникли под воздействием татарского фольклора. Такая же аналогия возможна и с западно-сибирскими баитами. Мы полагаем, что баиты привнесены в эти края переселенцами татарами из разных областей Поволжья. Подтверждением этому суждению могла бы служить стилевая близость баитов обоих этнических территорий. Они проявляются прежде всего в интонационно-ладовом строе напевов, тематико-сюжетном единстве поэтических текстов, в форме бытования, традиций создания и исполнения. Благодаря устойчивости эпических произведений (особенно в барабинской

группе), баиты влились в народное творчество Сибири как его органическая часть.

И там и здесь баиты создаются на заранее определенный напев – формулу. У «бәетче», как правило, не остается времени на создание нового напева, т.к. это чрезвычайно трудная работа. Она требует от исполнителя образного музыкального мышления. Этим даром «бәетче» может и не обладать. А откликнуться сегодня же на происходящее «событие своим поэтическим даром – он «обязан».

Советская наша действительность с ее качественно новыми социально-экономическими отношениями, да и внутренние закономерности стадий развития самого жанра обусловили нынешнее его состояние. Следует подчеркнуть особо татарский, что наряду с повсеместным распространением и сравнительно активным бытованием традиционных баитов, репертуар жанра в количественном отношении заметно убавляется. С каждым годом все реже и реже становятся те выдающиеся умельцы, которые были бы способны создавать новые баиты на тематику наших дней. Сегодняшние «бәет әйтүче» это хранители общетатарского классического репертуара и наиболее оригинальных локальных образцов. Из вышеизложенного проясняется основная тенденция современного положения баитов – жанр давно уже вступил в специфическую полосу развития в сторону неуклонного угасания. Основным импульсом бытия остается инертность.

Относительно периодов развития баитов весьма любопытные наблюдения имеются у фольклориста-филолога Ф. Урманчеева. «Гомумән, элекке бәетләр белән совет чоры бәетләрен чагыштырып караганда, аларның эчтәлегендә һәм поэтик формаларында шактый зур аерма барлыгы күзгә ташлана... безнеңчә, бәетләрнең фольклор жанры буларак чәчәк аткан чоры XVI–XIX йөзләргә һәм XX йөз башына кайтып кала. Бөек Ватан сугышыннан соң хәзерге заман темасын яхшырткан югары ху-

дожестволы бәетләрнең язылып алынмавы да шул ук фикерне раслый»[1].

Изучая баиты не следует упускать из вида, что предметом изучения музыкальной фольклористики являются его музыкально-стилистические параметры, хотя по единодушному мнению фольклористов-филологов и этномузыковедов в большинстве баитов основную жанровую функцию берет на себя его поэтический текст. Однако, в сибирских баитах это положение не всегда имеет основополагающего значения, т.к. баиты не изолированы от других песенных жанров. Они исполняются теми же музыкально-одаренными певцами, которые имеют в своем репертуаре не только множества песен, но и мунажатов. В силу этого, именно у таких исполнителей скрещиваются стилевые признаки «көйләү» и пения. Отстоящиеся в течение многих веков западно-сибирские баиты со своим арсеналом средств выразительности, необычайно устойчивым музыкальным языком и непревзойденным оригинальным поэтическим мышлением имеют очень глубокие коренные связи с другими песенными жанрами и мунажатами.

Баит западно-сибирских татар как жанр эпического порядка в наши дни теряет свои утилитарные и эстетические позиции. Несмотря на это, средства выражения поэтические и музыкальные не отбрасываются и не забываются. Они входят как составные части в другие песенные жанры. Тем более баиты как отмечают фольклористы, развивались взаимодействуя с другими жанрами. В связи с этим перед нами встает одна характерная особенность западно-сибирских, да и не только западно-сибирских баитов. В них весьма не однороден характер связи поэтического текста и музыки. На такое своеобразие указывают фольклористы – музыковеды и филологи.

---

[1] *Урманчеев Ф.* «Татар халык иҗатының кайбер мәсьәләләре // Татар теле һәм әдәбияты», өченче китап. Изд-ние ИЯЛИ АН СССР. Казань, 1965, С. 64.

Обратимся к филологическим трудам. И. Надиров при анализе баитов периода Великой Отечественной войны указывает на них влияние народных песен. «Үзләренең композицион бөтенлекләре, логик эзлекле булулары һәм сәнгатьчә матур эшләнеше белән алар (“Салих бәете”, “Сүнмәс хәсрәт” – *И.К.*) безнең кайбер сюжетлы җырларны хәтерләтәләр. Борынгыдан килгән гадәт буенча, бу бәетләрнең нинди дә булса көйгә җырланып йөртелүендә, шуның нәтиҗәсендә камилләшүләрендә шик юк»[1].

Ф. Урманчеев, на анализе некоторых баитов того же периода, замечает следующее: «Бу бәетләрдә вакыйганы сурәтләү икенче планга күчә; аларда геройның хис-кичерешләренә зур урын бирелә. Үзләренең гомуми характерлары, образлары, лирик буяулары белән бу бәетләр лирик җырларга һәм шигырьләргә бик якын»[2].

Х. Ярми, говоря о баитах татар-мишарей, пишет о том, что фольклорным экспедициям не удалось встретить баитов, сохранившихся в письменном виде. «Татар-мишәрләрдә һәрбер бәетнең үзенә махсус көе бар һәм һәрбер бәет үз көе белән яттан әйтелә. Кайбер бәетләрне сюжетлы җырлардан, җырны бәеттән аеруы да кыен. Мәсәлән, ... формасы белән бәет дип саналырга тиешле булган «Әбдулман купич»не сюжетлы җырдан аерып алуы бик читен. Монда инде лиро-эпик бәетләрнең сюжетлы җырларга якын тору мәсьәләсе килеп баса, һәм бу мәсьәлә аерым рәвештә тикшерүне таләп итә»[3].

Обратимся к музыковедческим работам. Например, М. Нигмедзянов в предисловии к книге «Татарские народные песни» пишет: «Отступая от стиля эпического, спокойного повествования, баит испытывал влияние лирической протяжной песни, иногда в зависимости от содержания приобретал активные и

---

[1] *Надиров И.Н.* Халык һәм җыр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. Б. 92.

[2] *Урманчеев Ф.И.* Совет чоры бәетләре // Казан утлары. 1966. № 6. Б. 117.

[3] *Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казань, 1967. С. 115.

драматические интонации... Таким образом, исполнители, стремясь отразить образнопоэтический склад баита, значительно расширили его стилистические пределы, придав этому жанру большую эмоциональную емкость. Все это привело к тому, что в ряде случаев трудно отличить лирическую песню от баитов, и наоборот»[1]. Далее автор приходит к весьма важному для татарской музыкальной фольклористики выводу: «При определении жанра в аналогичных случаях следует исходить из характера и типа поэтической образности текста и из мелодического содержания песни»[2]. Все сказанное наталкивает на мысль, что эволюция и становление лирической песни как в особый самостоятельный жанр должно рассматриваться и на базе баитов. Баиты легли в основу многих жанров татарского песенного творчества и определили в некоторой степени их особенности. Безусловно, тесная связь двух жанров, перекрещивание их стилистических черт прежде всего обнаруживается в так называемых исторических песнях.

Примером тесного взаимопроникновения баита и песни мог бы служить популярный среди калмаков Кемеровской области «Җир бәете» («Баит о земле»), который был сочинен в 1905-х годах С. Таминдаровым в деревне Искитим (Эскәтем) Юргинского района. Автор баита – известный певец-импровизатор во всем округе. Для распевания своего баита он использовал напев широкоизвестной песни среди калмаков «Тау башында таш тегермән» («Мельница на горе»). Из песенной мелодии остался только в тезисной форме интонационно-мелодический каркас, целиком подчиненный речитативному повествованию.

Примером жанрового «несоответствия» напева и поэтического текста является «Баит о Салиме», для которого используется мелодия известной башкирской народной песни

[1] *Нигмедзянов М*. Татарские народные песни. С. 9.
[2] Там же. С. 9–10.

«Карабай»[1]. В песенном быту башкир она одна из самых популярных шуточных такмаков, возникших еще в дореволюционное время, на основе подпевания напеву плясовой, исполняемой на курае»[2]. Однако такмачный напев при исполнении баита медленно распевается, тем самым приближается к протяжной лирической песне, обретает печально-повествовательный характер.

Необходимо особо выделить из всего музыкально-поэтического творчества западно-сибирских татар своеобразного жанра «мунажат»[3], который имеется в репертуаре исполнителей среднего и старшего поколения. Мунажаты, как известно, имеют

---

[1] Следует особенно отметить то, что это не единственный случай творческого заимствования. Например, в Заказанье (дер. Б. Березі) Н. Берески и др. Арского района ТАССР) на мелодию «Карабая» дети поют новогоднюю песню «Чыршы җыры» («Песня о елке»).

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе;
Син тагы да матуррак
Бизәлгәнсең бу юлы.

[2] *Лебединский Л.Н.* Башкирские народные песни и наигрыши. М.: Музыка, 1965. С. 217.

[3] Мунажат аналогичен русскому духовному стиху. Среди заболотных татар его называют «сикер». «Закер» – закр (радение мусульманских сектантов; зикер әйтү – читать молитву, воздавая хвалу». См.: Татарско-русский словарь. М.: Сов. энцик., 1966. С. 154. Некоторые дервиши (напр., в Египте и Персии) пользуются и доселе хашишем для приведения себя в желаемое настроение, но наиболее употребительным средством для достижения экстаза служил «зикръ», буквально «упоминание» имени Бога». См.: Материалы по мусульманству. Вып. III, Ташкент, 1898. С. 8; Слово встречается и в татарских баитах. Например:

Төрекләр каладан чыкканда,
Зекер әйтеп чыгалар;
Ядрә килеп тигәчтен,
Чәчрәп каннар чыгалар.

Зекер әйтеп – дини ерлар ерлап (пение религиозных песен). См.: Халык җырлары / сост.: Х. Ярми, А. Ахмет. Казань, 1940. С. 89.

религиозное содержание. В образно-поэтическом построении в них преобладает обязательное описание загробной жизни и готовит мусульман к «великому подвигу перед Всевышним».

Мунажаты, безусловно, привнесенный жанр в эти края проповедниками ислама. После принятия западно-сибирскими татарами мусульманства и установления религиозных праздников в быт начали проникать с запада – от казанских татар и татар-мишарей, а с юга – от бухарцев, обряды и песнопения при чтении священных книг. Их носителями были представители духовенства, которые получили профессионально-религиозное образование в лучших медресе Самарканда, Бухары и Хивы, даже Каира. Именно в медресе они разучивали песнопение макамом, т.е. мотивом.

Вот что об этом пишет музыкант-этонграф С. Рыбаков: «В медресе (высшее мусульманское духовное учебное заведение. – *И.К.*) сосредоточивается вся татарская грамотность и письменность, из них же выходят произведения книжного сочинительства и известные под названием мунажат и баит. Это нечто вроде религиозных и светских поэм и стихотворений поучительных или повествовательных или на злобы дня из жизни народной. От татар эти продукты искусственного сочинительства распространяются среди других инородцев...»[1].

По свидетельству С. Рыбакова мунажаты принадлежат перу определенных грамотных личностей, главным образом, мулл из татар. Они исполняются «в солидных собраниях, религиозных и т.п. и имеют успех среди класса степенных, пожилых правоверных, считающих неприличным для себя и за грех петь чисто народные лирические песни, особенно скорые... Стихотворения книжного происхождения отличаются своей длиною и имеют каждое свою мелодию»[2].

---

[1] *Рыбаков С.Г.* Музыка и песни Уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897. С. 14.

[2] Там же. С. 45–46.

Весьма любопытны наблюдения Н.В. Никольского: «В столице Болгарского, а затем Казанского царства заводятся школы, где самое преподавание большинства предметов ведется нараспев. Усвоение пришлых напевов было обязательно не только потому, что учащиеся были мусульмане, но и потому, что их задача по выходе из школы состояла в насаждении мусульманской науки и пении среди простого народа... Влияние ислама на поволжские народности, а чрез него и арабской музыки, проникало в среду тюркских и финских народностей Поволжья, также путем житейских сношений и соответствующей школьной литературы»[1]. Экспедиционные наблюдения показывают, что в Западной Сибири исполнителями мунажатов выступают обычно или сами служители духовенства или же особо грамотные: пользующиеся всеобщим уважением и доверием верующих, но музыкально-поэтически одаренные люди. Итак, мунажаты, как нам представляются, – духовное песнопение официального назначения, торжественно-обрядовый вид профессиональной музыки устной традиции.

Песнопенное чтение священных книг является уделом только лишь официально признанных представителей духовенства. Функция песнопения – сосредоточить внимание коллектива верующих на непонятное для основной массы слушателей содержание Корана и других священных книг и при этом воздействовать на чувства и мысли, удовлетворяя одновременно, в какой-то степени.

Психо-физиологическое воздействие на массы, использование магической и утилитарно-организационной роли в нем музыки заимствованы мусульманством из язычества. Как справедливо пишет по данному вопросу Л. Гошовский, «...как посредник между человеком и богом и мог разговаривать с ними перед народом только пением или мелодическим речитативом.

---

[1] *Никольский Н.В.* Конспект по истории народной музыки у народностей Поволжья. Казань: Первая Государственная типография, 1920. С. 35

Вот почему и до сих пор во всех культах чтение священных книг во время обряда совершается необычной разговорной речью, но своеобразным мелодическим речитативом или чтением нараспев (т.н. псалмодия)»[1].

В наше время потусторонняя жизнь, изложенная в мунажатах полностью отвергаются как религиозные пережитки прошлого. Но тем не менее они как памятники тысячелетнего пути народа, живущего под этой идеологией, представляют определенный интерес для всестороннего исследования музыкально-поэтического творчества татарского народа. Хотя мунажаты составляют и специфический жанр народного творчества, их нельзя и не правомерно рассматривать в отрыве от других песенных жанров и баитов. Все они составляли и сейчас составляют в некоторой степени неразрывное целое музыкального быта сибирских татар.

Мунажаты требуют пристального внимания исследователей, в первую очередь, музыковедов, т.к. выявление музыкально-стилистических особенностей мунажатов поможет полнее изучить интонационно-ладовую специфику других жанров. Мунажаты именно тот жанр, который служит мостом при изучении не только баитов, но и песенных жанров. Поэтому публикация мелодических образцов и исследование их применяя все аргументы музыкальной фольклористики неоправданно затягиваются из-за поэтического содержания. Хотя тексты мунажатов, в отличие от подлинных народных песен, насыщены арабизмами, перешедшими в них из мусульманских молитв, в том числе и из Корана, музыкальный язык глубоко народный.

Наши наблюдения, базирующиеся исключительно на материалах полевых экспедиций, убедительно показывают живучесть жанра до настоящего времени. Особенно сильное эстетическое и моральное удовлетворение от них получают те люди

---

[1] *Гошовский В.* У истоков народной музыки славян. М.: Сов. композитор, 1971. С. 44.

старшего поколения, которые в дореволюционных школах (мәктәп) и медресе пели на специальные мелодии отрывки учебных книг «Бакырган», «Мухаммадия», «Бадавам» и др. И сегодня во время религиозных праздничных застолий, при поминках на 3, 7, 40 день и в годовщину мулла или абыстай до чтения молитв напевают мунажаты, тем самым создают определенный музыкально-поэтический настрой присутствующих. Искусство некоторых настолько велико, что собравшиеся слушают со слезами на глазах.

Нужно иметь в виду то, что при этом могут присутствовать люди неверующие любых возрастных групп, в том числе молодые и дети. Хотя текст мунажатов менее понятен для основной массы присутствующих, но музыкальный язык более понятен и ясен.

Это не единичный случай в музыкальной практике. Например, современный человек с большим удовольствием слушает и напевает музыку совершенно незнакомых ему народов, хотя ему не понятен будет смысл текста. Там и здесь важен сам напев и его исполнение, создание у себя определенного настроения при помощи музыкальных образов. Именно они являются межнациональными.

Из вышесказанного ясно одно – изучение мунажатов диктуется не только запросами науки. Пока существует религиозные предрассудки в сознании определенных групп людей, пока существуют религиозные обряды и праздники, будут жить и мунажаты. А самое главное в бытовании этого жанра среди западно-сибирских татар то, что в настоящее время основными носителями и повседневными исполнителями являются народные певцы и баитче. Среди них можно выделить Сабитову Бибинур (1895) из деревни Байкал, Янгулову Фаузию (1910) из деревни Исат Ялуторовского района, Тазетдинову Джамилю (1906) из деревни Лайтамак Тобольского района Тюменской области; Фахрутдинову Валию (1899) из деревни Тусказан

Большеречинского района, Маматалиеву Фархи (1905) из деревни Б. Тибендя Усть-Ишимского района Омской области и др.

Основу мунажатов, собранных среди западносибирских татар, составляет ангемитонная пентатоника. Мунажаты с олиготонными ангелитонными ладовыми формами не обнаружены. Пентатоника имеет три разновидности: две из них – звукоряды без тонической терции. Как известно, они типичны, главным образом, для традиционных напевов далекого прошлого казанских татар[1].

Мелодика мунажатов характеризуется основной чертой мелодического развития традиционных народных песен казанских татар – ангемитонная поступенность. Кроме этого ей присуще плавное волнообразное движение без больших скачков в обоих направлениях, за исключением большой терции и кварты через ступень. Во всех случаях финальный нижний звук имеет тоническую функцию. Следует при этом заметить, что эта закономерность единственная и всеобщая для всех жанров народной музыки любой этнической группы татарского народа. Это возможно только при генетической связи музыкальной статистики мунаджатов с другими народно-песенными жанрами.

Собранные немногочисленные записи мунаджатов не позволяют полнее проследить достаточно долгий путь эволюции жанра. Несмотря на это, мелос мунажатов, складывающийся прежде всего из мелодики и ладового строения говорит о нерасторжимой связи мунаджатов с народной татарской песенностью. В этом и нужно искать основную ценность мунажатов для музыкальной фольклористики.

*И. Кадыров*

---

[1] *Нигмедзянов М.* Татарская народная песня в обработке композиторов. Казань, 1964. С. 131.

## «Башмагым» җыры

*Кыз:*

Башмагымның башы башка,
Басмас идем мәрмәр ташка,
Бирсә егет башмагымны,
Мин алдандым башым яшькә.

– Урманда агач шаулыйдыр,
Әткәем башмак даулыйдыр,
Әнкәй дә шуны каулыйдыр,
Бирче, егет, башмагымны?

*Егет:*

Урманда агач шаулыйдыр,
Әткәң дә башмак даулыйдыр.
Минем башларым аурыйдыр,
Сине бүтәннәр яулыйдыр.

*Кыз:*

Башмак башы аклы-кара,
Таң йолдызы сызылып бара.
Бирсәң егет башмагымны,
Син генә алдың, йөзең кара.

*Егет:*

Башмак башың юеш булса,
Башмак бавың кереш булса,
Шунда бирәм башмагыңны,
Телләр биреп үбеш булса.

– Көннәр арты көннәр уза,
Яшь егетнең йөзе сула;
Сине күрсәм, күңелем була,
Тукта, бирәм башмагыңны!

– Башмак йөзе яшел була,
Яшел җире чуклы була;
Кыз баланың күңеле тула,
Менә бирәм башмагыңны.

*Омск өлкәсе Тәвриз районы үзәгендә Маликова Зәнифә Баһаветдин кызыннан (Боговитьевна) (1947 елгы) И. Закирова тарафыннан язып алынган.*

*Информант шушы ук районның Отыз авылында туып үскән.*

## Башмагым




*Кыз:*

Башмагымның башы башка,
Басмас идем мәрүәр[1] ташка;
Мин алдандым башым яшькә,
Бирсәнә, егет, башмагымны[2].

*Егет:*

Бер башмагың простой чуклы,
Бер башмагың яшел чуклы;
Әйтеп-сөйләп йөрмә юкны,
Мин алган юк башмагыңны.

---

[1] Мәрүәр – мәрвәр, энҗе.
[2] Өченче һәм дүртенче юллар кабатлана.

*Кыз:*

Атлас юрганнар ябыем,
Мамык мендәрләр салыем;
Үбеп-кочып йоклатырмын,
Бирсәнә, егет, башмагымны.

*Егет:*

Мамык мендәрләр салсаң да,
Атлас юрганнар япсаң да,
Үбеп-кочып йоклатсаң да,
Мин алгам юк башмагыңны.

*Кыз:*

Ат яхшысы ала була,
Алалары кола була;
Әткәм тойса, бәла була,
Бирсә лә, егет, башмагымны.

*1968 елның 4 июлендә Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Саургач авылында Разулев Шәфыйкъ (1913 елгы, 55 яшь) һәм Разулева Сафиядән (1915 елгы, 53 яшь) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*«Башмагым» җыры*

*«Башмагым» – татар халкының классик җырларының берсе. Хәзерге вакытка кадәр төрле региоонарда узган экспедицияләр вакытында «Башмагым» җырының күпсанлы вариантлары еш очрый. Бу җырның жанрына карата фольклорчылар арасында ике төрле караш яши. Мәсәлән, Х. Ярми аның бәет жанрына каравын яза[1], И. Надиров кара-каршы җырлана торган җырлар рәтенә кертә[2]. Татар халкының лиро-эпик жанрларына караган*

---

[1] *Ярми Х.* Бәетләр. Казан, 1960. Б. 192.

[2] *Надиров И.* Татар халык җырлары. Казан, 1955. Б. 220.

*татар бәетләрен өйрәнгән Ф. Урманчеев исә «Башмагым»ны игътибарсыз калдыра*[1]*.*

*М. Нигъмәтҗанов җырның килеп чыгышын бәеткә бәйли. «Гәрчә аларда бәетнең структур нигезе ачык күренеп торса да, кайбер бәетләрнең көйләре, еш башкарылып, озын җырларга әверелде. Мәсәлән, «Тәфтиләү», «Башмагым»*[2]*. А. Ключарев*[3] *һәм М. Мозаффаров*[4] *«Башмагым»ны җырлар рәтенә кертәләр.*

*Г. Тукай да үз заманында гаять популяр булган «Башмак көе»н бәет дип күрсәтми, ә «Сак-Сок» турында исә «бәет вә көе» дип яза: «Бу Башмак көе дә мөфти вә мирзаларыбыздан зур фамилияле бер кешегә чыгарылган көй булырга кирәк. Ләкин тәгаен кемгә вә ни хосуста чыгарылганын, мәгаттәәссеф, тәфтиш (тикшерү) итә алмадым. Бу көй, зан идәрсәм (уйлыйм ки), бер заман хөкүмәт тарафыннан җырланырга мәнгы да ителгән (тыелган) иде, бугай»*[5]*.*

*«Башмагым» җырының шигыре революциягә кадәр дә һәм аннан соң күп мәртәбәләр төрле китапларда басылган. Аны 1901 елда Хельсинки шәһәрендә фин галиме, лингвист Х. Паасонен «Татар җырлары» исеме белән немец телендә басылган хезмәтенә дә кертә. Ул текст1899 елда элекке Самара губернасы Бөгелмә өязе Чагатай авылында Мөбәрәкша җырлаганча бирелгән.*

*Г. Ибраһимов исемндәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә җырның фольклор экспедицияләре вакытында язып алынган күпсанлы вариантлары саклана. Х. Ярми шуларның бер нөсхәсен «Бәетләр» китабына кертә. «Искәрмәләр» бүлегендә исә 1955 елда Х. Ишмаметовтан язып алынган һәм,*

---

[1] *Урманчеев Ф.* Халык авазы. Казан, 1974.

[2] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967.

[3] Татарские народные песни / составитель и собиратель А.С. Ключарев. Казань: Таткнигоиздат, 1955. С. 200

[4] Татарские народные песни». С. 47.

[5] *Тукай Г.* Әсәрләр. Дүрт томда. Т. 2. Казан: Таткнигоиздат, 1955. Б. 258.

*«Башмагым» исеме астында йөртелеп, әдәби эшкәртелгән бер варианты» булуы әйтелә.*

*Бу урында шуны билгеләп үтү урынлы булыр: «Башмагым» көе татарлар яшәгән барлык регионнарда да очрый. Бу китапта, себер татарларының халык иҗатына багышланган хезмәт буларак, Себердә язып алынган вариантларны гына бирәбез. Җырның сүзләрен төрле елларда фольклорчы галимнәр Х. Гатина, Ф. Урманчеев, И. Закирова себер татарларыннан Омск, Төмән, Омск өлкәләрендә язып алганнар.*

*«Башмак» көе зур сәхнә әсәрләренең музыкаль лейтмотивына да әйләнде. Мәсәлән, XX гасырның 30 нчы елларында драматург, композитор-мелодист Хәбибулла Ибраһимов һәм композитор Мөсәлим Вәлиев*[1]*, 1942 елда композитор Җ. Фәйзи «Башмагым» исемле музыкаль комедияләр язалар.*

---

[1] *Атанова Л.* Масалим Валеев. Уфа: Башк. кн. изд-во, 1970. С. 10.

## Хан кызы

«Хан кызы» егет белән кызның кара-каршы әйтешенә корылган мәхәббәт турындагы әсәр булып, галимнәр арасында аның кайсы жанрга каравы турында бердәм караш юк. Мәсәлән, тарихчы һәм археограф Миркасыйм Госманов аны югалган дастанның өзеге дип карый[1], «Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар» томын төзегән фольклорчы галим Илбарис Надиров мәхәббәт турындагы лирик җырларга кертә. М. Госманов билгеләп үткәнчә, әлеге әсәр берничә төрки халыкның уртак мирасы[2] булып тора. Мәсәлән, аның хакас вариантын Н.Ф. Катанов язып алган, бу текст В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» дигән хезмәтенең 1907 елда дөнья күргән IX томында басылып чыга.

Әсәр егет белән кызның шаярып сөйләшүе – кара каршы әйтеш формасында. Егет кызның ишеге янына килеп, үзен кертүен сорый:

Хан кызы, ач ишегең, бән керәем…

Кызның матурлыгы турында күп тапкырлар ишеткән егетнең, кызның үзен күрәсе, үз күзләре белән бу матурлыкка инанасы килә.

Сәнең буең зифа диләр, бән күрәем…

Кыз егетнең һәр сүзенә җавап таба. Мәсәлән, үзенең зифа буен су буенда үскән тал-чыбык белән, вак тешләрен энҗе белән чагыштырып, егеткә шуларны карап, кызны күзалдына китерергә куша.

Кыз, егеттән бу рәвешле «котыла» алмагач, егетне үзенең ата-анасы, агалары, энеләре, ахырда тәкәсе, эте белән куркыта

---

[1] *Госманов М.* Каурый каләм эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 224.

[2] Шунда ук.

башлый. Бу очракта егет кызның һәр сүзенә җавап биреп, үзенең алардан курыкмасын әйтә.

Аулак өйләрдә, туйларда башкарылган. «Хан кызы»ның күпсанлы вариантлардагы текстлары фәнни экспедицияләр вакытында Россиянең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә дә язып алынуы аның халыкта популярлыгын күрсәтеп тора.

### Илаһи матур хан кызы

1. Һавадин очып йөргән кош дәгелме?
   Егетнең җаны сөйгәне кыз дәгелме?

2. Бер кич бардым кыз катына – күзәттеләр:
   Унике чукмар белән озаттылар.

3. Бар әйтеңез ярыма: кайгырмасын,
   Сул кабыргам кыңгыр иде – төзәттеләр.

4. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
   Сәнең буең зифа дирләр, бән күрәем.

5. – Бәнем буем зифасын сән нидәрсән?
   Сазда үскән тал-чыбыклар күрмәймесән?!

6. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
   Сәнең бармакың нечкә дирләр, бән күрәем.

7. – Бәнем бармакым нечкәсен сән нидәрсән?
   Сазда үскән сары камыш күрмәймесән?!

8. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
   Сәнең сачың кара дирләр, бән күрәем.

9. – Бәнем сачым карасын сән нидәрсән?
Асламчыда кара ефәк күрмәймесән?!

10. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең кашың кара дирләр, бән күрәем.

11. – Бәнем кашым карасын сән нидәрсән?
Шәкертләрдә кара каләм күрмәймесән?!

12. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең күзең кара дирләр, бән күрәем.

13. – Бәнем күзем карасын сән нидәрсән?
Шәһәрләрдә кара түмә күрмәймесән?

14. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең агызың кечкенә дирләр, бән күрәем.

15. – Бәнем агызым кечкенәсен сән нидәрсән?
Асламчыда алтын уймак күрмәймесән?!

16. – Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең дешең вак дирләр, бән күрәем.

17. – Бәнем дешем ваклыгын сән нидәрсән?
Базардагы йенҗү-мәрҗән күрмәймесән?!

18. Тәнем егет, җаным егет, кермә егет,
Бәнем атам усал кеше, күрсә сүгәр.

19. – Атаңа алтын таяк бән бирәем,
Мәсҗет юлын күрсәтүбән йибәрәем.

20. – Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,
Бәнем анам усал кеше, күрсә сүгәр.

21. – Анаңа алтын тарак бән бирәем,
Мунча юлын күрсәтүбән йибәрәем!

22. – Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,
Бәнем агам усал кеше, күрсә сүгәр.

23. – Агаңны акбүз атка мендерәем,
Шәһәр юлын күрсәтүбән йибәрәем!

24. – Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,
Бәнем җиңгәм усал кеше, күрсә сүгәр.

25. – Җиңгәңә челтәрле чана бән бирәем,
Атасының өенә йибәрәем!

26. – Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,
Бәнем энем усал кеше, күрсә сүгәр.

27. – Энеңә матур кызый бән бирәем,
Шәһәр юлын күрсәтүбән йибәрәем!

28. – Тәнем егет, җаным егет, кермә, егет,
Бәнем тәкәм – усал хайван, күрсә сөзәр.

29. – Тәкәңә олуг кәҗә бән бирәем,
Абзар юлын күрсәтүбән йибәрәем.

*Текст Миркасыйм Госмановның «Каурый каләм эзеннән» (Казан, 1994. Б. 209–211) китабыннан алынды.*

## Кан кызы




Кан кызы, ач ишегең, бән керәйем,
Сәнең йөзең нурлы диләр, бән күрәйем.

Бәнем йөзен күреп сиңа нидер файда,
Сатучыда күрмәдеңме кызыл алма?

Кан кызы, ач ишегең, бән керәйем,
Синең буең зифа диләр, бән күрәйем.

Бәнем буем күреп сиңа нидер файда,
Су буенда күрмәдеңме буй-буй камыш?

*1969 елда Томск өлкәсе Томск районы Яүштә авылында Низаметдинов Гомәр җырлаган (1895 елгы, 74 яшь). Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Кан кызы




Кан кысы, ац ишегең, мин герәйен,
Пуең сифа тип әйтәләр, мин күрәйен!

Агыйтелтә күрмәйсеңмә пуй-пуй гамыш?
Агыйтелтә күрмәйсеңмә пуй-пуй гамыш?

Кан кысы, ач ишегең, мин герәйен,
Чәчең осын тип әйтәләр, мин гүрәйен!

Сатучыта күрмәйсеңмә кара ленты?
Сатучыта күрмәйсеңмә кара ленты?

Кан кысы, ач ишегең, мин гүрәйен,
Тешең ак-вак тип әйтәләр, мин гүрәйен!

Сатучыта күрмәйсенмә вах-вах йенче[1]?
Сатучыта вак-вак йенче күрмәйсенмә?

*1971 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Лаймтамак авылында Исәнярова Зинникамал җырлаган (1927 елгы, 44 яшь). Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Җырчының әйтүенә караганда, «Хан кызы» яшьләр кичәләрендә, аулак өйләрдә һәм туй мәҗлесләрдә кара-каршы җырланган.*

*«Хан кызы»ның жанрын филологлар бәет дип билгелиләр. Аны беренче мәртәбә Х. Бәдигый бастырып чыгара. Әсәрнең тагын бер вариантын Х. Ярми язып алган.*

*Яшь егет белән кызның бер-берсенә тапкыр сүзләр әйтеп кара-каршы җырлый торган лирик җырлары үзбәкләрдә, таҗикларда һ.б. халыкларда киң таралган.*

*Татар халкының кара-каршы җырлана торган «Башмагым», «Җизнәкәй», «Былбылым» җырлары аеруча киң таралган.*

[1] Йенче – энҗе.

## Мәрәтнең җыры




Әйә чаныем, йыр йырлаем
Дәлил урамнарын пашлап.
Раслап мине сөйгән пулсаң,
Китмәгел ятларга ташлап.
Раслап мине сөйгән пулсаң,
Китмәгел ятларга ташлап.

Әй чаныем, син йөрисең,
Йөрүеңне күрәсе юк.
Миңа нигә үпкәләйсең,
Үзеңнеке ырысың[1] юк.
Миңа нигә үпкәләйсең,
Үзеңнеке ырысың юк.

Могарланган сәел төндә
Кыслар кия кара кертә.[2]
Асатыма[3] әйтер ием
Кайгырып йөрмәсен бер дә.
Асатыма әйтер ием
Кайгырып йөрмәсен бер дә.

[1] Ырыс – бәхет.
[2] Кертә – пальто(?)
[3] Асат – бердәнбер.

Сине күрсәм, кай түзә алмайым,
Сине өнәмәй түсә алмайым,
Сине өнәмәй түсә алмайым,
Шикәр чәйнәп йота алмайым.
Сине өнәмәй түсә алмайым,
Шикәр чәйнәп йота алмайым.

Башыңа лай япкан ак яулыгың
Яңа яуган кардин артык.
Сиба пуең, матур йөсең,
Буйдак йөргән кысдин артык.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Саургач авылында Ганиев Вәлиулладан (1908 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Мәрәт бер кызны яраткан. Аны ала алмагач, сөйгәненә багышлап шушы җырны чыгарган.*

*Җырның соңгы ике куплетын Разулев Шәфикъ өстәп җырлады.*

## Мәхмүт мәргән




Мәхмүт лә мәргәнне[1]сурасагыс –
Юлтамагай[2] киткән, вай, өйтә йук.
Кушырып/ы/ салган най куш өйләрем
Оцып барган кошның, әй, йулынта.

Наскы лай йылгамтай киртләч-киртләч,
Киртләчләре китәр, вай, бос киткәч.
Беснең лә авыл та, сәел[3] авыл,
Йәмнәре петәр, вай, мин киткәч.

*1971 елда Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында Таҗетдинова Җәмиләдән (1906 елгы) магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

---

[1] Мәргән – төз атучы, курку белмәс сунарчы, батыр.
[2] Йулымта – юлга чыгу, аугa китү, эзләп, юллап китү.
[3] Сәел – күркәм, матур.

## Туктасын качкын җыры




Йыраккай йиртә, гуй, мин йөрәймен, гуй, әйе-вай,
Ай, туган-үскән иллремәү хат ясып,
Ай, туган-үскән илләремәү хат ясып.

Йир йыраккайларындай мин йөреймен, гуй, әйе-вай,
Ай, туган-үскән илләремне ят итеп,
Ай, туган-үскән илләремне ят итеп.

Агыйделлләргәй төшкәнемтә, гуй, әйе-вай,
Уай, кайыкка ментем, гуй, ат йалан,
Уай, кайыкка ментем, гуй, ат йалан.

Шулып ла башта, вай, карлыгач, әйе-вай,
Уай, атыткай лау алтым, гуй, карным ач,
Уай, атыткай лау алтым, гуй, карным ач.

Ни ашасам да, уай, карным ач, ай-вай,
Уай, ятып калды, гуй, туганым Карбигәч,
Уай, ятып калды, гуй, туганым Карбигәч.

Кара урманнарга кергәнемдә, гуй, ай-вай,
Ай, сызгырты урманның кийеге,
Ай, сызгырты урманның кийеге.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Саургач авылында Шәфыйк Разулевтән (1913 елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

**Шәрук**




Шәрукның башынтай кринкәй бүрек,
Алмагачка кунган лай кош кебек.
Туган ла җирем, үскән җирем,
Йокыларда күргән төш кебек.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Хәбибуллин Кәримулла (1928 елгы, 40 яшь) баянда уйнап җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Җырның кайда, кайчан һәм кем тарафыннан чыгарылуы башкаручыга билгеле түгел. «Әхмәт солдат җыры» исеме белән А. Ключаревның «Татар халык көйләре» җыентыгында бирелгән. Анда көй ике музыкаль җөмләдән тора. Безнең язма исә аның беренче җөмләсе белән тәңгәл килә, җырның түбәндәге сүзләре бар:*

*Башыма ла кигән, әй, бүрегем,*
*Казыкларга кунган ла кош кебек;*
*Туган үскән илем, күргән көнем,*
*Йокыларда күргән төш кебек.*

*Бормалы ла борма-борма баскыч,*
*Менәбез лә бауларга тотынып;*
*Солдат башкайлары ниләр күрми,*
*Булыр микән тиздән котылып.*

*Жырның бер строфасы И. Надировның «Татар халык җырлары» китабына кертелгән «Шәрук беглый»да да бар:*

*Шәрукның башында камчат бүрек,*
*Алмагачка кунган кош кебек.*
*Самат илләрендә йөргән чагым*
*Төн йокымда күргән төш кебек.*

*Искәрмәләр өлешендә исә Шәрукның XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында яшәгәнлеге әйтелә. Ул элеккеге Самара губернасында туган икән. Армиягә алынгач кача. Аны тотып төрмәгә япсалар да, яңадан кача һәм качкын булып урманда яши. Ләкин аны тоталар һәм сөргенгә җибәрәләр.*

*Җырның Себергә килүенә ике сәбәп булуы мөмкин: я аны күчкән мишәрләр алып килгән, я булмаса Шәрук бу якларга сөрелгәч үзе җырлап тараткан.*

*«Шәрук» – мишәрләр арасында зур яңгыраш табып, бәеттән җырга күчкән! Әлегә аның Куйбышев һәм Ульяновск өлкәләрендә таралуы мәгълүм.*

## Бараба җиренә күчкәндә




Бийек кенәй кырның әй башында
Борлыгадыр[1] богдай орлыгы.
Карындаш тугандин әй айрылган,
Әй-хайы гынай дөньяның хурлыги.

Бараба ла җире әй мал җири,
Беснең Сембер җири – ут җири.
Ут җире дә булса китмәс идем,
Бар да бер Ходайның тәкъдире.

Утырдым чананың әй төбенәй,
Дилбегәй генәмне кулыма алып.
Өч мең чакрым җиргәй бән барамын
Әҗәл генәемне кулыма алып.

---

[1] Борлыгу – боегу.

Өч бубаска[1] йектем әй китәргә,
Барабай иленәй китәргә.
Туганнарым әйтми әй китәргәй,
Белмәймен үк нихәл итәргәй.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Сәлимҗанов Гыйльман җырлаган (1889 елгы, 79 яшь). Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Гыйльман бабайның әйтүенә караганда, бу – Себергә күчеп килгән мишәрләр җыры. Йәдүгәр исемле мулла Сембердән бөтен бер авылны Бараба далаларына алып киткән.*

[1] Бубаска – повозка, йөк.

## Солдат җырлары

### *Беренче җыр*




Солтатлай ятыр казарматау
Вай, тар шинелькәйләрен гуй ябынып,
Вай, тар шинелькәйләрен гуй ябынып.
Солдатлай мескен әй вай төш күрә,
Вай, тыуган-үсекән илләрен сагынып,
Вай, тыуган-үсекән илләрен сагынып.

Пез киткән уакыт неитәй гуй вакыт,
Вай, йерләр туңган ай агачының тамыры мән,
Йерләр гуй туңган гынай агачының тамыры мән.
Чыламай, әтием, чылама, әнием,
Вай, солтат пулуы әй Алланың әмере мән,
Вай, солтат пулуы әй Алланың әмере мән.

*1968 елның 4 июлендә Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Саургач авылында Разулев Шәфыйктан (1913 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

### *Икенче җыр*




Матур /да/ матур җөргән җир,
Җөргән җирдән матур туган ил. } 2 кат.
Туган илдә калды нечкә бил,
Нечкә билдән кочкан төннәрем. } 2 кат.

Арт/ы/ма салдым сары шинелем,
Кул/ы/ма мылтык алам, ук алам } 2 кат.
Кул/ы/ма мылтык алам, ук алам,
Сугышларга кереп югалам. } 2 кат.

*Төмән өлкәсе Ялутор районы Кактамак авылында Нурмөхәммәтов Әйтмөхәммәттән (1915 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган.*

*Көнбатыш Себердә бу көйнең төрле вариантлары таралган. «Кыз озату җыры», «Картлар җыры», «Иске җыр» кебек җырлар шушы көйгә башкарыла.*

*Гомумән, татар халкының әлеге борынгы көе хәзер дә яңгырый, ул китапларда басыла*[1]*, пластинкаларда саклана, радиодан яңгырый. Җыентыкларга да кергән.*

[1] *Ключарев А.* Татар халык көйләре. Казан, 1955; *Фаттах А.* Народная музыка Татарии. М.: Музыка, 1973. С. 3.

## *Өченче җыр*




Түбәтәйләреңне калдырып кит,
Читләренә ука мин тотармын.
Китәсең калдырып ялгызымны,
Хәсрәтләнеп ялкын уй йотармын.

Озата бара дускай, үзе җылый,
Бирдем кулгынамдин яулыгымны.
Хат язып тор, дускай, хат язып тор,
Исәнлегең белән саулыгыңны.

Сахраларга чыксам ялгыз үзем,
Һаваларда йолдыз, ай – юлдашым.
Һаваларда йолдыз, ай – юлдашым,
Мең дошманга каршы ялгыз башым.

*Төмән өлкәсе Ялутор районы Рауды авылында Курманов Галимнән (1895 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

**Безнең илләр**

*(Солдат җыры)*




Без/е/нең е/ илләр/е/ кайда диеп/е/,
Кыр/ы/ казындин/е/ сорадым/ы/ /най/,
Кыр/ы/ каз/ы/лары/й/ кайгылдашкач,
Бер утырып/ы/ йыладым.
Кыр/ы/ каз/ы/лары/й/ кайгылдашкач,
Бер утырып/ы/ йыладым.

Безнең илләр кайси җакта,
Алмас та/й/ идем күземне/ләй/,
Очып барган кош артындин
Әйтер идем сүземне.
Очып барган кош артындин
Әйтер идем сүземне.

*Томск өлкәсе Томск районы Яүштә авылында Мәүлекиев Габдулладан (1890 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## *Бишенче җыр*




Чуйын чүлмәк, аузи тар ла,  
Пешәр салдат ашлари ла;  
Кош-корт очып җитмәс җиргә,  
Китә салдат башлары ла.

Таш казарма буйларына  
Мылтыгымны сөйәдем;  
Туган-үскән илләремә  
Кайчан кайтыр сөйәгем?

Салдат итеп алдылар,  
Билемә каеш салдылар;  
Минем белән барган дуслар  
Җараусызга калдылар.

*1970 елда Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сабитова Сәрби (1895 елгы, 75 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Борынгы солдат җыры. Бәеткә тартым. Сәрби апа яшь чагында күршеләре олы яшьтәге бер бабай җырлаганча көйләп күрсәтте. Бу авылда Казан ягыннан килгән татарлар күп.*

## Герман сугышы




Карлыгач кара, муены ала/й/,
Һаваларга китеп югала/й/.

Бәхетле бала өйдә кала/й/,
Бәхетсезләр китеп югала/й/,
Бәхетсезләр китеп югала/й/.

Тәрәзә/й/ ачып уклар аттым,
Былбыл дигән кошны кузгаттым,
Былбыл дигән кошны кузгаттым.

Капкалар ачып юл күрсәттем,
Күз күрмәслек җиргә/й/ озаттым,
Күз күрмәслек җиргә/й/ озаттым.

Сари атлар җиктем мин китәргә,
Өйгә кердем киңәш итәргә/й/,
Өйгә кердем киңәш итәргә/й/.

Ал китабың, ди, тот мәслихәт,
Китап кушкан сабыр итәргә/й/,
Китап кушкан сабыр итәргә/й/.

Сандугач кайда – ай заяда,
Аның балалары ояда/й/,
Аның балалары ояда/й/.

Сандугач кебек сайрый-сайрый,
Күрешербез микән дөньяда,
Күрешербез микән дөньяда.

*Томск өлкәсе Томск районы районы Кызылкаш авылында Сафиуллина Рәхиләдән (1900 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Шушы ук авылның Мәрфуга Әбсәлимовадан (1910) һәм Гайшә Казакова (1909 елгы) көйгә түбәндәге куплетларын өстәп җырлаган:*

*Җегереп /тә/ бара /ай/ ир бала*
*Ачык капкаларын ябарга.*
*Ачык капкаларны кемнәр япмас,*
*Безнең ялгыз башны кем какмас.*

*Селәүченнәр*[1] *оча тауаска,*
*Тау астагы сары камышка.*
*Камыштай кебек буй үстереп*
*Калдык инде кайгы-сагышка.*

[1] Селәүчен – бал корты.

## Тоткыннар җыры




Иртән торсам ишекләр бикле, } 2 кат
Ай, тәрәсәләре тимерле.} 2 кат

Тәрәс аша карый-карый} 2 кат
Ай, ике күсләрем тилмерти. } 2 кат

Иртән торсам ишекләр бикле, } 2 кат
Ай, аяк-куллар тимер чипле. } 2 кат

Тимер чипләр өсеп пулмай,
Ай, тәгать итеп түсепләр пулмай. } 2 кат

Эчәр-эчмәс утырганча,
Ай, эчсәң төпләрен күренгәнчә.

Эчсәң төпләрен күренгәнчә,
Ай, дус пуларбыз бес үлгәнчә.

Читле лампа якты яна,
Ай, җите төн уртасындалай.

Йите уянып, йите йылыйм,
Ай, йите төн уртасында.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абитов Биктимердән (1918 елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Испанчылар




Еллар авыр килде испанчыларга,
Ком бураннары аша ничек чыгарга?

*Кушымта:*

Ташкын таулар аша,
Еллар аша ерак илләргә.
Чит илләрне кичеп,
Дошманнарны изеп
Без кайтырбыз туган илләргә.

Үтәме бу еллар? Үтәме – үтә!
Агамы бу сулар? Агамы – ага!

*Кушымта.*

Үтәме бу көннәр? Үтәме – үтә!
Исәме бу җилләр? Исәме – исә!

*Кушымта.*

Ерак авыр килмәс испанчыларга!
Күкерәк киереп баралар алга.

*Кушымта.*

*Түбән өлкәсе Ялутор районы Пумаер авылында Рәхимова Фәридәдән (1918 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Испанчылар*

*Фәридә апа бу җырны 1936–1937 елларда шушы районның Кулик[1] авылында ШКМ[2]да укыган вакытта Гайшә Латыйповадан отып алган. Җыр беренче тапкыр 1936 елда үткәрелгән сайлаулар вакытында башкарылган.*

*Героик испан халкы белән берлектә азатлык өчен көрәшүче интернациаль бригада членнары турындагы бу җырның дөньяга килүе халык иҗатының көн кадагына суга торган вакыйгалар вакытында җыр иҗат итү традициясенә бер мисал булып тора.*

*Андый үрнәкләр еш кына иске җыр-көйләргә нигезләнеп языла. Мәсәлән, «Көзге ачы җилләрдә» җырының сүзләре Беренче Бөтендөнья сугышы елларында чыккан «Окоп көе» белән туры килә. «Испанчылар» җырының сүзләре дә «Япончылар җыры»ныкы белән туры килә.*

[1] Бу авылда, нигездә, Казан ягыннан күчеп килүчеләр яши.

[2] ШКМ – Школа Красной молодежи.

## Бандит көе




Бан(ы)дит(ы) көе, бан(ы)дит көе,
Бандит(ы) көйләрен йаратам;
Бандит(ы) көйләренә йырлап,
Бары хәсерәтем таратам.

Утырысам уйылый башлыйм ла,
Уйласам йырлый башлыйм;
Күп уйыланып йырламасам,
Дивана була башлыйм.

Уйыга калам, уйыга батам,
Кулымда кош уйынатам;
Күп уйыланып бере йырыласам,
Күңелләрне йуатам.

*1969 елда Томск өлкәсе Томск районы Кызылкаш авылында Аблин Хаҗиәмәт (1904 елгы, 65 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Җырның көе мәшһүр «Идел» – «Су буйлап»ны хәтерләтә. «Алсу» җырының көе интонацияләренә дә бик якын. Хаҗиәхмәт абыйның әйтүенә караганда, «Бандит көе» бу якларда күптәннән җырлана. Һәрхәлдә, «Идел» көеннән иртәрәк. Җырның сүзләрен беренче булып язып алучы М. Мәһдиев болай яза: «Турысын гына әйткәндә, бу көйнең исемен ишеткәч, бераз каушап калдым. Ничек инде ул – бандит көе? Бәхеткә каршы, җырның сүзләрендә куркынычлы андый берни дә очрамады. Ә менә көенә килсәң, гаҗәп. Бу көй аһәңгә шулкадәр бай, шулкадәр тирән моң – монда иксез-чиксез тайганың шаулавына Себернең киң сулы елгаларының салмак агымы кушыла. Бу җырны тыңлаганда, ирексездән, богауларын чыңлатып тайга юлларыннан сөргенгә куылган бабайларның аһ-зарын, йөрәк сыкрануын ишетәсең. Ләкин халык җыры буларак ул тирән оптимизм белән сугарылган һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, бу җырны мин тантаналы-драматик җыр дип атар идем[1].*

[1] *Мәһдиев М.* Себер татарлары иҗаты // Казан утлары. 1968. № 10.

## Баламишкин




Баламишкинның пуентай
Акы палыклары уйынта, ай;
Ак палыктай матур йарлар
Йата йегет куйыныта.

Аксак-туксак йегеп цыксак,
Пестә тә пар туратлар.
Әвәлге йерегәннәрен
Ник оныткан пу картлар?

Алларән кайта минең ти,
Көлләрем кайта минең;
Уналты йәшемтә сөйгән
Йар гынам кайти минем?

*1971 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Лаймтамак авылында Таҗетдинова Җәмилә (1906 елгы, 65 яшь) җырлаган.*

*Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров..*

*Гомумтатар көенең үзенчәлекле бер варианты. Туй-мәҗлесләрдә кунакларны сыйлаганда җырланган.*

*Җәмилә мамай – җыр капчыгы. Ул шулкадәр ихласланып, бөтен көченә кычкырып җырларга күнеккән. Лаймтамаклылар урамда, ачык тәрәзә аша, кул чабып алкышлап тора.*

## Сак-Сок бәете

Мәдрәсәләрдә
Китап киштәсе,
Сак берлән Сокның
Тавышын ишетәсе.

Мәдрәсәләрдә
Пыяла ишек,
Сак берлән Сокның
Тавышын ишет.

Әткәй орышты
Тимер ук өчен,
Әткәй орышты
Бигрәк юк өчен.

Җимнәр ташыйдыр
Кошлар басудан.
Әнкәй каргады
Безне ачудан.

Самавыр куйды,
Чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч
Каргап очырды.

Әнкәй каргады
Рамазан аенда,
Сак-Сок булдык без
Кадер кичендә.

Утырып уйнадык,
Уйнап егъладык.
Әнкәй каргагач,
Сәгать тормадык.

Ишек алдында
Җиктем кара ат.
Әнкәй каргагач,
Яралды канат.

Агачка кунгач,
Язылды канат.
Икәүләп бергә
Очтык шул сәгать.

Уң якта канат,
Сул якта канат.
Очып киткәндә
Калдылар карап.

Киртәдән очтык,
Кундык агачка.
Ниләр килмәде
Безнең бу башка.

Алты яшькәчә
Уйнап йөрдек без.
Җиде яшьләрдә
Сак-Сок булдык без.

Комач күлмәгем
Бер дә кимәдем.
Очып киткәндә
«Сау бул!» димәдем.

Без киттек, әнкәй,
Бәхил булыгыз.
Намаз артыннан
Дога кылыгыз.

Яңа тунымны
Ботак ерткандыр,
Гомерем беткәнгә
Нәфесем тарткандыр.

Әткәй калдырды,
Өйдә торсын, дип.
Әнкәй каргады,
Сак-Сок булсын, дип.

Каргады безне
Газиз әнкәбез.
Якты дөньяны
Күрми калабыз.

Кыйбла ягыннан
Җилләр исәдер.
Безнең ризыкны
Әнкәй кисәдер.

Су буйларында
Диңгез камышы,
Дөм урманында
Сак-Сок тавышы.

Урман эчендә
Кошлар сайрыйдыр.
Шулар янында
Сак-Сок егълыйдыр.

Әнкәй каргагач,
Урманга баргач,
Йөрәгем ярылды
Зур имән аугач.

Каргап җибәрде,
Эшне бетерде,
Безләр кош булгач,
Үзе үкенде.

Урман ичләре,
Каен башлары,
Газиз әнкәйнең
Түгелә яшьләре.

Урман эчендә
Аю үкерә.
«Ник каргадым?» дип
Әнкәй үкенә.

Ишек алдында
Кошлар сайрыйдыр.
«Балам кайда?» дип
Әткәй сорыйдыр.

Безне сорагач,
Әнкәй каушады,
«Каргадым» дигәч,
Әткәй егълады.

«Балам, Балам» дип
Әнкәй егълыйдыр.
«Ник каргадың?» дип,
Әткәй тиргидер.

Әнкәй каргады,
Әткәй белдеңме?
Түреңнән уздык,
Әткәй, күрдеңме?

Йокыга киткәч,
Бер төш күрдем мин.
Япан кырларда
Ялгыз йөрдем мин.

Бардык урманга,
Җыйдык карлыган.
Без ятимнәрне
Әнкәй каргаган.

Төшкәндер безгә
Әнкәй каргышы.
Үзебез туганчы
Тәкъдир язмышы.

Әнкәй каргагач,
Сак-Сок булдык без.
Бу дөньялардан
Гыйбрәт алдык без.

Су буйларында
Бик күп йөрдек без.
Сак-Сок булгачдин,
Дөнья гиздек без.

Чыктык басуга
Урак урырга.
Ходай язгандыр
Шулай булырга.

Кистем пар нарат
Яңа өйләргә.
Ике күземнән
Канлы яшь ага.

Су буйларында
Бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә
Өзелә үзәкләр.

Аклы күлмәкне
Туя кимәдем.
Газиз әнкәмне
Туя күрмәдем.

Бер ел тулганчы,
Кайтам дип йөрдем.
Бер ел тулгачдин,
Өметне өздем.

Урныбыз – урман,
Икебез – туган.
Каушу юк безгә –
Әнкәй каргаган.

Кичләр дә була,
Иртә дә була.
Сак берлән Сок
Кауша алмый кала.

Өйгән кибәнне
Җилләр тарата.
Каушабыз дигәч,
Хәзер таң ата.

Кояш чыкканда
Кан тула күзгә.
Кыямәт көнсез
Каушу юк безгә.

Бардым урманга,
Кистем пар каен,
Газиз әнкәмне
Сагынам көн саен.

Мамык эшләпә
Алып кайтыгыз.
Әнкәйне күргәч,
Сәлам әйтегез.

Ягъмур явадыр,
Әнкәй, башыма,
Егълап килдек без,
Әнкәй, каршыңа.

Әнкәй егълыйдыр,
«Ник каргадым» дип.
Сак-Сок йөридер
«Хәрап булдык» дип.

Бардык урманга,
Җиләкләр пешкәч.
Әнкәй егълыйдыр,
Исенә төшкәч.

Кара карлыгач,
Сары сандугач,
Әнкәй егълама
Үзең каргагач.

Калган киемне
Алып куярсың.
Исеңә төшкәч
Алып иснәрсең.

Имезгән сөткә
Әнкәй, өрсәнә.
Кыямәт көнендә
Бәхил булсана.

Газиз әнкәем,
Бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң,
Өйгә кайтаем.

Мамык эшләпәм
Җилгә очырдым.
Ике баламны
Каргап очырдым.

Мендем ботакка,
Карадым як-якка.
Ике баламны
Каргадым юкка.

Җәйгән җәймәмнең
Калды яртысы.
Ике баламның
Калмады берсе.

Моңлы моңлансын
Сары саргайсын.
Балаң очырдың,
Кемгә егъларсың.

*2014 елда Омск өлкәсе Тәвриз районы Әшевән авылында Хәмидуллина Шәмсия Касим кызыннан (1925 елгы) И. Закирова язып алган. Информант үзе язган дәфтәрдән карап сөйләгән.*

## Сак-Сук

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сукның бәетен иштәсе.
Мәдрәсәләрдә пияла ишек,
Сак белән Сукның бәетен ишет.
Әнкәй каргады тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бигрәк юк өчен.
Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.
Самавыр куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.
Яңа тунымны ботак ерткандыр,
Гомерем беткәнгә, җаным тарткандыр.
Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип.
Әнкәй каргады Сак-Сук булсын дип.
Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әнкәй кисәдер.
Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.
Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.
Әнкәй каргагач, Сак-Сук булдык без,
Бу дөньяларга гыйбрәт булдык без.
Су буйларында бик күп йөрдек без,
Сак-Сук булгачтын, дөнья гиздек без.
Кистем пар нарат яңа ызбага,
Ике күземнән канлы яшь ага.
Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә, өзелә үзәкләр.
Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз әнкәмне туя күрмәдем.
Бер ел тулганчы, кайтам дип йөрдем,
Бер ел тулгачтын, өметне өздем.

Урныбыз – урман, икебез туган.
Кавышу юк безгә, әнкәй караган.
Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышыбыз дигәч, хәзер таң ата.
Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәмне сагынам көн саен.
Мамык эшләпәм алып кайтыгыз,
Әнкәмне күргәч, сәлам әйтегез.
Мамык эшләпәм җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.
Җәйгән җәймәмнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.
Моңлы моңлансын, зарлы саргайсын,
Балаң очырдың, кемгә еларсың?
Идел буенда диңгез камышы
Кара урманда Сак-Сук тавышы.
Яңгыр явадыр әнкәй башыма,
Егълап килдек без әнкәй каршыңа.
Әнкәй елыйдыр, ник каргадым дип,
Сак-Сук йөридер, харап булдык дип.
Бардык урманга, җиләкләр пешкәч,
Әнкәй елыйдыр, исенә төшкәч.
Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй елама, үзең каргагач.
Болай булдык без, әнкәй каргышы,
Елама, әткәй, Ходай язмышы.
Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, алып иснәрсең.
Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар очканда карап калырсың.
Имезгән сөткә әнкәй рәнҗемә,

Кыямәт көнсез күрешү юк безгә.
Газиз әнкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өйгә кайтаем.
Сары күлмәгем һәч тә кимәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.
Якты дөньяны күрми калабыз,
Каргады безне газиз анабыз.
Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Кара урманда очып йөрдек без.
Су буйларында балалы үрдәк,
Искә төшкәндә өзелә үзәк.
Алты яшькәчә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сук идек без.
Әнкәй токмачны үзең күп кистең,
Әткәй кайтканчы безне юк иттең.
Әткәбез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.
Әнкәй кер юдың Идел буенда,
Сак-Сук булыр дип юктыр уеңда.
Бардым урманга, бастым баланга,
Балам елыйдыр кара урманда.
Алдагы көнне икәү уйнадык,
Әнкәй каргар дип без уйламадык.
Әнкәй каргады, әткәй белдеңме,
Турыңнан уздык, әткәй күрдеңме?
Ишегалдымда имән дугасы.
Әткәй, елама, әнкәй догасы.

*2017 елда Новосибирск өлкәсе Колыван районы Акбалык авылында Ризванова Нәсыйхә Әбүбәкер кызыннан (1934 елгы, Батуринда туган, алты яшендә Акбалыкка күчкәннәр) һәм Хәсәнова Мәйсәрвәр Әбүбәкер кызыннан (1946 елгы) И. Закирова язып алган.*

## Сак-Сок бәете




Әнекәй каргагач,
Сак/о/-Сок/о/ булдык/ы/ без.
Бу дөньялар/ы/да
Гыйб/е/рәт алдык без.

Бардык урманга
Җиләкләр пешкәч,
Әнкәй җылыйдыр,
Исенә төшкәч.

Кара бүрекемни
Алып кайтыңыз,
Әнкәйни күргәч
Сәлам әйтегез.

Комач күлмәгем
Һич тә кимәдем,
Чыгып киткәндә
Сау бул димәдем.

Кистем пар нарат
Яңи өйләргә,
Әнкәй каргагач,
Яралды канат.

*Омск өлкәсе Муромцево районы Юртбиргамак авылында Таишмова Мөслимәдән (1911елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Сак-Сок




Карга карылдый, урман шауылдый,
Чыгып китәргә сәбәп табылдый.

*Омск өлкәсе Муромцево районы Юртбиргамак авылында Искәндәрова Хупҗамалдан (1905 елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Себер татарлары «Сак-Сок» бәетен, нигездә, шушы көйгә әйтәләр. Ул, күптөрле вариантларда гаять зур территориядә яшәүче татарларга күптәннән таныш.*

## Көйдем бәете




Ике лә өйем /гой/ урталарында /гой/ /и/,
Чаналар үтәде /гой/ турылык/ы/ белән.
Җан сөйгән ярым ман /гой/ кушылмаен /гой/ /и/,
Гомерем үтте /гой/ сар/ы/лык белән.

Сауыскан /лай/ кош иде /гой/,
Кош кундырма/й/ /ла/ тирәгенә.
Ашыйк хәлләре /ләй/ бик авыр хәл,
Аш кундырмайты /гой/ йөрәгемә.

*Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Вахитова Сафурадан магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Көйтем йантым бәете




Көйтем лә йантым,
Йар биеккәйләрен йанга салтым,
Йар биеккәйләрен йанга салтым.

Карасаң ла, күсләрем камаша,
Карап торуларың ай күк пескә.
Син азаткайымны мин тигәймен,
Бер үсең арткаулар кыска.

Аякларга кигән кара тиңгә
Буйларыңа килешәдер синең.
Азаткайым булай инде, йиңгә,
Балдызкаең аңа тимлә.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибендe авылында Абитов Биктимер (1918 елгы, 50 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Рус-япон сугышы бәете




Тугыз йөздә, дүртенчедә
Сугышларга башладык.
Сугышка дип хәбәр алгач,
Вольный кием ташладык.

Бу бәетне язамын,
Искә алсын туганнар.
Хәзерендәй безләрне
Сугышырга куалар.

Бу бәетне язабыз,
Ничә солдат җыелып.
Көне-төне җылаганга,
Бетте яшем коелып.

Укучы, дим, үтенәмен,
Гаеп кылма карарга.

Чибәррәк тә язар идем,
Табып булмый язарга.

Ачы суык җилләр исә,
Өскә/й/ карлар сылаша.
Машинага/й/ утырганда
Туганнарым җылаша.

Караңгы төн, ачы буран,
Ачып та булмый күзләрне.
Колакларым ишетмидер
Сау бул дигән сүзләрне.

Бүзгат сырнай уйнаганда
Күңелем тулып йыладым.
Аерылып киткән чакта
Бик моңаеп җырладым.

Камышлыкны/й/ чыккан чакта
Аяк асты баткылык.
Йөзе кара японецлар
Калды безгә аткалап.

Сары диңгезнең өстендә
Дулкын булды давылга.
Яйсез булган чыгарга,
Барып төштек авылга.

Ранинуслар[1] килә иде
Ходаем юлны бирер дип.
Кем уйлаган бу эшләрне
Безнең башка килер дип.

*Томск өлкәсе Томск районы Яуштә авылында Мәулекиев Габдулладан (1890 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

---

[1] Ранинус – броненосец.

## Гыйбадулла бәете




Гыйбадулла иртән торып тәһарәт ала,
Тулган айны ярты күребе хәйран кала.
Әнекәсе хәер бирәм, улым, диде.
Хәер бирер көннәр түгел, әнием, диде,
Ике балам ятим булып кала, диде.

Гыйбадулла урак урып ятар иде,
Урагы ятып калды курасынта.
Шуны әйтеп Гыйбадулла күп егълады
Ыстанавай приставның курасында.

Атарында сыер ята бозау белән,
Кызлар чәчен үстерәләр сыйрау белән.
Әнекәсе карт кияүгә бирәм, дисә,
Күс майларын сысдыралар йылау белән.

*Бәетнең көе 1970 елда Төмән өлкәсе Ялутор районы Исәт авылында Яхина Җомабикә (1903 елгы) һәм Шәнгәрәев Әхмәт (1903 елгы) башкаруында И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров. Сүзләре Ялутор районы Аслана авылында Бакиев Ганидән (1912 елгы) язып алынган.*

*Бу якларда бик киң таралган һәм яратылып башкарыла торган бәет. Халыкта йөргән сүзләргә караганда, Гыйбадулла ниндидер зур түрәне үтергән. Аны алып киткәч, әнисе бәет чыгарган.*

*Бәет шушы ук районның Аслана авылында Бакиев Ганидән (1912 елгы) дә язып алынды. Ул аны «Ибәдулла бәете» дип җырлый. Гани Бакиев бәеттә Шадрин районының Өчкен, Тәрсүк авылларында булган вакыйга турында сүз баруын әйтә.*

*Бәетнең «Габидулла бәете» дигән бер варианты Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультеты студентлары тарафыннан Курган өлкәсендә язып алынган. Бу бәеттә мондый строфалар бар:*

*Ат аранда, сыер ята бозау белән,*
*Әнекәсе чәчен тарый майлау белән.*
*Габидулла чыгып китте олау белән,*
*Әнкәсе күз бетерде егълау белән.*

*Үрдәк әйтә, казлар әйтә, очам, диеп,*
*Казанның киң җиренә төшәм, диеп.*
*Мул казанның киң җирләре тардыр безгә,*
*Бер Ходаның боерыгы бардыр безгә.*

*М. Мәһдиев тарафыннан КДУ студентларының Курган өлкәсендә узган фольклор экспедициясе нәтиҗәләрен яктыртып язылган «Курган татарларының авыз иҗаты» дигән мәкаләдә бу*

*бәет турында түбәндәге мәгълүмат бирелә: «тарихи озын җырлар арасында качкыннар турында, патша властеның җәберенә эләгүчеләр һәм 1812 елгы сугышта катнашкан егетләр турындагылары очрый. Патша түрәләре эзәрлекләвеннән качып, Урал аръягына килеп чыккан Казан егетләре турындагы җырлар да бар. Шундыйлардан безгә бик ошаганы һәм бөтен Шадрин һәм Шатров районнарында популяр булганы – «Габидулла бәете». Габидулла бәетенең язмышы бик кызыклы. Бу бәетнең кайбер строфаларын соңгы вакытта Пугачев восстаниесенә кагылышлы архив документлары арасыннан да таптылар. Безнен уебызча, Габидулла Казан ягы егете булып, Пугачев восстаниесендә катнашкан һәм ахырдан патша хөкүмәте тарафыннан сөргенгә җибәрелгән булырга тиеш. Бәетнең эчтәлеге, һәрхәлдә, шуңа ишарә ясый. Аңнан сон, барлык җырлар арасында да Курган ягы татарлары бу җырны аеруча яраталар һәм картлар арасында моны белмәгән кеше юк диярлек»*[1].

[1] Курган татарлары авыз иҗаты // Казан утлары. 1967. № 9. Б. 138.

## Бәет




Арынкының сиратындай
Төнәмәгән кошы юк.
Канбикәне, Кәшифәне
Сөйләмәгән кеше юк.

*1970 елда Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Киндерле авылында Асадуллина Фатыймадан (1907 елгы) И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров*

## Бәет




Аклы ситса күлмәгем,
Күтәрмәйтер беләгем.
Партыр мәнем күрәчәгем,
Алгасайтыр[1] йөрәгем.

Әткәм салган куш өйләр
Отчар кошның йулынта.
Әткәм исән булган булса,
Йөрмәс идек йат илтә.

Йалан йертә ялыгыс тирәк,
Оясы бар, кошы йук.
Йырак йертә сарыхау булсаң,
Хәлең сорар кеше йук.

---

[1] Алгасайтыру – сизенү, сагаю.

Иртә торсаң, иртәләр
Коръән салып кертәләр.
Үс туганнарың пулмагансын
Кемгә генә иркәләр.

*1971 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Лайтамак авылында Кучумова Һава җырлаган (1894 елгы). Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Бәет




Сара апа иртән торгачтын да
Килеп күреп китте кыз чагын:
Кай җирләрдә әрәм булып ята микән
Ялтыратып муен мунчагым?

Бәгырькәем, сине эзләп йөрим,
Күтәреп карачы муйныңны.
Ничек җәлләмичә әрәм иттең
Бу хәдәрле зифа буеңны.

Печәннәргә алып китте,
Печәннәрне җыярга.
Төн буена уйлап йөргән
Минем башны җуйарга.

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Тимганова Талигадан (1900 елгы) И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Суга баткан Гайшә бәете

Чәршәмбе көн кер юарга
Ник җибәрдең, әнкәем,
Барма, кызым, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем.

Кулымдагы көмеш йөзек
Көнгә каршы эридер.
Тал чыбыктай зифа буем
Су төбендә черидер.

Өстемдәге камзулымны
Элеп куйдым казыкка.
Зифа буем үскән икән
Балыкларга азыкка.

Баткан чакта итәкләрем
Батадыр да, калкадыр.
Муендагы тәңкәләрем
Су төбенә тартадыр.

Чәршәмбе көн мунча яктым
Битем-күзем юарга.
Чәршәмбе көн кер чайкадым
Газиз башым җуярга.

Аучы мылтык атадыр,
Төтене кире кайтадыр,
Матур Гайшә баткан дигәч,
Туе елап кайтадыр.

Приказчик егет килгән
Баткан җирне күзлидер,
Һич курыкмаенча суга кереп
Чумып-чумып эзлидер.

Батыр егет чума торгач,
Арып калды хәленнән,
Җан сөygәнен эзли-эзли
Аерылды җаныннан.

Зирәк егет Гайшә кызны
Алыр өчен мал биргән.
Үлсә дә күреп калыйм дип,
Су эчендә җан биргән.

Үкенче үлем булды,
Буйга үсеп җиткәндә.
Икесе дә суда вафат,
Туй була дип көткәндә.

Иртә торып мунча яктым
Битем-башым юарга,
Басма өстендә кер чайкадым
Газиз башым җуярга.

Камил гашыйк булган егет
Җәлләмәгән малын да.
Биргән вәгъдәсе өчен
Кызганмаган җанын да.

*Текст «Халык иҗаты» (Казан, 1938) җыентыгыннан алынды.*

## Гайшә бәете


♩ ≈ 76
Гәй - шә мес - кен су - га бат - кан, буш кал - ган - дыр ө - йе - гез,
Тыу - ган сең - лем Хә - бәй - бә - не Гай - шә ке - бек сө - йе - гез.
Ти - шәм - бе көн кер йу - ма, дип әйт - кән и - де ән - кә - ем;
Ә - чәл тар - тып, тәкъ - дир я - зып бән а - шык - тым, ән - кә - ем.
Ку - лым - да - гы кө - меш йө - зек ко - яш - ка куй - сам э - ри - дер,
Тал чы - бык - тай зи - фа бу - ем сыу тө - бен - тә че - ри - дер.
Тал чы - бык - тай зи - фа бу - ем сыу тө - бен - тә че - ри - дер.
Би - лем - дә - ге кам - зу - лы - мны чи - шеп эл - дем ка - зык - ка.
Ак - лы сит - са күл - мәк - лә - рем ба - та - дыр да кал - ка - дыр.
Зи - фа бу - ем ус - кән и - гән ба - лык - лар - га а - сык - ка.
Муй - ным - да - гы йет - меш тәң - кәм су тө - бе - нә тар - та - дыр.

Гайшә мескен сыуга баткан,
Буш калгандыр өйегез.
Тыуган сеңлем Хөбәйдәне
Гайшә кебек сөйегез.

Тишәмбе көн кер йума, дип
Әйткән иде әнкәем;
Әҗәл тартып, тәкъдир язып
Бән ашыктым, әнкәем.

Кулымдагы көмеш йөзек
Кояшка куйсам эридер.
Тал чыбыктай зифа буем
Сыу төбентә черидер.

Чан алганта, чан биргәндә
Су төпләре тар булты.
Кәбен сырып салыр өчен
Әткәм-әнкәм сар пулты.

Пилемдәге камзулымны
Чишеп элдем казыкка.
Зифа буем үскән игән
Палыкларга асыкка.

Аклы ситса күлмәкләрем
Батадыр да калкадыр.
Муйнымдагы йитмеш тәңкәм
Су төбенә тартадыр.

*1969 елда Омск өлкәсе Большеречье районы Үләнкүл авылында Рәшитова Рәбига (1903 елгы) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Мөхәррәм мулла бәете




Ходаем язса тәкъдирдә,
Һәр эшләрне кадердә
Накил булсын мөфтә бәндә
Күрер башы шәфалардан.

Ходай язган килер микән,
Нәмиктары олыр микән,
Нәхак бәндә күрәр икән
Дәхи бәла-казалардан.

Кеше хәлен кеше белмәй,
Янар бәгърем бәнем сүнмәй,
Мәгәр гамли кеше үлмәс,
Ирешмәсә әҗәлләри.

*Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылында Нургалиева Вәйдәдән (1899 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Борынгы бәет




Йокы басти, ике күсем кысылди,
Ягамдагы якут мәрчән өселдей.

*1972 елда Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яркүл авылында Байнова Зөһрәдән (1900 елгы) магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

**Әбделмән купец бәете**




Бай Әптелман куписнең азбарында сарайлар.
Сарайларга эленгән тарайлар.
Бай Әптелман куписне
Судит итәлмадылар
Сембер губернасының боярлар.

Әптелман бай куписнең
Ишек алды сарайлар.
Сарайларгай эленгән тарайлар.
Әптелман бай куписнең
Аяклары димен лә
Баструк тирәзәсендин карайлар.

Дим елгаларының буйларында димен лә
Унике иде минем тирмәнем.
Кешеләргә дә генәй ай бирмәдем димен лә,
Үзем(е) дә игелеген күрмәдем.

* * *

Әбделмән купичнең илле бер ялчысы баралар главныйга урманга.
Бу ла бәлаләрдән Ходай коткарса иде, мең куй суяр идем корбанга.

Әбделмән купичнең икедер хатыны, кигән киемнәре лә шау ука.
Судьялар илтәләр хөкем залларына, һичбер адәм чыкмайдыр
порукка.

Ай да бу сарайлар, вай да бу сарайлар, эчләренә тулырлар варайлар[1]
Ислам динен хурлап утыралар Сембер өязендәге боярлар.

Ишегем алдына таш түшәлгән иде, судьялар йөри-йөри баз булды.
Унике генә пот кәгазь акчам иде, башымны йоларга ла аз булды.

Гыйгыл да гына гыйгыл, ниләр гыйгылдый Әбделмән купичның
ук казлары.
Сембер өязендә елашып йөриләр Әбделмән купичның ук кызлары.

Алтын суга торган алтын өстәлемне, сал, әнкәй кабәм, ук грязьгә.
Конюшняда үскән кара айгырымны бир, әнкәй кабәм, ук князьгә.

Унике лә ташлы тегермәнем, акчам кая киткәнен белмәдем.

*1969 елда Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылында Шулаяков Гафурдан (1885 елгы) һәм Шулаяков Сөнгатулладан (1900 елгы) магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Әптелман купис*

*1969 елның матур сентябрь аенда Кемерово өлкәсенең Юрга районы, Кышлау авылында фәнни экспедициядә булдым. Үзенә күрә шактый бай музыкаль мирас саклана икән бу авылда. Бигрәк тә туй йоласы белән бәйләнешле алар: «Кыз озату», «Ишек бавы», «И, былбылым» һ.б. Бик гыйбрәтле тарихи «Җир бәете»*

[1] Варай – шаһит.

*дә табылды. Таһир Якупов башкаруында радиодан яңгыраган «Тау башында таш тегермән»дә – шушы авылның сөеп-яратылып башкарылган җыры. Сораштыра торгач, бертуган Гафур һәм Сөнгатулла Шулаяковлар «Әптелмән купис» җырын магнитофонга яздырдылар. Имеш, Әптелмән атлы купис Сембер якларыннан сөргенгә монда җибәрелгән. Үзе белән җыры да килгән.*

*Минем музыкаль фольклор җыюга кереп киткән генә вакыт, тәҗрибә бөтенләй юк, һәр җырның тарихын тәфтишләп сорап бетереп булмый, себер татарлары теле бөтенләй аңлашылмый, шуңа күрә бар игътибар музыка-көйгә юнәлтелгән. Ә «Әптелмән купис» җыры турында мин әле берни белмим, чөнки моңа кадәр басылган нота җыентыкларында ул күренмәде.*

*Һәм, ниһаять, «Әптелмән купис» М. Нигъмәтҗановның 1970 елда Мәскәүдә «Советский композитор» нәшриятында дөнья күргән саллы җыентыгында урын ала. Баксаң, ул мишәрләрнең иң яратып башкарыла торган җырларыннан икән! Аңлатмада болай диелгән: «Широко распространенный среди мишар байт-песня. Очень интересный в поэтическом отношении текст рассказывает о купце, сосланном в Сибирь»*[1].

*Ә җырны көе белән магнитофон тасмасына аксакал фольклорчыбыз Хәмит ага Ярми Мордовиянең Кадошкин районы Иса авылында тирә-якта дан тоткан җырчы һәм музыкант Абдулла Кротовтан (1919–2005) язып алган. Галим үзенең «Татар халкының поэтик иҗаты» китабында болай яза: «Татар-мишәрләрдә һәрбер бәет үз көе белән яттан әйтелә. Кайбер бәетләрне сюжетлы җырлардан, җырны бәеттән аеруы да кыен. Мәсәлән, Пенза өлкәсе мишәрләре арасында бик нык таралган һәм эчтәлеге, формасы белән бәет дип саналырга тиеш булган "Әптелмән купис"ның сюжетлы җырларга якын тору мәсьәләсе килеп баса, һәм бу мәсьәлә аерым рәвештә тикшерүне таләп итә»*[2].

*Җыр көе белән икенче мәртәбә 2007 елда Казанда басылган «Иса авылы җырлары» җыентыгында чыга. «Бу халык җәүһәр-*

---

[1] *Нигмедзянов М.* Татарские народные песни. М.: Сов. композитор, 1970.

[2] *Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967. Б. 115.

*ләрен саклауда, таратуда һәм баетуда югарыда әйтелгән Абдулла Кротовның роле искиткеч зур» диелә кереш сүздә. Китапчыкка кергән 20 җыр яшьрәк буын вәкиле – Иса авылында туып, бүген Казанда яшәүче Мөхәммәткәрим Дәүләтказин башкаруында язып алынган. Безне кызыксындырган «Әптелмән купис»ның көе бераз лирик җырга якынайган. Бу гаҗәп түгел. Әлеге сыйфатны М. Нигъмәтҗанов та искәртә: «Немало баитов, в которых наблюдаются признаки лирических протяжных песен (склад стиха, равнодлительность слогонот, широта интонационного развития). А такая повсеместно бытующая песня как “Абдельман купец” только наличием развитой сюжетности соприкасается с баитом»[1].*

*2009 елны Әстерханнан «Татар җыры» конкурсыннан кайтканда Волгоград каласына кердем. «Старая Сарепта» тарихи-мәдәни кирмәнендә Татар мәдәнияте бүлеге мөдире Таифә ханым Мостафина мине шәһәрдән ерак түгел Иске Чапурин авылына алып барды. Анда яңа Мәдәният йорты ачылу тантанасында катнаштык. Бу авыл бик данлыклы – классик шедеврыбызга әйләнгән «Чатырлар» җыры монда табылган. Таифә ханым мине Рита ханым Саянова (1940 елгы) фатирына алып барды. Ул чыгышы белән Түбән Новгород каласыннан. Әнисе Сергач ягы Анды, әтисе Рыбушкино – Рбища авылыннан. Әтисе авылыннан һәрчак шәһәргә төрле эшләр белән кешеләр өзелмәгән. Менә шулар җырлаган «Әптелмән купис»ны отып калган да инде яшь вакытында Рита Юнисова (бу аның кыз фамилиясе).*

*Ә җырның текстындагы үзенчәлекләре белән инде 1962 елда ук «Материалы по татарской диалектологии» дигән фәнни хезмәттә хәбәр ителгән[2]. Шул ук сериянең 1974 елгы басмасында диалектолог Д. Рамазанованың Ульяновски өлкәсе Карсун районы Татар Горенкасы авылында һәм Инза районы Шлемасс авылында алынган язмасы бар: «“Әптелмән купец” һәм “Шәрук егет”*

---

[1] *Нигмедзянов М.* Татарская народная музыка. Казань: Магариф, 2003. С. 165

[2] Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962. С. 295–296.

*бәетләре үзләренә махсус көй белән җырланалар һәм халык арасында җыр булып киткәннәр дияргә мөмкин... Бу җырда ялган акча ясап баеган сәүдәгәрне халыкның яратып бетермәве, аңа мыскыл катыш көлеп каравы күренеп тора»*[1].

*Д. Рамазанова шулай ук 1994–1998 елларда Себергә оештырылган экспедицияләр материаллары тупланган «Себер диалектларыннан материаллар» исемле китабында Төмән өлкәсе Ялутор районы Аслана авылында табылган текстны китерә:*

*Көннәр күкри, йәшни күк,*
*Апакай атлар кешнидер.*
*Күп алакайларның ияләре*
*Баш китәргә эшне эшлидер.*

*Әптелмән купецның кара туры аты*
*Цапкан атка каршы юргапый.*
*Әптелмән купецны аткалы апцыкканта*
*Ь1спрауник пашын боргалый*[2].

*Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылында Таһир Селивановтан (1905 елгы) әсәрнең түбәндәге юлларын да язып алдык:*

*Әп/е/телман бай куписның*
*Ишек алды сарайлар,*
*Сарайларгай эленгән тарайлар.*
*Әп/е/телман бай куписның*
*Аяклары димен лә*
*Баструк тирәзәсендин карайлар.*
*Дим елгаларының буйларында димен лә*
*Ун ик/е/иде минем тирмәнем*[3].
*Кешеләргә дә генәй ай бирмәдем, димен лә,*
*Үзем/е/ дә изгелеген күрмәдем.*

[1] Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1974. С. 223–224.

[2] *Рамазанова Д.Б.* Себер диалектларыннан материаллар. Казан: Фикер, 2001. Б. 8.

[3] Тирмән – тегермән.

# Бәет




Бер мөнәҗәт әйтәйем, әгәр кабул күрсәгез.
Муллагали Тәскирәсен йат итәмен, тыңлагыз.
Муллагали түзә алмый, керле тәннең шешенә,
Түзмәенчә нихәл итсен бер Алланың эшенә.

*1968 елда Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Сәлимҗанов Гыйльманнан (1889 елгы) магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Тәзкирә бәете

*(«Тәфтиләү» көенә)*




Тишәмбә көн ауру булып
Яттым әҗәл түшәкемәи
Әҗәл җитеп, вакыт җиткәч,
Җаным килде күкрәгемә.

*Түмән өлкәсе Ялутор районы Исәт авылында Яхина Җомабикәдән (1903 елгы) И. Кадыйров тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Зөлхәбирә




Капкыннар салтым тау буена,
Тау буенда йөргән төлкегә.
Мостаба мулла – пик сур мулла,
Калган калыкларга көлкегә.
Мостаба мулла – пик сур мулла,
Калган калыкларга көлкегә.

Әнекәем күлмәк тектергән,
Итәк читен читләп бөктергән.
Мостаба мулла – пик сур мулла,
Карта уйнап кысын оттырган.
Мостаба мулла – пик сур мулла,
Карта уйнап кысын оттырган.

Кара урманнарны таптадым,
Таянырга таяк тапмадым.
Әр йомалар саен катлар ястым,
Җибәрергә җаен тапмадым.
Әр йомалар саен катлар ястым,
Җибәрергә җаен тапмадым.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абитов Биктимердән (1918 елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*«Зөлхәбирә» бәете – халык арасында киң таралган әсәр, ул «Мостафа мулла» исеме белән дә мәгълүм. Казанда төрле вариантларда күп тапкырлар басылган*[1].

[1] Бу турыда: *Ярми Хәмит*. Бәетләр. Казан, 1960. Б. 164–166, 359.

## Зөләйха бәете




Зөләйха суга киткән җирнең
Чакрым ярым чамасы.
Зөләйха сыуларга батты дигәч,
Йөгереп килде анасы.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абитов Биктимер (1918 елгы, 50 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Кәлбиҗамал бәете




Җыл да ике гает була,  
Берсе – Корбан гаете.  
Без әйтәбез, сез тыңлагыз –  
Көлбиҗамал бәете.

Төмәннәргә барган чакта  
Барма димәде әнкәем.  
Барма, кызым, дигән булсаң,  
Бармас идем, әнкәем.

Мине урлап алып китте  
Талымхан пар атлары.  
Муйныма пычак салдылар  
Талымхан караклары.

Алып чиләк, бардым суга,  
Батырып алдым, тулмады.  
Аягым чылбырлы чакта  
Кызганучы булмады.

Моңлы җырларым җырладым,
Чылбыр белән ятканда.
Күзләремдин яшьләр чыкты
Мылтык белән атканда.

Иртә буран, кич тә буран,
Талымханның урамы.
Башымны исыраф итте
Талымханның бурлары.

Кулымдагы яулыгымны
Элдем мин киртәләргә.
Көлбиҗамалның бәете
Төшәр гәҗитәләргә.

*1970 елның 9 июнендә Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Киндерле авылыннан Әхтәриев Рәхимҗан (1904 елгы) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Сәлимә бәете




Кичке сәгать алтыда фабрикадан кайтканда,
Агуланган Сәлимәне больницага салганда.

Салдылар караватка,
Ике доктор, бер сестра йөриләр коткарырга.

Коткармагыз, коткармагыз, мин барыбер үләмен.
Я рәхәтен, я михнәтен каберләрдә күрермен.

Беренче көн килде янга анасы хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде, авыр хәлдә ята, дип.

Икенче көн килде янга дуслары хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде, авыр хәлдә ята, дип.

Өченче көн килде янга сөйгәне хәл белергә.
Доктор аңа хәбәр бирде, амбарларда ята, дип.

Ачтылар амбарларны, күрделәр кара г/ы/руб.
Кара г/ы/руб эчләрендә ята Сәлимә үлеп.

Ач, Сәлимә, ач, Сәлимә, ач. Сәлимә, күзеңне,
Әгәр ачмасаң күзеңне, юк итәмен үземне.

Сәлимәнең яннарында сөйгән яры суелды,
Сәлимәнең сөйгән яры бер кабергә куелды.

*Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абтюкова Шәмсиядән магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Пракуб Мәкүб




Пракуб Мәкүпнең кыслары
Үгес ите ашыйлар.
Җуаш җергән җәш байларга
Буш бутылка ташыйлар.

Пракуб Мәкүпнең кыслары
Төрле кием кияләр.
Аракы эцкән егетләрне
Яратам, дип куалар.

*1968 елда Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде авылында Абитов Биктимердән (1918 елгы) И. Кадыйров һәм Ф. Урманчеев тарафыннан язып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

**Камали бәете**

Әйттерәләр, сүттерәләр
Камали балалары.
Алар белән бигрәк ямьле
Умский калалары.
Камалиның комнатында
Ике өстәл, өч көзге.
Камалида мин дә булдым
Сугыштан кайткан көзне.

Камалиның бер кызы бар
Исемнәре – Хәдичә.
Хәдичә өчен суларга
Төшә яздым әллә ничә.
Камалиның бер кызы бар,
Исемнәре Фатыйма.
Фатыймакай, акчам бетте,
Илләремә кайтыйм ла.

*1968 елда Омск өлкәсе Тәвриз районы Югары Ай авылында Абдуллин Фазылҗан Хәйрулла улыннан (1912 елгы) Х. Мәхмүтов язып алган.*

## Камали бай көе




Уйнап җибәр гармуныңны
«Камарский» көенә.
Кунак кызны күрегең килсә,
Кер Камали өенә.

И, алтурый-балтурый,
Камалигә бар турый.
Камалигә барсаң туры,
Шунда кызлар матуры.

*1973 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Тубылтура авылында Абайдуллин Равил (1937) һәм Абайдуллина Нурия (1940) башкаруында И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

*Информантлар икесе дә Ярково районы Бурбар авылында туганнар.*

*Камали бай, имеш, Казан бае булган. Күп хатыннар тоткан, яшь кызлар алган.*

**Мөнәҗәт**




Кат изәр үлем нәүбәте,
Кат изәр үлем гыйлләте.
Ни әйләсә – үз кодрәте,
Алланың чиксез рәхмәте.

Куркам үлем нәүбәтеннән,
Төрле-төрле гыйлләтеннән.
Өмитем күп рәхмәтеңнән
Кыйльма мәхрүм яннәтеңнән.

Алып килерләр бер таяк
Буендин үлчәп алырга.
Сабый балам юктыр минем
Артымнан җылап калырга.

Юл буендагы чирәмне
Юлаучылар аты ашый.
Дөнья ачысы ачы түгел,
Үлем ачысы бик ачы.

........................................
Ал җефәккә тезмәк кирәк,
Җан бирүләр ачы диләр,
Нихәл генә түзмәк кирәк.

Җаным тәндән аерылгач,
Сиягем китәр сузылып.
Карап торырлар тезелеп,
Елаучым кала өзелеп.

Садахамны өләшегез
Кәфенемне җүләгәндә.
Ризалыгым юктыр минем
Гайбәтемне сүләгәнгә.

*1970 елның 8 июнендә Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сабитова Бибинур (1894 елгы, 75 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

**Әбәү Алла**




Әбәү Алла, чәнчү ала  
Тәндин түбән – бәгеремдин.  
Бу кайгымнан вафат булсам,  
Очкын чыгар каберемдин /лә/,  
Очкын чыгар каберемдин.

Әбәү Алла, диямен /лә/,  
Башым түбән иямен.  
Башым түбән, күңлем сүнгән,  
Шул кадәрле көямен /лә/  
Шул кадәрле көямен.

*1971 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Лаймтамак авылында Таҗетдинова Җәмилә (1906 елгы) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров һәм М. Кадыйрова тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Мөнәҗәт




Яттым, я, Алла,
Тордым, Иншаалла.
Шушы ятудан тормасам,
Иман бирсен бер Алла.

Иман белән үтәем,
Чыназа берлән китәем.
Күптер мәнем гөнаһым,
Кылса гафу илаһым.

*1970 елның 8 июнендә Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сабитова Бибинур (1894 елгы, 75 яшь) җырлаган. Магнитофон тасмасына И. Кадыйров тарафыннан яздырып алынган. Нотага төшерүче И. Кадыйров.*

## Мөнәҗәт




Әй Ыраппым, сән яраттың мәне үзең,
Әй Ыраппым, сән яраттың мәне үзең.
Әй, Ыраппым, биргел мәне ике күсем,
Әй, Ыраппым, биргел мәне ике күсем.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш *(И. Закирова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

Себер татарлары музыкасы *(И. Кадыйров)* . . . . . . . . . 6

Напевы в дастанах и сказках западно-сибирских татар
*(И. Кадыров)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20

Татар халык дастаннары – жырулы йомак *(И. Закирова)* . . . . 32

Кузы Көрпәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

«Кузы-Күрпәч һәм Баян Сылу» дастанынннан назым:
әнисе җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54

Кузы Көрпеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

Баян белән җиңгәсе диалогы . . . . . . . . . . . . . . 72

Кузы Көрпеч белән Баян Сылу . . . . . . . . . . . . . . 73

Кузының әнисе белән диалогы . . . . . . . . . . . . . . 82

Бүз егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83

Бүс егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .108

Бүсьегет. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .110

Бүз егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .111

Бүз егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .113

«Бүз егет» дастанының «Йар-йар» җырлары . . . . . . . .114

Беренче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .114

Икенче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .115

Өченче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117

Дүртенче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .119

Бишенче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .121

Алтынчы җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .122

Җиденче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .123

Тайыр менән Сәүрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124

«Таһир-Зөһрә» дастаны көйләре . . . . . . . . . . . . . . . .142

Беренче көй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .142

Икенче көй. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .143

Өченче көй. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .147

Сәйфелмөлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .148

Сәйпелмөлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .155

«Сәйфелмөлек» дастаны көйләре. . . . . . . . . . . . . . . .161

Беренче көй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .161

Икенче көй. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .162

Өченче көй. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .164

«Әйтүкә»: җырдан дастанга *(И. Закирова)*. . . . . . . . . .165

Әйтүкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .171

Дастаннарга тиң мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . .185

Әйтүкәнең беренче җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . .189

Әйтүкәнең икенче җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . .192

Мөлтәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .193

«Мөлтәл» әкиятеннән назым . . . . . . . . . . . . . . . .198

«Колган байның кызы» йомагыннан назым . . . . . . . . . .199

Бәетләр һәм тарихи җырлар *(И. Закирова)* . . . . . . . . . . .200

Баиты и мунажаты *(И. Кадыров)* . . . . . . . . . . . . . . . .202

«Башмагым» җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .222

Башмагым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .224

Хан кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .228

Илаһи матур хан кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . .229

Кан кызы *(Кан кызы, ач ишегең, бән керәйем)*. . . . . . . . .232

Кан кызы Кан кызы *(Кан кысы, аң ишегең, мин герәйен)*. . .233

Мәрәтнең җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .235

Мәхмүт мәргән. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .237

Туктасын качкын җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . .238

Шәрук. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .240

Бараба җиренә күчкәндә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .242
Солдат җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .244
Беренче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .244
Икенче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .245
Өченче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .246
Безнең илләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .247
Бишенче җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .248
Герман сугышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .250
Тоткыннар җыры. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .252
Испанчылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .253
Бандит көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .255
Баламишкин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .257
Сак-Сок бәете *(Мәдрәсәләрдә китап киштәсе)* . . . . . . . .259
Сак-Сук . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .264
Сак-Сок бәете *(Әнекәй каргагач)* . . . . . . . . . . . . . .267
Сак-Сокү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .268
Көйдем бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .269
Көйтем йантым бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .270
Рус-япон сугышы бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .271
Гыйбадулла бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .273
Бәет *(Арынкының сиратындай)* . . . . . . . . . . . . . . . . .276
Бәет *(Аклы ситса күлмәгем)* . . . . . . . . . . . . . . . . .277
Бәет (*Сара апа иртән торгачтын да)* . . . . . . . . . . . . .279
Суга баткан Гайшә бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . .280
Гайшә бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .282
Мөхәррәм мулла бәете. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .284
Борынгы бәет. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .285
Әбделмән купец бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .286
Бәет *(Бер мөнәҗәт әйтәйем, әгәр кабул күрсәгез)* . . . . . .291
Тәзкирә бәете *(«Тәфтиләү» көенә)* . . . . . . . . . . . . . .292
Зөлхәбирә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .293

Зөләйха бәете. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .295
Кәлбиҗамал бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .296
Сәлимә бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .298
Пракуб Мәкүб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .299
Камали бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .300
Камали бай көе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .301
Мөнәҗәт *(Кат изәр үлем нәүбәте*). . . . . . . . . . . . .302
Әбәү Алла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .304
Мөнәҗәт *(Яттым, я, Алла)* . . . . . . . . . . . . . . . . .305
Мөнәҗәт *(Әй Ыраппым, сән яраттың мәне үзең)* . . . . . .306

**Ноталарны компьютерда Д.Н. Арсланова һәм Н.Х. Нургаянова җыйды**

**Д.Н. Арсланова:** Испанчылар, Шәрүк, Гыйбадулла бәете, Тоткыннар җыры, Бәет *(Арынкының сиратындай),* Бәет *(Бер мөнәҗәт әйтәем),* Гайшә бәете, Бәет *(Аклы ситса күлмәгем),* Бәет *(Сара апа иртән торгачтын да),* Пракуб Мәкүб, Камали көе, Мөхәррәм мулла бәете, Тәскирә бәете, Борынгы бәет, Көйдем бәете, «Кузы Көрпәч» дастаныннан Кузының әнисе белән диалогы, «Кузы Көрпәч» дастаныннан Баян белән җиңгәсе диалогы, «Колган байның кысы» йомагыннан назым, «Мөлтәл» экиятеннән назым, «Бүз егет» дастаны җырлары, «Әйтүкә» җырлары, «Таһир-Зөһрә» дастаныннан назым *(Әйтә, гыслар, үтәлек, тите),* Мәхмүт мәргән, Туктасын качкын җыры, Әптелман купец, «Сак-Сок» бәете көйләре, Зөләйха бәете, Сәлимә бәете, Көйтем-янтым бәете, Зөлхәбирә бәете, Мәрәтнең җыры, Көлбиҗамал бәете, Мөнәҗәт *(Әй Ыраппым, сән яраттың мәне үзең),* Мөнәҗәт *(Кат изәр үлем нәүбәте),* Әбәү Алла, Мөнәҗәт *(Яттым, я, Алла),* Солдат җырлары, Безнең илләр, Герман сугышы җыры, Рус-Япон сугышы бәете.

**Н.Х. Нургаянова:** Башмагым, «Хан кызы» көйләре, Бараба җиренә күчкәндә, Бандит көе, Баламишкин, «Таһир-Зөһрә» дастаныннан ике назым *(Кысыл алма айагың), (Таһире затыңы пәримә),* «Сәйфелмөлек» дастаныннан ике назым *(Кашың карай күсеңнең күклегенәй), (Йәшел сантык эцләрентә алтын кашык),* «Бүз егет» дастаныннан «Яр-Яр» җырлары (җиде көй).

Научное издание

**Кадыров Ильгиз Шафикович**
**Закирова Ильсеяр Гамиловна**

**МУЗЫКАЛЬНО-ЭПИЧЕСКОЕ ТВОРЧЕСТВО ТАТАРСКОГО НАРОДА**
**Сибирский ареал**

Редакторы: *Л.Г. Шарифуллина, Д.Р. Галиуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать 09.12.2022.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 18,2. Уч.-изд. л. 12. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20